**БУ САНДА**

## ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Йосыпов Ф.Й.* Нагайбәк татарлары сөйләшенең фонетик үзенчәлекләре турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
*Хисамов О.Р.* Бараба татарларын өйрәнү тәҗрибәсеннән . . . . . . 19
*Мирхәев Р.Ф.* Татар язуы тарихыннан . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
*Вәлиева М.З.* Лексик-семантик категорияләрне иске татар язма чыганаклары нигезендә өйрәнү . . . . . . . . . . . . . . . . . 31

## ӘДӘБИ БАГЛАНЫШЛАР

*Кунафин Г.С.* XIX гасыр әдәби «башкорт җыры» жанрының идея-художество үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
*Калижанов В.К.* Казакъстан әдәбияты һәм бүгенге заман . . . . . 43

## КОНКУРСКА

*Хәбибуллина Л.Г.* Әдәби тәрҗемә мәсьәләсе (Анна Ахматованың «Сайланма әсәрләр»е мисалында) . . . . . . . . 49
*Хаҗиева-Демирбаш Г.С.* Рафаил Газиз хикәяләренең поэтик ономастикасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54

## ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Рогачев В.И.* Мордва фольклорында татар образы . . . . . . . . . . 59
*Дәүләтшина Л.Х.* Халкыбызның дини-мифологик күзаллаулары (материал туплау өчен сораулык) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65

## ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Кореева Н.А.* XIX гасырның беренче яртысында татар эшмәкәрләре эшчәнлегендә вексель хокукы . . . . . . . . . . . . 75

## ФӘЛСӘФИ ФИКЕР

*Корганбеков Б.С.* Күчмә төркиләрнең рухи яшәешендә Хуҗа Әхмәт Ясәви карашлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87

## ТӨГӘЛ ФӘННӘР

*Галимҗанов Ә.Ф., Миңнегалиева Ч.Б.* Гомумиләштерелгән интерполяцион полиномиаль оператор . . . . . . . . . . . . . . . . 99

## МАНСУР ХӘСӘНОВКА – 85

*Заһидуллина Д.Ф.* Әдәбият галиме Мансур Хәсәнов: Г. Ибраһимовның иҗат мирасын комплексны өйрәнү . . . . . . . 111
*Таһиров И.Р.* Мансур Хәсәнов – күренекле галим, кыю һәм тәвәккәл дәүләт эшлеклесе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
*Зыятдинов А.Ш.* Ул эш кешесе иде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
*Фәйзуллина Ф.Г.* Мансур Хәсәнов. «Сайланма хезмәтләр»: яңа китапка күзәтү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127

## ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТКӘ – 120

*Галимуллин Ф.Г.* Таҗи Гыйззәт иҗатында татар халкы язмышы . 130
*Миңнуллина Ф.Х.* Т. Гыйззәт драматургиясендә шәхес фаҗигасе . 135
*Арсланов М.Г.* Таҗи Гыйззәтнең иҗат эволюциясе . . . . . . . . 140
*Шакирҗан Л.Г.* Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры репертуарында Таҗи Гыйззәт иҗаты . . . . . . . . . . . 146
*Хәйруллин И.З.* Таҗи Гыйззәт иҗаты һәм периферия театрлары . 154

## ҖӘМИЛ ГЫЙЛЬМАНОВКА – 90

*Хәмидуллин Л.* Ул һәрчак үрнәк булды . . . . . . . . . . . . . 157

## ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР ЭЗЕННӘН

*Алкая И.* Себергә сәяхәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160

## ЯҢА КИТАПЛАР

Урманче Ф.И. Тюркский героический эпос . . . . . . . . . . . . 168
Илдар Ханов. Воспоминания, размышления о творчестве . . . 170
Г. Тукай әсәрләренең III һәм IV томнары турында . . . . . . . . 171

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

**В НОМЕРЕ**

## ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Юсупов Ф.Ю.* О фонетических особенностях говора нагайбакских татар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
*Хисамов О.Л.* Из опыта изучения барабинских татар . . . . . . . . 19
*Мирхаев Р.Ф.* Из истории татарской письменности . . . . . . . . . . 25
*Валиева М.З.* Изучение лексико-семантических категорий по старо-татарским письменным источникам . . . . . 31

## ЛИТЕРАТУРНЫЕ СВЯЗИ

*Кунафин Г.С.* Идейно-художественные особенности литературного жанра XIX века «башкирская песня» . . . . . . . . 37
*Калижанов В.К.* Казахская литература и современность . . . . . . 43

## НА КОНКУРС

*Хабибуллина Л.Г.* Вопросы литературного перевода (на примере «Избранных произведений» Анны Ахматовой) . . . . 49
*Хазиева-Демирбаш Г.С.* Поэтическая ономастика рассказов Рафаиля Газиза . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54

## НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Рогачев В.И.* Образ татарина в мордовском фольклоре . . . . . . . 59
*Давлетшина Л.Х.* Религиозно-мифологические представления татар (вопросник для сбора материала) . . . . . . . . . . . . . . . . . 65

## СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Кореева Н.А.* Реализация вексельного права среди татарских предпринимателей в первой половине XIX века . . . . . . . . . . 75

## ФИЛОСОФСКАЯ МЫСЛЬ

*Корганбеков Б.С.* Духовность тюрков-кочевников и Ходжа Ахмет Ясави . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87

## ТОЧНЫЕ НАУКИ

*Галимзянов А.Ф., Миннегалиева Ч.Б.* Обобщенный интерполяционный полиномиальный оператор . . . . . . . . . . . . . 99

## МАНСУРУ ХАСАНОВУ – 85

*Загидуллина Д.Ф.* Литературовед Мансур Хасанов: комплексное изучение творческого наследия Г. Ибрагимова . . . . 111
*Тагиров И.Р.* Мансур Хасанов – знаменитый ученый и решительный государственный деятель . . . . . . . . . . 116
*Зиятдинов А.Ш.* Он был человеком дела . . . . . . . . . . . . . . . . 121
*Файзуллина Ф.Г.* Мансур Хасанов. «Сайланма хезмәтләр»: новая книга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127

ТАЗИ ГИЗЗАТУ – 120

*Галимуллин Ф.Г.* Судьба татарского народа в творчестве Т. Гиззата . 130
*Миннуллина Ф.Х.* Трагедия личности в драматургии Т. Гиззата . . 135
*Арсланов М.Г.* Творческая эволюция Тази Гиззата . . . . . . . . . . 140
*Шакирзянова Л.Г.* Творчество Тази Гиззата в репертуаре Татарского государственного академического театра им. Г. Камала . 146
*Хайруллин И.З.* Творчество Тази Гиззата и театры периферии . . 154

ЗАМИЛЮ ГИЛЬМАНОВУ – 90

*Хамидуллин Л.* Он всегда был примером . . . . . . . . . . . . . . . . 157

ПО СЛЕДАМ ЭКСПЕДИЦИЙ

*Алкая И.* Путешествие в Сибирь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160

НОВЫЕ КНИГИ

Урманче Ф.И. Тюркский героический эпос . . . . . . . . . . . . . 168
Илдар Ханов. Воспоминания, размышления о творчестве . . . 170
О III, IV томах произведений Г. Тукая . . . . . . . . . . . . . . . . 171

## БАШ РЕДАКТОР СҮЗЕ

Хөрмәтле галимнәребез!
Мөхтәрәм авторларыбыз һәм укучыларыбыз!

Кулыгызда – «Фәнни Татарстан»ның икенче «журнал елы»н төгәлләп килүче сан. Мәгълүм булганча, ул Татарстан Дәүләт Советы хуплавы белән, Мәгариф һәм фән министрлыгы йөзендә республикабыз Хөкүмәте химаясендә, Татарстан Фәннәр академиясе тарафыннан гамәлгә куелды. Татар телендә фән журналы чыгарыла башлавы җәмәгатьчелектә шактый зур кызыксыну уятты һәм тиешле бәясен алды.

Чыннан да, чагыштырмача кыска бу вакыт эчендә яшь басма үзенең структурасын тәгаенләде, тематик юнәлешләрен билгеләде, эчтәлеген төрләндерү һәм киңәйтү юнәлешендә даими эш алып барды, авторлар даирәсен тупларга өлгерде, укучыларын һәм, кыскасы, үз йөзен табып килә дип әйтә алабыз.

Әлбәттә, ирешелгән кадәресе белән без әле тулысынча канәгать түгел. Яңа басмада, гәрчә хезмәттәшлек итәргә даими чакырып торсак та, кызганыч ки, республикабызның гыйльми потенциалы барлык спектрларында чагылмавы, бигрәк тә төгәл фәннәр, табигать фәннәре өлкәсендә эзләнүләр алып баручы һәм туган телләрендә үз ачышларын, фикерләрен киң җәмәгатьчелек белән уртаклаша алырлык галимнәребезнең активлыгы җитмәве яки аз булуы күренде. Яшь коллегаларыбызның, бигрәк тә аспирантларның шундый бәрәкәтле мәйданнан тиешенчә файдалана алмавы татар телендә фәннең алга үсеше турында билгеле бер борчылу хисләре уятмый калмый.

Быел Россиядә Әдәбият елы игълан ителү уңаеннан һәм яшь галимнәрнең хезмәтләренә өстәмә стимул-этәргеч бирү максатында, журналыбыз кысаларында махсус конкурс-бәйге игълан ителгән иде. Конкурска килгән кайбер материаллар инде басылып та чыкты, һәм аларга тиздән йомгак ясалачак. Алдан хәбәр ителгәнчә, җиңүчеләрнең исемнәрен атау, аларны бүләкләү тантанасы Татарстан Фәннәр академиясенең (Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының) еллык эшенә йомгак ясау җыелышында башкарылыр дип көтелә.

Узган ел, бай мәдәни мирасыбызны барлау юлындагы эшләребез – төрле дәрәҗәдәге һәм шәкелдәге (форматтагы) фәнни-гамәли конференцияләр, монографик хезмәтләр һәм күмәк (коллектив) җыентыклар белән бергә, журналыбыздагы язмаларда да киң чагылыш тапты. Бу санда да Татарстан Фәннәр академиясе белән берлектә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре оештырган юбилейлар уңаеннан талантлы драматург

Таҗи Гыйззәт, күренекле әдип, галим һәм дәүләт эшлеклесе Мансур Хәсәнов, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында булып узган танылган тарихчы Җәмил Гыйльмановка багышланган мәкаләләр урын алды.

Гомумән, «Фәнни Татарстан» милли-мәдәни мирасыбыздан үрнәкләрне, аларга күзәтү ясаган, анализлаган эшләрне биреп баруны даими күз уңында тотарга тырыша.

Соңгы елларда Фәннәр академиясенең төрки дөнья гыйльми оешмалары, фән эшлекделәре белән элемтәсе ныгый бара, зур ачышлар вәгъдә итүче уртак проектлар өстендә эшләүгә җитди адымнар ясала. Бу эшчәнлекнең барышы һәм нәтиҗәләре журнал сәхифәрендә дә чагылыш табуын күрәсез.

Туган телебезнең хасиятләрен барлау, грамматик үзенчәлекләрне, зур байлыгыбыз булган диалект-сөйләшләрне, тел тарихын өйрәнүгә йөз тоткан фәнни эзләнүләр һәр санны ачып җибәрүче «Тел белеме» рубрикасында урын ала.

«Сәнгать» рубрикасы журналыбызны бизәсә, «Фәнни-иҗтимагый тормышыбыздан» һәм «Яңа китаплар» бүлекләре укучыны мәгълүмати яктан баета. Милли мәгариф тарихын һәм аның бүгенге торышын, тел өйрәтү һәм дәреслекләр әзерләү проблемаларын яктырткан хезмәтләргә дә игътибар зур.

Алда әйтелгәнчә, журналның йөзен аның авторлары – күренекле галимнәребез, яшь фән эшлекләре билгели. Без алга таба да сезнең белән дәвамлы һәм нәтиҗәле хезмәттәшлеккә өметләнәбез.

«Фәнни Татарстан» сәхифәләренә рәхим итегез!

УДК 811.512.145´*342*

***Ф.Й. Йосыпов***

# НАГАЙБӘК ТАТАРЛАРЫ СӨЙЛӘШЕНЕҢ ФОНЕТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ ТУРЫНДА

В предыдущей статье автора вкратце была освещена история формирования нагайбакских татар и их говора. Данная статья посвящена изучению фонетических особенностей говора нагайбакских татар. Как показали исследования, нагайбакский говор, с точки зрения фонетических особенностей, входит в единую систему диалектов татарского языка.

**Ключевые слова:** диалекты и говоры татарского языка, нагайбакский говор, фонетические особенности говора.

Нагайбәкләр сөйләшендә ун сузык аваз бар:

Арткы рәт сузыклар: **[а], [у], [о], [ы], [ый].**

Алгы рәт сузыклар: **[ә]//[ә], [е], [ү], [ө], [и].**

Татар әдәби теленә рус теле аша кергән **[о], [ы]**, **[э]** авазлары без өйрәнә торган сөйләштә кулланылмый, сөйләшнең үз авазлары белән алмаштырып әйтеләләр.

Кайбер авазларны исәпкә алмаганда, сузыкларның әйтелеше ягыннан Нагайбәк сөйләше татар әдәби теленнән, нигездә, аерылмый. Сөйләшнең төп үзенчәлекләре итеп, түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин:

**1. [а]** авазы. Бу сузыкның әйтелешен билгеләү татар диалектологиясендә зур әһәмияткә ия. Чөнки [а] авазының әйтелеше ягыннан урта һәм мишәр диалектлары бер-берсенә каршы куела. Билгеле булганча, урта диалект сөйләшләренә иренләшкән [а$^0$] авазы, мишәр диалекты өчен ачык [а] хас дигән фикер урнашкан [Бурганова, 1962, с. 10; Махмутова, 1962, с. 33]. Ләкин бу билгеләмәләрне шартлы рәвештә генә кабул итәргә мөмкин. Дөреслектә исә урта диалект сөйләшләре үзләре үк [а] авазын иренләштереп яки ачык әйтү буенча бер-берсеннән нык аерылып торалар. Бу үзенчәлектән чыгып, урта диалект, нигездә, ике төркем сөйләшләрне берләштерә дип әйтергә булыр иде:

а) иренләштерүче сөйләшләр: казан арты, тау ягы, минзәлә, өлешчә златоуст, абдулла, каргалы сөйләшләре. Иренләштерү дәрәҗәсе ягыннан да бу сөйләшләрнең кайберләре әдәби телдән аерылып тора;

ә) [а] авазын нугай тибындагы [а] кебек ачык итеп, иренләштерми торган сөйләшләр: казан арты-дөбьяз, касыйм, нократ-кистем, пермь сөйләшләре;

Нагайбәк сөйләше бу яктан урта диалектның икенче төркем сөйләшләренә якын тора, ягъни монда [а] авазы – ачык, арткы рәт, түбән күтәрелештәге, иренләшмәгән сузык аваз, сүзнең барлык позицияләрендә – тамыр һәм кушымчаларда кулланыла: *ай, ал, аш, алты, арба, баш,*

*сал, қар, сала, бала, ала, қарға, талда, баралар, балаларға* һ.б.

Ләкин [а] авазының сөйләштәге әйтелеше барлык фонетик позицияләрдә дә бертөсле түгел. Ул беренче иҗектәге иренирен [о] авазы йогынтысында ирен төсмере белән әйтелә. Шулай да иренләшү дәрәҗәсе әдәби телдәгегә караганда кимрәк: *бора⁰, сора°, тора⁰, тота⁰, бора°у, боза°у, бода°й, монда°ғы, тора⁰лар* һ. б.

[а] авазын ачык әйтү ягыннан, нагайбәк сөйләше нугай компоненты катнашында формалашкан урта диалектның касыйм [Махмутова, 1955, с. 151], нократ-кистем [Бурганова, 1962, с. 10], казан арты-дөбьяз, пермь һәм кайбер керәшен [Баязитова, 1986, с. 49; Рамазанова, 1996, с. 39] сөйләшләре белән зур уртаклык күрсәтә. Әйтергә кирәк, нагайбәк сөйләшендәге ачык [а] авазы гомумтөрки ачык [а] авазына якын тора.

**2.** Нагайбәк сөйләшендә **[ә]** авазының ике төрле варианты бар:

а) татар әдәби телендәгечә, алгы рәт (нечкә), түбән күтәрелештәге (киң), иренләшмәгән сузык аваз. Сөйләштә бу авазның кулланылышы актив, ул төрле фонетик шартларда һәм сүзнең төрле позицияләрендә килә ала: *әнә, әкрен, әби, бәке, бәлеш, тәкә, тәтәү, тәрәзә, күгәрчен* һ.б.;

ә) нократ-кистем, касыйм [Махмутова, 1955, с. 150] һәм мордва-каратай [Арсланов, 1965, с. 120] сөйләшләрендәге кебек, әдәби әйтелешкә караганда, таррак варианты. Сөйләштә бу авазның кулланылышы аерым фонетик шартлар белән чикләнгән. Югарыда күрсәтелгән сөйләшләрдәге кебек үк тар [ә] варианты, күзәтүләргә караганда, беренче иҗектә тар [и],[ә[е]] сузыклары булган сүзләрдә әйтелә: *җиргә, киңәш, эченә, пешерә, итәләр, килә, эшләдек, беткән, белән, кешеләр, шикәр, печәннәр* һ. б.

Бу яктан нагайбәк сөйләше Урал төбәгендә таралган пермь һәм красноуфим сөйләшләре белән уртаклык күрсәтә. Бу сөйләшләрдә бер төркем сүзләрдә түбән күтәрелештәге киң [ә] авазы, тараеп, урта күтәрелештәге ярымтар [е] авазы белән алмаштырылып әйтелә. Димәк, [ә] авазының тар вариантын куллану ягыннан, Урал лингвистик ареалында үзенчәлекле изоглосса барлыкка килә. Бу, үз чиратында, әлеге территориядәге сөйләшләрнең формалашуында борынгы төрки компонентның катнашуы турында сөйли.

Сөйләштәге башка сузыкларның әйтелеше татар әдәби теленнән аерылмый. Шулай да әйтелешләре һәм табигатьләре татар диалектлары өчен мөһим булган **[о], [ө]** сузыкларының артикуляциясе турында әйтеп китәргә кирәк.

Сөйләштә [о] сузыгы – катнаш рәт, иренләшкән сузык аваз. Әйтелеше урта диалектның казан арты, тау ягы, минзәлә, бөре, златоуст сөйләшләрендәге кебек. Артикуляцион һәм акустик яктан бу аваз әдәби телдәге варианттан да аерылмый. Сүзнең төрле позицияләрендә килергә мөмкин; беренче, икенче, өченче, хәтта дүртенче иҗекләрдә дә ачык ишетелә. Бу яктан татар әдәби теленең барлык нормаларына туры килә:

*он, от, тор, бор, тотона, борола, боролош, ҷоролма, тормошо* һ.б.

Билгеле булганча, мишәр диалектында һәм урта диалектның нугай нигезле сөйләшләре өчен бу аваз хас түгел.

Катнаш рәт, иренләшкән [ө] сузыгын куллану буенча да нагайбәк сөйләше урта диалектның югарыда санап үтелгән нигез сөйләшләре һәм татар әдәби теленә якын тора. Бу аваз сүзнең беренче, икенче, өченче иҗекләрендә дә ачык ишетелә. Артикуляцион һәм акустик табигате ягыннан татар теленең орфоэпик нормаларыннан тайпылмый: *төр, төрлө, төрлөсө, бөрө, бөрлөгән, төн, төнгө, төзөлөшө* һ.б.

Нагайбәк сөйләше сузык авазлары арасындагы тәңгәллек күренеше белән дә урта диалект сөйләшләренә якын тора. Әдәби телдән аермалы булган үзенчәлекләрдән түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин:

**1. [а], [ә] ~ [ы], [е]** сузыклары арасындагы тәңгәллек *-ғынчы, -генче* формалы хәл фигыль кушымчаларында күзәтелә: *алғынчы – алганчы, барғынчы – барганчы, җатҷынчы – ятканчы, булғынчы – булганчы, торғынчы – торганчы, җыйылғынчы – җыелганчы, беткенче – беткәнче, әйткенче – әйткәнче, күргенче – күргәнче, килгенче – килгәнче* һ.б.

Сузыклар арасындагы әлеге тәңгәллек татар теле сөйләшләрендә киң таралган күренешләрдән санала. Аерым сөйләшләрдә [а], [ә] ~ [ы], [е] күренеше күбрәк сүзләргә һәм формаларга карарга мөмкин. Бу үзенчәлеге белән нагайбәк сөйләше бигрәк тә урта диалектның казан арты һәм тау ягы [Бурганова 1955, с. 62], пермь [Рамазанова, 1996, с. 40], златоуст, эчкен сөйләшләренә якын тора.

Киң [а], [ә] сузыкларын хәл фигыль формаларында тар [ы], [е] сузыклары белән тәңгәлләштерү керәшен сөйләшләренең уртак үзенчәлекләреннән санала [Баязитова, 1986, с. 50].

**2. [о] ~ [у].** Әдәби телдәге ирен-ирен кыска [о] сузыгын ирен-ирен озын [у] авазы белән алмаштыру түбәндәге сүзләрдә күзәтелде: *суң – соң, сурашу – сорашу, бутҷа – ботка.* [о] ~ [у] тәңгәллеге бер төркем сүзләрдә татар теленең барлык сөйләшләрендә дә күзәтелә. Ләкин бу яктан да нагайбәк сөйләше бигрәк тә Урал төбәгендә таралган пермь, красноуфим, златоуст сөйләшләренә якын тора.

**3. [у] ~ [ы].** Бер төркем сүзләрдә ирен-ирен озын [у] авазын иренләшмәгән кыска [ы] сузыгы белән алмаштыру да бар: *быйау* – бuяу, *былышу* – булышу, *былу* – булу һ.б. Мәгълүм булганча, ирен-ирен [у] сузыгын иренләшмәгән [ы] сузыгы белән тәңгәлләштерү бигрәк тә мишәр сөйләшләре өчен хас.

**4. [ү] ~ [ө].** Югары күтәрелешле, алгы рәт, иренләшкән [ү] сузыгы сөйләштә әйтелеше һәм кулланылыш ягыннан да татар әдәби теленнән аерылмый. Бары тик Астафьевка авылында яшәүчеләр сөйләмендә *бүген, түгел* сүзләрендәге [ү] сузыгын урта күтәрелешле, иренләшкән, тар әйтелешле [ө] белән алмаштырып, *бөгөн, төгөл* дип сөйлиләр.

Димәк, бу яктан да нагайбәк сөйләшенең татар әдәби теленә

һәм урта диалектның нигез сөйләшләренә якынлыгы күренә.

Сингармонизм күренешләрендә дә нагайбәк сөйләшен татар әдәби теленнән аерып торган үзенчәлекләр күп түгел. Сүзләрнең калынлыкта-нечкәлектә ярашулары һәм ирен гармониясе эзлеклелеге ягыннан нагайбәк сөйләше татар әдәби теленнән аерылмый. Кайбер үзенчәлекләр итеп, түбәндәге күренешләрне күрсәтергә мөмкин: ирен-ирен [о], [ө] сузык авазлары үзләреннән соң килгән иренсез [ы], [е] авазларын гына иренләштереп калмыйлар, бәлки киң [а], [ә] сузыкларына да тәэсир итеп, аларны беркадәр иренләштерәләр:

а) иренләшмәгән [а] авазы, ирен-ирен [о] сузыгыннан соң килгәндә, үзенең ачыклыгын югалта, әдәби телдәге иренләшкән [а] сыман ирен төсмере белән әйтелә. Өченче, дүртенче иҗекләрдә иренләшү кими, сизелми: *бола°й, тора°, сора°у, тома°н, қора°ма°, бота°қ, тора°қ, қорба°н, қола°қла°р, боза°улар, бола°йрақ* һ.б.;

ә) беренче иҗектә ирен-ирен [ө] авазы булса, аның көчле йогынтысында икенче иҗектәге [ә] авазы берникадәр иренләштереп әйтелә, ягъни [ө] һәм [ә] авазлары уртасындагы үзенчәлекле сузык барлыкка килә: *тәйә$^{ө}$к, көйә$^{ө}$нтә, көрә$^{ө}$ш, терә$^{ө}$ү, көлтә$^{ө}$, төймә$^{ө}$* һ. б.

[ә] авазының ирен-ирен [ө] сузыгыннан сон иренләшү табигате татар әдәби теле өчен дә чит күренеш түгел. В.А. Богородицкий да татар телендә [ө] авазы үзеннән соң килгән [ә] сузыгын берникадәр иренләштерә дип күрсәтә [Богородицкий, 1934, с. 131].

Күрсәтелгән позициядә [ә] авазын берникадәр ө-ләштереп әйтү Себер татарлары диалекты, шулай ук Чиләбе һәм Курган өлкәләрендә таралган эчкен һәм сафакүл сөйләшләрендә дә күзәтелә. Мондый күренеш башкорт әдәби теле өчен дә хас [Киекбаев, 1958, с. 33].

Димәк, Урал төбәгендә [ә] авазының билгеле фонетик позицияләрдә ирен төсмере алуы таралыш чикләре төгәл билгеле булган мөстәкыйль изоглоссада чагыла. Бу изоглосса үз эченә Көнбатыш Себер татарлары диалектын да ала.

Татар теленең күп кенә сөйләшләрендәге кебек үк, нагайбәк сөйләшендә дә сингармоник параллельләр кулланыла. Әдәби телдә калын әйтелә торган сүзләрне нечкәртеп яки, киресенчә, нечкә әйтелә торган сүзләрне калын итеп сөйләү очраклары күзәтелә: *мақрум – мәхрүм, мына – менә, қайырчы – хәерче, бағыт – бәхет, муқлақ сыйыр – мүкләк сыер, әрчү – арчу, җәбешү – ябышу, җәр – яр* һ. б.

Татар әдәби телендәге кебек, нагайбәк сөйләшендә дә чын дифтонглар юк. Бары тик [а], [ә], [у], [ү], [о], [ө], [ы], [е] сузыкларының [й], [w] ярым сузыклары белән ясалган ялган дифтонглар гына кулланыла [Современный татарский..., 1969, с. 87].

Дифтонглар, ясауда катнашкан элементларга карап, төшерелмә һәм күтәрелмә дифтонгларга бүленәләр.

Төшерелмә дифтонглар: [ай], [әй], [ой]; [өй], [aw], [әw] һ.б.:

*тутай, малай, сайрый, майлый, туй, ķуй, унаw, сөйләw* һ. б.

Күтәрелмә дифтонглар: [йа], [йә], [wa], [wә] һ. б.: *йал, йәш, йуķа, йүķә, wалчык, wаķыт* һ.б.

Нагайбәк сөйләшендә, нигездә, татар әдәби теле һәм урта диалект сөйләшләре өчен хас булган дифтонглар кулланыла. Үзенчәлеге итеп, **[ей], [ыу], [еү]** дифтонгларын күрсәтергә мөмкин.

[ей] дифтонгы, системалы рәвештә булмаса да, ачык иҗектә килгән алгы рәт тар [и] сузыгы урынына әйтелә: *кей – ки, кейтер – китер, телей – тели, эшләмей – эшләми, җитмей – җитми, белмей – белми, песей – песи, тейеш – тиеш, Күчтей – Костя* (Казан арты керәшен сөйләшләрендә – *Күчти*), *кейәү – кияү, үгей – үги* һ. б. [и] > [ей] күренеше татар сөйләшләре өчен чит күренеш түгел. Бу үзенчәлек, беренче чиратта, керәшен татарлары сөйләшләренә хас [Баязитова, 1986, с. 56]. [и] сузыгы урынына [ей] дифтонгын әйтү пермь татарлары [Рамазанова, 1996, с. 47], красноуфим, златоуст, эчкен, сафакүл сөйләшләре, шулай ук көнчыгыш диалекты [Тумашева, 1968, с. 70] өчен дә характерлы үзенчәлекләрнең берсе булып тора. Башкорт әдәби теле һәм сөйләшләрендә [Баева, 1959, с. 14] еш кулланыла торган бу дифтонгны, күп кенә тюркологлар кебек, Ж.Г. Киекбаев та борынгы [ег], [ед], [ез] кушымчаларыннан барлыкка килгән дип аңлата [Киекбаев, 1958, с. 86].

Күргәнебезчә, иҗек азагында килгән [и] сузыгы урынына [ей] дифтонгы куллану ягыннан, Урал һәм Көнбатыш Себер лингвистик төбәгендә югарыда күрсәтелгән сөйләшләрне эченә алган мөстәкыйль изоглосса барлыкка килә. Бу изоглоссаның үзәге булып, башкорт теле һәм Көнбатыш Себер татарлары диалекты санала. Минзәлә, бөре, абдулла һәм каргалы сөйләшләре бу изоглоссаның тирбәлеш зонасын хасил итә.

Әдәби телдәге иҗек һәм сүз азагындагы (бигрәк тә исем фигыль кушымчасында) ирен-ирен [у], [ү] сузыкларына борынгы төрки телдәге -ог, -уг, -ыг, -гы, -ге тезмәләре [Баскаков, 1952, с. 416], сөйләштә [ыу], [еү], [ыw], [ew] дифтонглары туры килә:

а) тамыр сүзләр: *сыwыķ – суык, ырыw – ыру, сыw – су, чеw – чү* һ. б.;

ә) исем фигыль кушымчаларында: *тыwған – туган, ķыw – ку, җыw – җыю, сыwсар – сусар, сыwсау – сусау, китеw – китә, бетеw – бетә, алыw – алу, барыw – бару* һ. б.

[ыу], [еү] дифтонгы татар теленең казан арты һәм тау ягы сөйләшләренә, шулай ук мишәр диалектына хас түгел. Бу үзенчәлеге белән нагайбәк сөйләше, беренче чиратта, керәшен татарларының башка сөйләшләре белән зур уртаклык күрсәтә. Югарыда әйтелгән шартларда [ыw], [ew] дифтонгларын куллану буенча нагайбәк сөйләше пермь, златоуст, касыйм, эчкен, сафакүл һәм учалы типтәрләре сөйләшләренә якын тора. Ачык иҗекләрдә һәм сүз азакларында килгәндә, [у], [ү] монофтонглары урынына [ыу], [еү] дифтонгларын әйтү башкорт теле өчен дә хас [Дмитриев, 1948, с. 16].

Димәк, бу үзенчәлек буенча Урал төбәгендә җыйнак изоглосса барлыкка килә. Әлеге изоглоссаның үзәге булып, Көнбатыш Себер татарлары диалекты санала. Минзәлә һәм бөре сөйләшләре бу күренешнең тирбәлеш зонасына керә.

Тюркологиядә урнашкан фикерләргә кушылып, проф. Җ.Г. Киекбаев та [ыу], [еү] дифтонгларын борынгы төрки телдәге [ок], [үк], [ык], [ек], [ыг], [ег] кушымчаларындагы [к], [к], [ғ], [г] тартыкларының [у] – [ү] сузыкларына күчүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән дип аңлата [Киекбаев, 1958, с. 86]. Без өйрәнә торган сөйләштә исә [ыу], [еү] дифтонгы борынгы [ык], [ыг], [ог] кушымчаларына туры килмәгән сүзләрдә дә күзәтелергә мөмкин.

Чибәркүл районында яшәүче нагайбәкләр сөйләшендә әдәби телдәге *өйрәнү, өйрәтә, сөйрәү, өйрә* сүзләрендәге **[өй]** дифтонгын монофтонглаштыру, ягъни ирен-ирен, алгы рәт озын **[ү]** сузыгы белән әйтү бар: *үрәтеү – өйрәтү, үрәнеү – өйрәнү, сүрәү – сөйрәү, үрә – өйрә, күрәй – көйрәү*. Калган сүзләрдә, татар әдәби телендәге кебек үк, [өй] дифтонгы саклана: *сөйләү, көй, чөй, көймә* һ. б.

Татар диалектологиясендә [өй] дифтонгын [ү] сузыгы белән монофтонглаштыру мишәр диалекты өчен хас үзенчәлек дигән фикер урнашкан. Дөрестән дә, бу диалектта [өй] ~ [ү] күренеше системалы төс ала. Шуның белән беррәттән, урта диалектның Урал территориясендә таралган сөйләшләрендә, бер төркем сүзләрдә генә булса да, шулай ук [өй] ~ [ү] күренеше күзәтелә. Нигездә, ул бер үк сүзләрне эченә ала. Бу яктан нагайбәк сөйләше керәшен татарларының башка сөйләшләренә якын. Моннан тыш, әлеге күренеш минзәлә [Рамазанова, 1984, с. 86], бөре, златоуст [Хайрутдинова, 1983, с. 28], пермь [Рамазанова, 1996, с. 48], нократ-кистем сөйләшләре өчен дә хас. Әйтергә кирәк, [өй] ~ [ү] күренешенең изоглоссасы бары тик югарыда күрсәтелгән татар сөйләшләре белән генә чикләнә.

[ей] дифтонгын күрсәтелгән сүзләрдә монофтонглаштыру белән дә нагайбәк сөйләше урта диалект сөйләшләре системасында урын ала.

Ясалу урынына, ягъни актив һәм пассив сөйләм органнарының катнашыннан чыгып, сөйләштәге тартык авазлар түбәндәгечә төркемләнә:

ирен-ирен авазлар: **[б],[w], [п], [м];**

тел очы авазлары: **[д], [т], [з], [с], [ж], [л], [н], [р], [ш];**

тел уртасы авазы: **[й];**

тел арты авазлары: **[г], [к], [х], [ң];**

тирән тел арты авазлары: **[ғ], [қ], [х], [ң].**

Югарыда китерелгән классификациядән күренгәнчә, нагайбәк сөйләше татар әдәби теленнән бары тик башка теллардән кергән [в], [һ], [ф], [ц], [щ] авазларының кулланылмавы белән генә аерыла.

Тартык авазларның әйтелеше ягыннан да нагайбәк сөйләше татар әдәби теленнән аерылмый. Ләкин шулай да бу урында татар теле сөйләшләрендә артикуляцион үзенчәлекләре булган кайбер

тартыкларның әйтелешен билгеләп китәргә кирәк. Чөнки ул сөйләшнең урынын, кайсы диалектка якынлыгын билгеләүдә зур әһәмияткә ия.

Сөйләштә кулланыла торган **[җ], [ч]** тартыклары – тел уртасы, өрелмәле, бер катлы, ике фокуслы авазлар, әйтелешләре белән әдәби телдән аерылмыйлар: *җәй , җыр, җиләк, җитен, җиңел, җирән, җимеш; чит, чебен, читек, читен, чирек, килгәч, чаба, чалгы, чалбар, қайчы, қарлыгач, әтәч* һ. б.

**[қ], [ғ]** авазлары тирән тел арты тартыклары булып әйтелә, бу яктан да нагайбәк сөйләше урта диалект сөйләшләреннән һәм татар әдәби теленнән аерылмый: *қатын, қаты, қарақ; қайрақ, қат, қәбәр, қарағай, тағын* һ.б.

**[ң]** тартыгы арткы рәт сузыклары белән килгәндә, тирән тел авазлары булып әйтеләләр: *чаңғы, караңғы, йаңғыр* һ.б.

Урта диалектның күпчелек сөйләшләрендәге кебек, нагайбәк сөйләшенә дә җ-ләштерү хас. Әдәби телдә тел уртасы **[й]** тартыгы белән әйтелә торган сүзләр боларда тел очы, өрелмәле, бер катлы **[җ]** авазы белән әйтелә. Мәсәлән, а) төрки тамырдан булган сүзләрдә: *җәмне – ямьле, җефәк – ефәк, җегет – егет, җаз – яз, җуқ – юк, җақын – якын, җыл – ел, җатқан – яткан, җөз – йөз, җөрей – йөри, җырақ – ерак, җылақ – елак, җоқо – йокы, җон – йон* һ.б.; ә) алынма сүзләрдә: *дөнҗа – дөнья, пыраулинҗа – правление, личинҗә – лечение, пичинҗә – печенье, памалҗә – фамилия, баринҗа – варенье, Илҗә – Илья, Наталҗа – Наталья* һ. б.

Билгеле булганча, җ-ләштерү татар диалектлар системасында урта диалект өчен хас билгеләрдән санала. Бу үзенчәлеге белән нагайбәк сөйләше казан арты, тау ягы, керәшен татарлары сөйләшләренә якын. Димәк, әлеге күренеш сөйләшне урта диалект системасында карарга нигез бирә торган дәлилләрнең берсе булып санала. Икенче яктан, җ-ләштерү күренешенең системалы булуы белән сөйләш Урал төбәгендә таралган татар теленең башка сөйләшләреннән аерылып тора. Бу сөйләшләрнең кайберләрендә, мәсәлән, минзәлә, бөре, өлешчә пермь сөйләшләрендә, [җ] тартыгы [й] авазы белән параллель кулланыла. Икенчеләре өчен исә, аерым алганда, нократ-кистем, златоуст, эчкен, сафакүл сөйләшләренә [җ] тартыгы бөтенләй хас түгел.

Алынма сүзләрдә дә [й] тартыгын бер катлы өрелмәле [җ] авазына алмаштыру үзенчәлеге белән дә нагайбәк сөйләше башка керәшен сөйләшләреннән аерылмый. Шундый ук үзенчәлек Уралда таралган минзәлә, бөре, красноуфим сөйләшләре өчен дә хас.

Сөйләш өчен характерлы икенче үзенчәлек итеп, әдәби телдәге тирән тел арты һәм тел арты өрелмәле **[х]** тартыгын системалы рәвештә тирән тел арты, шартлаулы саңгырау **[қ]** тартыгы белән алмаштырып сөйләүне әйтергә кирәк: *қалық – халык, қатын – хатын, қат – хат, қақ – хак, қәбәр – хәбәр, мәқрүм – мәхрүм, җақшы – яхшы, өчто-*

*мақ – оҗмах, қәстәр – хәстәр, қурбулу – хур булу, рөқсәт – рөхсәт* һ. б.

Татар әдәби телендәге [х] урынына [к] әйтү теге яки бу күләмдә татар теленең барлык сөйләшләрендә дә табыла. Шулай да ул аеруча керәшен татарлары сөйләшләре өчен хас. Бу яктан нагайбәк сөйләше әлеге сөйләшләр белән зур уртаклык күрсәтә. Татар диалектологиясендә бу күренеш бигрәк тә урта диалект үзенчәлеге дип санала. Керәшен татарлары сөйләшләреннән тыш, [х] ~ [к] күренеше пермь [Рамазанова, 1969, с. 13], нократ-кистем [Бурганова, 1962, с. 30] сөйләшләрендә дә киң таралган. Әлеге үзенчәлек Көнбатыш Себер татарлары сөйләшләрендә дә системалы төс ала [Тумашева, 1961, б. 28]. Урта диалектның казан арты, бәрәңге сөйләшләрендә дә ул шактый актив. Минзәлә, бөре сөйләшләрендә исә аерым сүзләрдә генә күзәтелә.

**[б] ~ [м].** Татар теленең үз сүзләрендә ирен-ирен яңгырау [б], рус һәм интернациональ алынмалардагы ирен-теш [в] тартыклары, берничә сүздә генә булса да, ирен-ирен [м] соноры белән тәңгәлләшә: *мәндә – бәндә, Моқар – Бохара, җәй муйы – җәй буе, қорман – корбан, нирмы – нервы, минаwат – виноват, митамин – витамин.*

Нагайбәк сөйләше иренирен, өрелмәле **[w]** тартыгын куллану буенча да урта диалект системасында ныклы урын алып тора. Артикуляцион һәм акустик сыйфатлары ягыннан әдәби телдән аерылмый. Сүзнең барлык позицияләрендә килә ала: *wақ, wалчық, аwыл, таwық, саwыт, мал-туwар, йаwа.*

**[w] ~ [б]:** *бағыт – вакыт, бәгдә – вәгъдә.*

Нагайбәк татарлары сөйләшендә бу күренешнең киресе дә бар, ягъни [б] тартыгы [w] авазына күчә. Урта диалект сөйләшләренә хас булганча, -ып/-еп формалы хәл фигыльләр нигезендәге яңгырау [б] тартыгы иренирен яңгырау [w] авазы белән алмаштырыла: *таwып – табып, қаwып – кабып, чаwылып – чабып, иаwып – ябып* һ.б.

Күрсәтелгән шартларда [б] авазын [w] тартыгы белән тәңгәлләштерү кыпчак телләре өчен хас.

**[ф] ~ [п].** Татар сөйләшләренә [ф] авазы хәзерге көндә дә тулысынча үзләштерелеп бетмәгән. Бу сөйләштә дә татар әдәби телендәге ирен-ирен, рус һәм интернациональ телләрдәге ирентеш өрелмәле [ф] авазы [Современный татарский ..., 1969, с. 90] йомык [п] тартыгы белән алмаштырыла: *пайда – файда, паный дөнҗа – фани дөнья, Упа – Уфа, нәпес – нәфес, җепәк – ефәк, тупрақ – туфрак, сыпат – сыйфат, заип – зәгыйфь, пәлән – фәлән, Марпа – Марфа, Пидыр – Федор, патир – фатир, пасун – фасон, пирме – ферма* һ.б.

**[ч] ~ [с].** Берничә сүздә генә әдәби телдәге [ч] тартыгы урынына [с] тартык авазын куллану бар: *сийа – чия, сит кеше – чит кеше, атас – әтәч.*

Бу күренешнең аерым очраклары минзәлә сөйләшендә дә теркәлгән [Рамазанова, 1984, с. 89].

Рус теле алынмаларында исә, киресенчә, [с] тартыгын [ч] авазы белән алмаштырып сөйләү

үзенчәлекле: *әчтинә – стена, начылай – насилу, анүч – анис, Нәчти – Настя, Мәкчем – Максим, Ычтапан – Степан, Бәчүк – Василий, Күчти – Костя* һ. б.

**[т] ~ [д].** Түбәндәге сүзләрдә саңгырау [т] тартыгы яңгырау [д] авазы белән алмаштырыла: *дән – тән, дигәнәк – тигәнәк, дары – тары, дөркем – төркем.*

**[к] ~ [г], [қ] ~ [ғ]:** *бағыт – бәхет, игенче – икенче, тығырық – тыкрык, гәрәз – кәрәз.*

Урта диалектның тау ягы, норлат-кайбыч, бәрәңге, минзәлә, казан арты һәм тау ягы керәшеннәре сөйләшләрендәге кебек, билгеле бер төркем сүзләрдәге ирен-ирен яңгырау [м] сонантына тел очы яңгырау [н] сонанты туры килә: *җаwын – явым, ағын сыу – агым су, қаwын – кавын (Апылы башқаның қаwыны башқа –* мәкаль).

Әдәби телдәге *чорнау, тырнау, җилен* сүзләрендә, киресенчә, тел очы [н] тартыгы иренирен [м] авазы белән тәңгәлләшә: *чормау, тырмау, җилем.*

**[ң] ~ [н].** Чибәркүл районындагы нагайбәкләр сөйләшендә тирән тел арты һәм тел арты [ң] авазы гомумән кулланылмый, ул барлык позицияләрдә дә тел очы [н] авазы белән алмаштырыла: *мен – мең, тан ата – таң ата, анышыу – аңлашу, сун – соң, уна – уңа, туна – туңа, күнелле – күңелле, сезнен – сезнең, безнен – безнең, анын – аның, кешенен – кешенең, беләсенме – беләсеңме, күрәсенме – күрәсеңме* һ.б.

Фонетик үзенчәлекләрдән күренгәнчә, нагайбәк сөйләше татар теле диалектлары системасыннан читтә тормый. Күп кенә күренешләрдә ул бигрәк тә урта диалектның башка керәшен татарлары, казан арты, тау ягы, минзәлә, бере, пермь сөйләшләре белән зур уртаклык күрсәтә.

### Әдәбият

*Арсланов Л.Ш.* Говор мордвы-каратаев // Татар теле һәм әдәбияты мәсьәләләре. Труды Казанского государственного педагогического института. Казань, 1965.

*Баскаков Н.А.* Каракалпакский язык. Фонетика и морфология. Т. 2, ч. I. М.: Изд-во АН СССР, 1952.

*Баязитова Ф.С.* Говоры татар-кряшен в сравнительном освещении. М.: Наука, 1986.

*Богородицкий В.А.* Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками. Казань: Татгосиздат, 1934.

*Бурганова Н.Б.* Особенности говора татар нагорной стороны ТАССР // Материалы по татарской диалектологии. Казань, 1955.

*Бурганова Н.Б.* Говор каринских и глазовских татар // Материалы по татарской диалектологии. Казань, 1962.

*Дмитриев Н.К.* Грамматика башкирского языка. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1948.

*Киекбаев Ж.Г.* Башкорт теленең фонетикасы. Өфө, 1958.

*Махмутова Л.Т.* Описание грамматических особенностей касимовского говора татарского языка. // Известия Казанского филиала АН СССР. Серия гуман. наук. Вып. 1 Казань, 1955.

*Махмутова Л.Т.* Основные характерные черты мишарских говоров на территории Пензенской области // Материалы по татарской диалектологии. Казань, 1962.

*Рамазанова Д.Б.* Говоры татар Среднего Прикамья: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1969.

*Рамазанова Д.Б.* Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984.

*Рамазанова Д.Б.* К истории формирования говора пермских татар. Казань, 1996.

Современный татарский литературный язык. М.: Наука, 1969.

*Тумашева Д. Г.* Көнбатыш себер татарлары теле. Грамматик очерк һәм сүзлек. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1961.

*Тумашева Д.Г.* Язык сибирских татар. Казань: Изд-во Казанского ун-та, 1968.

*Хайрутдинова Т.Х.* Бирский говор среднего диалекта татарского языка // ИИДТЯ. Казань, 1983.

***Йосыпов Феритс Йосыф улы***
*филология фәннәре докторы, профессор*

УДК 811.512.145'282

***О.Р. Хисамов***

## БАРАБА ТАТАРЛАРЫН ӨЙРӘНҮ ТӘҖРИБӘСЕННӘН

В статье рассматриваются особенности барабинского диалекта татарского языка в контексте истории его формирования. В частности, анализируются вокализм и консонантизм диалекта.

**Ключевые слова**: барабинские татары, диалект барабинских татар, сибирские татары, история барабинских татар.

Фәнни әдәбиятта бараба татарлары Себер татарларының бер төркеме, Обь һәм Иртыш елгалары буенда яшәүче төрки телле җирле халык буларак күрсәтелә. Бүгенге көндә алар Новосибирск өлкәсенең Бараба, Венгер, Каргат, Куйбышев, Кыштау, Уба, Усть-Тар, Чаны районнарында көн күрәләр. Бу районнарның күбесе Бараба даласында, Новосибирск өлкәсенең көнбатыш өлешендә урнашкан. 2012 елның 23–26 нчы маенда Төркиядә (Әнкара шәһәрендә) телләре һәм мәдәниятләре юкка чыгу куркынычы астында торган халыкларга багышланган IV халыкара конференциядә татар теленең бараба диалекты югала баручы телләр исемлегенә кертелде.

2013 елның июнь аенда мәкаләнең авторы бараба татарлары яшәгән төбәккә оештырылган фәнни экспедициянең эшендә катнашты. Экспедициягә шулай ук филология фәннәре докторы, профессор Ф.Й. Йосыпов һәм филология фәннәре кандидаты И.Г. Гомәрев тә бардылар. Экспедиция төркеме Новосибирск өлкәсенең Чаны, Кыштау, Куйбышев, Венгер, Бараба районнарына караган Малый Чебис (Чортангүл), Белихта, Кошгүл, Аялу (Аялуцк), Тебис (Чүплегүл), Тармагуль (Унар), Воробьевка (Мангыт, Акбалык), Чаргары, Альменево (Тарлар), Усманка, Бергуль (Яргүл), Шагыр, Омаул (Осинцево), Тандов (Тамдау), Бакчагүл (Ново-Курупкаевка) авылларында эшләде. Нәтиҗәдә, зур күләмдә диалектологик, топонимик, фольклористик һәм этнографик материал тупланды.

Экспедиция нәтиҗәләре буенча 2013 елда Ф.Й. Йосыпов, Ф.С. Сәйфуллина, О.Р. Хисамов, И.Г. Гомәрев тарафыннан әзерләнгән «Барабинские татары. Страницы духовной культуры» дигән монография бастырылды (Казань, Издательство Казанского университета, 2013, 665 стр.). Әлеге хезмәттә барабалыларның тарихы, Новосибирск өлкәсенең төрки-татар топонимиясе турында фәнни мәгълүмат, халык авыз иҗаты үрнәкләре һәм кульязма материаллар урын алды.

1897 нче елгы Бөтенроссия һәм 1926 нчы елгы Бөтенсоюз халык исәбен алу материалларында барабалылар аерым этник төркем буларак аерып чыгарылган. Әлеге материалларда бараба татарларының саны 4443

һәм 7528 кеше дип билгеләнгән. 1970 нче елларның башларында бараба татарлары якынча 8,4 мең кеше исәпләнгән. Россия Фәннәр Академиясенең Себер бүлекчәсе филология институты мәгълүматларына караганда, 2012 елда Новосибирск өлкәсендә якынча 8000 бараба татары яшәгәнлеге мәгълүм.

Бараба татарларының төп шөгыле – аучылык, терлекчелек, балыкчылык була, игенчелек аларга соңрак керә [Дмитриева 1981, с. 9]. Бу шөгыльләрен алар хәзерге вакытта да ташлап бетермәгәннәр. Киресенчә, аучылык һәм балыкчылык бүген яңадан киң таралыш ала бара.

Бараба татарлары ислам динен тоталар. Аны бирегә бохаралылар һәм Казан татарлары алып килгән. Ислам динен кабул иткәнгә кадәр бараба татарлары, мәҗүсилектә булып, курчакларга табынганнар. Курчакларга корбан итеп мал чалуларын информантлар әле дә хәтерлиләр. 1920 елга кадәр бараба татарларында шаманнар булган һәм авыруларны алар да дәвалаганнар.

Россия Себерне яулап алганчы бараба татарлары Себер ханлыгына буйсынганнар һәм шул ук вакытта калмыкларга, казакъларга да ясак түләп торганнар. Бараба даласына руслар 1722 нче елда килеп төпләнә башлыйлар.

Бараба татарлары турында беренче тапкыр XVI гасырга караган язма чыганакларда искә алына. Г.Ф. Миллерның «Описание Сибирского царства и всех происшедших в нем дел» (1937) дигән хезмәтендә бу этник төркем турында кайбер мәгълүматлар китерелә. Сәяхәтче этнограф Иоганн-Готлиб Георги бараба татарларының 1776 һәм 1780 еллардагы тарихи этнографик белешмәсенең тулырак вариантын эшли. Ул барабалыларның яшәү рәвешләре һәм ышанулары буенча Алтай төркиләре белән уртак якларын билгеләп үтә (1799). XIX гасырда сәяхәтче-географ А.Ф. Миддендорф, Бараба даласын географик яктан тикшереп, бараба татарлары турында «тиздән бөтенләйгә юкка чыгачак халык» дигән нәтиҗә ясый (1871).

Бараба татарларының сөйләше татар теленең көнчыгыш (Себер) диалектына карый. Н.А. Баскаков үзенең генеалогик классификациясендә бараба-татар телен төрки халыкларның көнбатыш хун тармагының кыпчак-болгар группасына кертеп карый [Баскаков 1960, с. 159]. Күпчелек тикшеренүчеләр аны беравыздан татар теленең көнчыгыш диалектына кертәләр [Ахатов 1979, с. 80; Байчура 1962, с. 66; Каримуллин 1989, с. 128]. Бараба-татар сөйләшен мөстәкыйль тел дип исәпләүче галимнәр дә бар [Валеев 1980, с. 233; Валеев 1987, с. 35; Валеев 1993, с. 208]. Бараба сөйләшенең аерым үзенчәлекләре В.В. Радлов хезмәтләрендә яктыртылган. Ул үзенең классификациясендә бараба сөйләшен төрки халыкларның көнчыгыш группасына, себер татарлары тубыл-иртыш диалектының көнбатыш группасына кертә. В.В. Радлов фикерләренә диалектолог Г.Х. Әхәтов та кушыла. Бараба теленең төрки телләр гаиләсендәге үзенчәлекле урынына, аерымланган хәленә

К. Томсен да игътибар итә. А.П. Дульзон аның Себер татар диалектыннан аерылып торуын билгеләп үтә, ул бараба сөйләше белән чулым төрки телләре арасындагы уртак якларын таба.

Шулай да бараба татарларының теле үзенең үзенчәлекләре буенча кыпчак телләре төркеменә керә һәм татар теленең себер диалектына карый дип әйтү дөрес булыр. Анда Идел-Урал һәм казах-алтай группаларына караган телләрнең үзенчәлекләре саклана. Бараба диалектының тагын бер әһәмиятле ягы бар – ул үзендә борынгы төрки телнең төп үзенчәлекләрен саклап калган.

Бараба татарларының теле турында беренче фәнни мәгълүматлар XIX гасыр уртасы – XX гасыр башларында В.В. Радлов, Н.Ф. Катанов хезмәтләрендә күренә башлый. 1950, 1967, 1968 елларда Новосибирск өлкәсенең Бараба һәм Куйбышев районнарында танылган тел галиме Л.В. Дмитриева тикшеренүләр үткәрә. Ул бараба татарларының фольклорын һәм сөйләм теле үрнәкләрен язып ала. 1981 елда аның «Язык Барабинских татар» (1981) дигән монографиясе дөнья күрә. Бу хезмәттә бараба сөйләшендә язып алынган оригиналь текстлар, аларның тәрҗемәләре, сүзлек һәм грамматика буенча очерк урын алган.

1956–1964 елларда Д.Г. Тумашева җитәкчелегендәге диалектологик экспедиция төркеме Себер татарлары сөйләшләре буенча материаллар җыя. 1961 елда алар Новосибирск өлкәсенең Куйбышев, Бараба, Чаны районнарында эшлиләр. Төп игътибар халыкның сөйләм телен өйрәнүгә бирелә.

XXI гасырга кергәч, барабаларның компактлы яшәү урыннарына Новосибирск галимәсе Т.Р. Рыжикова тарафыннан да берничә экспедиция оештырыла. Галимәнең «Консонантизм языка барабинских татар. Сопоставительно-типологический аспект» (2005) исемле монографиясендә бараба диалектының консонантизм системасын эксперименталь тикшерү нәтиҗәләре чагылыш таба.

Югарыда искә алынган хезмәтләргә карамастан, бүгенге көнгә кадәр бу диалектның үзенчәлекләрен бөтен яктан да (фонетика системасы, грамматик төзелеш, лексик состав) ачып бирә алырлык фәнни хезмәтләр юк дисәк тә ялгышмабыз.

Соңгы елларда автор катнашында уздырылган экспедицияләр вакытында бараба диалекты фонетикасының түбәндәге үзенчәлекләре билгеләнде.

Бараба диалектының сузык авазлары түбәндәгеләр: [а], [ә], [е], [о], [ө], [ŏ], [ө] (редукцияләнгән аваз), [i], [ы], [и], [у], [ү]. Болардан [а], [е], [о], [ө], [ы], [и], [у], [ү] сузык авазлары – гомумтөрки чыгышлы, [ŏ], [ө], [i] – кыска, редукцияләнгән, тар әйтелешле авазлар, киң, ачык [а] сузыгы кулланыла. Бараба диалектының башлангыч вокализмы борынгы төрки телгә якын булган. Ә бүгенгесе исә, кайбер борынгы төрки үзенчәлекләрен саклаган хәлдә, казан-татар вокализмына якынайган. Бу әдәби телнең тәэсире белән бәйле. Сүзләрне әйткәндә, аларның төрле вариантлары

барлыкка килә, ә бу инде халыкара сөйләм теле – диалектның формалашу процессы тәмамланмавы турында сөйли. Бараба диалектының вокализмы белән казах теле вокализмы арасында да билгеле бер охшашлыклар бар [Тумашева 1977, с. 186].

Бараба диалектының алтай телләренә һәм борынгы төрки телләргә якынлыгын күрсәтүче тагын бер дәлил – диалектта озын сузыклар кулланылу. Сузык авазларның сузылышы аеруча беренче иҗектә очрый: *паарып* «барып», *қаапты* «капты» (балык турында), *оолы* «олы», *аачық* «ачык», *боолды* «булды» һ.б. Л.В. Дмитриева бу күренешкә мисалларның Куйбышев районы Шагыр авылында аеруча күп икәнлеген күрсәтә. [Дмитриева 1981, с. 202]. Безнең күзәтүләребез буенча мондый күренеш өлкәнең башка торак пунктларында да киң таралган. Бигрәк тә [а], [о], [ө], [ә] авазлары сузылып әйтелә. Дөрес, диалектта сузыкларның озынлыгы фонематик роль уйнамый. Комбинатор озынлыкка да мисаллар очрый: *таап/табып, цаап/чабып*.

Бу диалект өчен [ә], [е], [и] сузыкларын беренче иҗектә актив куллану хас: *әр/ир*, *йәр/җир*, *тәрәнә/тирән*, *тәмер/тимер*, *еү/өй*, *тәпсәү* «туй», *пәклиләр/бикләр*, *пәргән/биргән*, *мәгәләй / бияләй*, *кәрәк/кирәк*.

Диалектта киң сузыкларның тараю очракларына да мисаллар очрый: *сөйлир/сөйләр*, *йырлыр/җырлар*, *парайын/парыйн/барыйм*, *йәшип/йәшәп*, *уйлымаған/уйламаған*.

Д.Г. Тумашева [о], [ө] сузыклары, кагыйдә буларак, үзләреннән соң килүче сузыкларны иренләштермиләр, дип яза [Тумашева 1977, с. 192]. Безнең күзәтүләребез буенча диалектта ирен гармониясе бик эзлекле рәвештә үтәлә. Без шундый мисалларны теркәдек: *көйөп китте*, *көбөр* «мүк», *оло* «олы», *өйөк* «калкулык», *өргөн* «чытырманлык», *тоғоз* «тугыз», *тосторол ташлағаннар* «туздырып ташлаганнар», *йөстөрә* «юа» һ.б. Шуның өстенә [у], [ү], [о], [ө] ирен авазлары [а], [ә] сузыкларын да шактый иренләштерә.

Бараба татарлары диалектының вокализмына борынгы төрки телдән Идел буе татарларының вокализмына акрынлап күчә бару хас [Дмитриева 1981, с. 204].

Бараба татарларындагы сузык авазларны билгеләгәндә, В.В. Радлов аларны сүздә куллану урынына карап классификацияли. Анлаутта 7 саңгырау тартык очраша – [q], [k], [t], [p], [c], [s], [š]; [1] яңгырау – [d]; 1 ярымсузык – [j]; 4 сонор – [m], [r], [ŋ], [n]; инлаутта: [n], [ń], [l], [r], [j], [ŋ], [γ], [g], [d], [z], [ž], [ć], [b]; ауслаутта 7 саңгырау – [q], [k], [t], [p], [s], [š], [č] һәм 6 сонор тартык – [ŋ], [l], [r], [m], [n], [ń] [Radloff 1882, s. 128, 199, 173].

Д.Г. Тумашева диалектта 22 тартык аваз күрсәтә: [п], [б], [м], [т], [d], [н], [л], [ц], [с], [з], [ш], [ж], [р], [к], [г], [й], [ғ], [х], [ң], [w], [қ], [ч] [Тумашева 1977, с. 192].

Л.В. Дмитриева 25 тартыкны билгели, аларның 6 сы ирен авазлары – [п], [б], [в], [ф], [ў], [м]; 11 тел алды тартыгы – [т] ([д]), [с] ([з]), [ш] ([ж]), [ч], [ц], [н], [л], [р], [1]; тел уртасы – [й]; 2 тел

арты тартыгы – [к], [г]; 4 увуляр – [к], [ғ], [ң], [х]; 1 фарингаль тартык – [h] [Дмитриева 1981, с. 202].

Бараба татарлары диалекты консонантизмының характерлы үзенчәлеге – сүздәге [ц] тартыгының һәр позициядә дә килүе: *карцык* «карчык», *курцак* «курчак», *сәлгенцәк* «бишек», *цай* «чәй». Ләкин [ц] тартык авазын куллану барлык территориядә дә тигез түгел. Аваз башлыча көнчыгыш районнарда (Куйбышев, Бараба) кулланыла. Ә көнбатыш районнарда (Чаны, Венгер, Кыштау) [ц] тартык авазы урынына аффрикат [$ч^{т}$] кулланыла: *сауч*$^{т}$*ы/йаучы* «яучы», $ч^{т}$*ай* «чәй», $ч^{т}$*wә-*$ч^{т}$*әй* «чынаяк», *арч*$^{т}$*уыл* «яулык», *табақч*$^{т}$*а* «чәй тәлинкәсе». Без [ц] урынына [$ч^{т}$] кулланылу тубыл-иртыш диалектының тәвриз сөйләше йогынтысында барлыкка килгән үзенчәлек дигән фикердә торабыз. Аффрикат [$ч^{т}$], аффрикат [*ц*] һәм ярымсузык [*й*] белән беррәттән, гарәп-фарсы алынмасы [*дж*]/[ж]ны алмаштыра [Дмитриева 1981, с. 207], ягъни [*дҗ*]/[ж] тартыгы бу диалектта бөтенләй кулланылмый, дип әйтергә була.

Бараба диалектындагы тартыклар системасын билгеләүче төп закончалыкларның тагын берсе – яңгырау шаулы тартыкларның яңгырауларга караганда күбрәк кулланылуы. Төрки сүзләрдә [б], [д],[з], [ж], [ж] авазлары урынына системалы рәвештә саңгырау тартыклар кулланыла: [п], [т], [с], [ч], [ш]. Мәсәлән: *пәклиләр/бикличәр, паллар/балалар, қыстың туғаннары / кызның туганнары*.

Татар әдәби телендәге кебек үк [п], [к], ]к] тартыклары интервокаль позициядә яңгыраулашалар. Әлеге үзенчәлек сүз уртасында да очрарга мөмкин: *аба/апа*, *қурғып/қурқып*.

Йомгаклап әйткәндә, бараба диалектын бүгенге көндә бик төрле, катнаш дип ассызыкларга мөмкин. Бер үк сүзләр төрле авылларда төрлечә әйтеләләр. Бу, бер яктан, бараба татарларының диалекты, тел буларак, ахырына кадәр формалашып бетәргә өлгермәгәнлеген, ә икенче яктан, аның башка диалект һәм телләрнең көчле йогынтысын кичергәнлеген күрсәтә.

Әмма, югарыда билгеләп үтелгәнчә, авазлар системасындагы шактый зур вариативлылык безгә әлеге диалект составында аерым сөйләшләр һәм аларның ниндидер төркемнәрен аерып чыгарырга тиешле дәрәҗәдә нигез бирми.

**Әдәбият**


*Ахатов Г.Х.* Татарская диалектология. Средний диалект. Уфа, 1979. 80 с.

*Байчура У.Ш.* Звуковой строй татарского языка в связи с некоторыми другими тюркскими и финно-угорскими языками: автореф. дис. … д-ра филол. наук. М., 1962. 66 с.

*Баскаков Н.А.* Тюркские языки. М., 1960. 248 с.

*Валеев Ф.Т.* Западносибирские татары во второй половине XIX – начале XX веков (Историко-этнографические очерки). Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. 233 с.

*Валеев Ф.Т.* Сибирские татары (проблемы этнокультурного развития во второй половине XIX – начале XX вв.): автореф. дис. … д-ра ист. наук. М., 1987. 35 с.

*Валеев Ф.Т.* Сибирские татары: культура и быт. Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. 208 с.

*Георги И.Г.* Описание всех обитающих в Российском государстве народов, их житейских обрядов, обыкновений, одежд, жилищ, упражнений, забав, вероисповеданий и других достопамятностей. I-РУ. СПб., 1799.

*Дмитриева Л.В.* Язык барабинских татар. Л.: Наука, 1981. 224 с.

*Каримуллин А.Г.* Татары: этнос и этноним. Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. 128 с.

*Миддендорф А.Ф.* Бараба. «Приложение» № 2 к т. XIX «Записок Российской Академии наук». СПб., 1871.

*Миллер Г.Ф.* История Сибири. Т. I. М., 1937.

*Рыжикова Т.Р.* Консонантизм языка барабинских татар. Сопоставительно-типологический аспект. Новосибирск: СО РАН, 2005. 266 с.

*Тумашева Д.Г.* Диалекты сибирских татар. Опыт сравнительного исследования. Казань, 1977. 293 с.

*Radloff W.* Phonetik der Nördlichen Türksprachen. Leipzig, 1882. 319 s.

***Хисамов Олег Ришат улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фәнни эшләр буенча директор урынбасары*

УДК 811.512.145´35

***Р.Ф. Мирхәев***

# ТАТАР ЯЗУЫ ТАРИХЫННАН

История письменности татарского народа уходит в глубь веков. На протяжении всей этой истории татары и их предки пользовались разными видами письменности. Статья посвящена краткому обзору истории развития татарской письменности и ее современного состояния.

**Ключевые слова:** древнетюркская руническая письменность, староуйгурская письменность, старотатарская письменность на основе арабской графики, татарская письменность на основе латиницы, татарская письменность на основе кириллицы.

Татар халкының язу тарихы бик борынгыдан килә. Галимнәр фикеренчә, татарларның ерак бабалары борынгы болгарларның VII–VIII гасырларда хәзерге Татарстан җирләренә күчеп утырганда ук инде үз алфавитлары булган. Бу алфавит фәнни әдәбиятта рун язуы дип йөртелә. Алга таба рун язуы гарәп графикасы белән алыштырыла. Алтын Урда дәүләте чорында билгеле бер даирәләрдә, гарәп язуы белән белән бергә, иске уйгыр язуы да кулланылган. Гарәп язуы татарларда мең ел буе гамәлдә булып, үзенең соңгы көннәрендә – XX гасыр башларында берничә мәртәбә үзгәртүләр кичерә. XX гасырның 20 нче елларында гарәп хәрефләре латин, ә берникадәр вакыттан соң ул кирилл язуы белән алыштырыла [Курбатов, б. 134]. Югарыда санап үтелгән язу төрләре һәм аларның үзенчәлекләре В. Томсен (1894), В. Радлов (1888, 1895), С.Е. Малов (1951, 1952, 1959), Г. Айдаров (1966, 1971), А.Н. Кононов (1980), Х.Р. Курбатов (1999), М.З. Зәкиев (2005), Ф.Ш. Нуриева (2007) һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә җентекле рәвештә өйрәнелгән. Бу мәкаләдә татар язуы тарихына һәм аның бүгенге торышына кыскача күзәтү ясау максат итеп куелды.

**Борынгы төрки рун язуы.** Фәндә борынгы төрки рун язуының барлыкка килү вакытын һәм географик яктан таралыш ареалын Үзәк Азиядәге борынгы төркиләрнең дәүләте (VI–X г.) белән бәйләп карыйлар. Шул ук вакытта әлеге язуның күпкә иртәрәк барлыкка килүе турында да фикерләр әйтелә [Кононов, с. 7].

Себер һәм Үзәк Азиядәге борынгы төрки язма истәлекләре турында беренче хәбәрләр XVII гасыр ахыры – XVIII гасыр башларында барлыкка килә. Алардагы тамгаларның Европа галимнәренә күптәннән таныш булган Гот һәм Скандинавия руналарына (*run* сүзе борынгы Скандинавия халыклары телендә «сер», «серле» дигән мәгънәгә туры килә) охшашлыгы фәнни әдәбиятта «борынгы төрки рун язуы» терминының барлыкка килүенә китерә [Малов, с. 11–12].

Әлеге язуның килеп чыгышын галимнәр төрлечә аңлата. Бер төркем галимнәр борынгы төрки рун язуы пиктографик билгеләрдән барлыкка килгән дип саныйлар. Алар, мондый билгеләргә үрнәк итеп, күчмә төрки кабиләләрдә билгеле бер ыруга, яисә нәселгә беркетелгән һәм буыннан буынга, атадан улга тапшырылып килгән тамгаларны китерәләр. Ләкин күпчелек галимнәр рун язуын төркиләр үзләренең күршеләре сәгъдиләрдән кабул иткәннәр һәм ул үзенең тамырлары белән Якын Көнчыгышка барып тоташа дигән фикердә торалар [Кононов, с. 23].

Борынгы төрки рун алфавиты морфонологик нигезгә корылган язу төре санала һәм ул фонемаларны түгел, ә аларның дифференциаль билгеләр системасын чагылдыра, ягъни руналар борынгы төрки телнең тартык фонемаларын түгел, ә бәлки аларның калын һәм нечкә сузыклар янында кулланылган комбинатор вариантларын билдергәннәр. Сузыклар күпчелек очракта язуда күрсәтелмәгән. Шул сәбәпле рун язулы текстларны хәрефләп, яисә иҗекләп укып булмый. Моның өчен һәрбер сүзне борынгы төрки телдәге сузык һәм тартык авазлар гармониясе яссылыгында тулаем күзаллау сорала [Кононов, с. 5759].

VIII–X гасырларда рун язуы хәзерге Монголия, Көньяк Себер, Көнчыгыш Төркестан, Урта Азия, Казахстан, Идел буе, Төньяк Кавказ һәм Көнчыгыш Европа җирләрендә көн күргән төрки кабиләләр тарафыннан кулланылган. Идел-Урал буйларына ул борынгы төрки-болгар кабиләләре белән бергә үтеп кергән дип санала. Аның бу җирләрдә кулланылганлыгын археологик материаллар дәлилли. Хәзерге көндә фәндә бу территориядә табылган унбер рун язулы табылдык билгеле. [Курбатов, б. 13–31]. Алга таба рун язуын кулланылыштан гарәп алфавиты кысрыклап чыгара.

**Иске уйгыр язуы.** Уйгырлар – Үзәк Азиядә яшәүче борынгы халыкларның берсе. VIII–IX гасырларда алар үзләренең беренче дәүләтләрен төзиләр, соңрак Караханлылар (IX–XIII гг.), Алтын Урда (XIII–XV гг.) дәүләтләренең идарә һәм мәгариф эшләрендә мөһим роль уйныйлар.

Галимнәр фикеренчә, уйгырлар тарафыннан барлыкка китерелгән алфавит үзенең тамырлары белән борынгы сәгъди язуына барып тоташа, ләкин аннан аермалы буларак, уйгыр текстлары уңнан сулга түгел, ә өстән аска язылганнар. Сәгъди алфавитындагы кебек үк, иске уйгыр язуындагы күпчелек хәрефләрнең формасы аларның сүздә кайсы урында (башта, уртада һәм ахырда) килүенә бәйле рәвештә үзгәргән [Малов, с. 105–106].

Уйгыр язуы Идел-Урал төбәгендә яшәгән төрки халыклар тарафыннан да кулланылган. Аерым алганда, Алтын Урда чорында хан сараенда уйгыр хәрефләре белән рәсми документлар һәм хатлар төзелгән. Мәсәлән, безнең көннәргә кадәр Алтын Урда ханнары Туктамыш һәм Тимер Котлыгның ярлыклары килеп җиткән, ягъни хәзерге татарларның борынгы бабаларында уйгыр

язуының кулланылышта булганлыгы тарихи документлар белән раслана [Курбатов, б. 13].

**Гарәп графикасы нигезендә иске татар язуы.** Гарәп алфавиты хәзерге Казан татарларының бабалары саналган Идел болгарлары тарафыннан IX гасырда Ислам дине белән бергә кабул ителә. Шулай ук бу язуның аннан элегрәк – фарсылар аркылы сәүдә мөнәсәбәтләре нәтиҗәсендә килеп кергәнен әйтүчеләр дә бар [Курбатов, б. 33].

28 хәрефтән торган гарәп алфавитында 25 хәреф тартык, 3 хәреф сузык авазларны белдерә. Хәреф өстенә яисә астына куелган өстәмә билгеләр (хәрәкәләр) ярдәмендә кыска сузыклар күрсәтелә. Хәрефләр, аерым, сүз башында, сүз уртасында һәм сүз ахырында килүләренә карап, ике яисә дүрт шәкелдә уңнан сулга язылганнар. Эчтәлеге, язылу максаты, язу материалы һәм язучының зәвыгына бәйле рәвештә, гарәп графикасындагы текстлар төрле стильләрдә (куфи, нәсех, сөлс, тәгълик һ.б.) эшләнгән.

Гарәп язуын татарлар рәсми эш кәгазьләрендә һәм әдәби әсәрләр иҗат иткәндә файдаланганнар. Алда әйтеп үткәнчә, XIII–XIV гасырларда Алтын Урда дәүләтендә кайбер мөһим актларны теркәү өчен уйгыр алфавиты да кулланылган, ләкин алга таба ул рәсми статуска ия булган гарәп язуы белән алыштырыла. XVI гасырның урталарыннан соң, Казан ханлыгы җимерелгәч, рәсми статусын югалткан гарәп язуы бары тик дин, мәгариф, әдәбият һәм фән өлкәләрендә генә кулланыла.

Фонетик һәм грамматик төзелеше ягыннан бөтенләй башка системадагы телгә – төрки телгә килеп кергән гарәп язуы татарлар тарафыннан, аерым хәрефләр өстәүне исәпкә алмаганда, XIX гасыр ахырларына кадәр бернинди үзгәртүләрсез диярлек кулланыла. Тарихка ул «Иске имля» («Иске орфография») исеме белән кереп калган.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башларында татарлар арасында имля төзәтү хәрәкәте көчәя. Бу вакытта әлифба китапларына татар теленең моңарчы язуда чагылыш тапмаган сузык авазлары өчен өстәмә хәрефләр кертелә башлый.

1899 елда Уфа шәһәрендә алфавит һәм орфография мәсьәләләренә багышланган беренче конференция үтә. Анда яңа чор мәктәпләре өчен программалар төзү һәм имля берләштерү турында карар кабул ителә [Курбатов, б. 43].

Октябрь революциясеннән соң имля мәсьәләсе дәүләт дәрәҗәсенә күтәрелә: 1920 елның 19 декабрендә ТАССР Халык Комиссарлары Советы карары нигезендә татар телендә гарәп язуын куллануга үзгәрешләр кертелә. Үзгәртелгән алфавит «Яңа имля» («Яңа орфография») дип атала башлый һәм ул татар телендә латин графикасын кабул иткәнгә кадәр (1927) кулланылышта була.

**Латин графикасы нигезендә татар язуы («Яңалиф»).** Гарәп хәрефләренең төрки телләрнең фонетик үзенчәлекләрен язуда тулысынча чагылдыра алмавы һәм аны башка алфавит белән алыштырырга кирәклеге

турындагы фикерне төрки зыялылары арасында беренчеләрдән булып XIX йөз урталарында бөек азәрбайҗан язучысы һәм драматургы Мирза Фатали Ахундов күтәреп чыга. Татарларда латинчылык хәрәкәтенең башында шагыйрь Сәгыйть Рәмиев торган. 1908–1909 елларда ул үзенең әсәрләрен латин хәрефләрен кулланып яза башлый һәм әлеге графика нигезендә татар теле өчен алфавит проектын төзи, ләкин бу чорда ул киң җәмәгатьчелектә яклау тапмый [Курбатов, б. 74].

1920 елда Казанда татар-башкорт журналистлары конференциясе үтә. Конференциядә имля-хәреф мәсьәләләре турында да сүз кузгала, гарәп хәрефләрен бер шәкелгә калдыру белән генә тынычланмаска, латин алфавитына күчәргә кирәклеге әйтелә. Алга таба 1924 елда Мәскәүдә төрле төрки халыкларның вәкилләре катнашлыгында яңалиф комитеты төзелә. Комитет латин хәрефләре нигезендә алфавит проекты хәзерли һәм әлеге проект «Татар-башкорт телендә яңа әлифба» исеме астында матбугатта да басылып чыга [Курбатов, б. 76, 79].

Латин мәсьәләсе 1926 елда Бакуда булып үткән Беренче Тюркология съездында да күтәрелә һәм яңа алфавитның төрки телләр өчен һәрьяклап уңай икәнлеге билгеләп үтелә. Съезддан соң Казанда «Яңалиф» җәмгыяте оештырыла. Җәмгыять яңа алфавит һәм орфография проектын төзи һәм шул проект нигезендә әлифба китабы, махсус брошюралар бастырып тарата. Яңа алфавитны халыкка җиткерүдә 1927 елда чыга башлаган «Яңалиф» журналы да зур роль уйный [Курбатов, б. 81–82].

1927 елның июнь башларында Бакуда төрки алфавитларны берләштерү (унификацияләү) буенча махсус конференция үткәрелә. Конференциядә Татарстан алфавиты проектына зур гына үзгәрешләр кертелә, кайбер хәрефләр яңалары белән алыштырыла. Нәтиҗәдә латин алфавиты түбәндәге рәвешкә керә: Aa Вв Cc Çç Dd Ee Әә Ff Gg Ƣƣ Hh Ii Jj Kk Ll Mm Nn Ŋŋ Oo Өө Pp Qq Rr Ss Şş Yy Tt Uu Vv Xx Zz Ƶƶ Ьь Ƅj ƅj [Курбатов, б. 88–90].

1927 елның 3 июлендә ТАССР Халык Комиссарлары Советы үзенең махсус карары белән латин алфавитын татар теленең рәсми алфавиты, дип игълан итә. Барлык мәктәп, матбугат һәм нәшрият 1930 елның 1 гыйнварена тулысынча яңалифкә күчеп бетә [Курбатов, б. 85, 100].

Яңалифкә соңгы өстәмәләр 1928 елда кертелә. Шуннан соң ул, кирилл графикасы нигезендә яңа алфавит кабул ителгәнгә кадәр, 12 ел кулланылышта була.

1990 елларда Татарстанда латинга күчү мәсьәләсе яңадан күтәрелә. Күпсанлы бәхәсләрдән соң, 1999 елда татар алфавитының латин графикасы нигезендә яңа варианты кабул ителә, ләкин 2002 елда Дәүләт Думасы тарафыннан Россия Федерациясе территориясендә кириллицадан кала башка язу системасына нигезләнгән алфавитларны рәсми рәвештә куллануны тыя торган канун кабул ителә.

**Кирилл графикасы нигезендә татар язуы.** Татар теле

авазларын язуда кирилл графикасы ярдәмендә бирүнең беренче тәҗрибәләре XIX гасыр урталарына карый. Бу чорда профессор Н.И. Ильминский үзенең фикердәшләре белән татар теле өчен кирилл графикасы нигезендә беренче алфавитны төзи. Ләкин әлеге эшнең асылында мөселман халыклары арасында христиан динен тарату омтылышы ятканлыктан, татарлар аны кулланудан баш тартканнар һәм ул керәшен татарлары арасында гына таралыш ала [Курбатов, б. 107, 108].

Кирилл графикасына күчү мәсьәләсе татарлар арасында XX гасырның утызынчы еллары ахырында күтәрелә һәм аның кирәклеге рус теленнән яңа кергән сүзләрне аның үзендәгечә язарга, рус һәм татар телләрен өйрәнгәндә төрле язу системаларын үзләштерүдән котылырга мөмкинлек бирү белән аңлатыла.

Кирилл графикасы нигезендә яңа татар алфавитының беренче проекты 1938 елның августында игълан ителә. Анда татар теленең үзенчәлекле авазлары өчен бернинди дә өстәмә хәрефләр алынмый. Алар язуда кирилл хәрефләре һәм *ъ, ь* билгеләреннән торган диграфлар, яисә рус телендәге охшаш яңгырашлы авазларны белдерүче хәрефләр белән бирелергә тиеш булганнар. Мәсәлән, *әни, үс, үсү, үсә, тәрәзә, өчен* сүзләрен *аьни, усь, усю, уся, тярязя, оьчен* рәвешендә язарга тәкъдим ителә. Проект җәмәгатьчелекне канәгатьләндерми һәм ул кире кагыла [Курбатов, б. 108–112]. Шуннан соң алфавитка татар теленең үз авазлары өчен *ә, ө, ү, җ, ң, һ* хәрефләре өстәлә. Яңа алфавит һәм орфография 1939 елның 5 маенда рәсми рәвештә гамәлгә куела [Курбатов, б. 113]. Кулланылыш барышында кертелгән кайбер орфографик аныклаулар 1941 елның 10 гыйнварында раслана [Курбатов, б. 116]. Татар язуын камилләштерү омтылышлары 1950 елларда да дәвам итә. Аерым алганда, татар теленең [қ], [ғ] һәм [w] авазларын язуда бирү өчен, алфавитка Ққ, Ғғ, Ўў хәрефләрен өстәргә тәкъдим ителә. 1955 елда яңа орфография проекты төзелә. Ул 1958 елда киң җәмәгатьчелек игътибарына тәкъдим ителә, ләкин хөкүмәт комиссиясе аны, җитешсезлекләре булу сәбәпле, гамәлгә ашырырлык дип тапмый [Курбатов, б. 132–133]. Әлеге мәсьәләгә кабат 1980 елларда әйләнеп кайтыла. 1989 елда ТАССР Югары Советы Президиумы указы белән татар алфавитына [қ], [ғ] һәм [w] авазлары өчен өстәмә хәрефләр кертелә, әмма җәмәгатьчелек арасында бу юлы «Яңалиф»кә кайту омтылышлары көчәйгән була.

Кирилл нигезендәге татар алфавитына соңгы үзгәрешләр 1997 елның гыйнварында кертелә. Нәтиҗәдә ул түбәндәге рәвешкә керә: Аа Әә Бб Вв Гг Дд Ее Ёё Жж Җҗ Зз Ии Йй Кк Лл Мм Нн Ңң Оо Өө Пп Рр Сс Тт Уу Үү Фф Хх Һһ Цц Чч Шш Щщ ъ Ыы ь Ээ Юю Яя.

Югарыда әйтелгәннәрдән күренгәнчә, татар язуы үзенең ике мең еллык тарихы дәвамында һәм аеруча соңгы дәвердә күп санлы үзгәреш-яңартулар кичергән. Галимнәр фикеренчә, алар язылыш белән әйтелеш арасындагы

аерымлыкларны мөмкин кадәр бетерү, дөрес язу кагыйдәләрен фәнни нигезгә салу һәм камилләштерүне күздә тотып тормышка ашырылган [Курбатов, б. 134]. Шуңа да карамастан, татар язуы белән бәйле бәхәсләр җәмгыятьтә әле бүген дә дәвам итә.

**Әдәбият**


*Кононов А.Н.* Грамматика языка тюркских рунических памятников VII–IX вв. Л.: Наука, 1980. 255 с.

*Курбатов Х.Р.* Татар әдәби теленең алфавит һәм орфография тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 139 б.

*Малов С.Е.* Памятники древнетюркской письменности. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1951. 451 с.



***Мирхаев Рифат Фирдинат улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145´373

***М.З. Вәлиева***

# ЛЕКСИК-СЕМАНТИК КАТЕГОРИЯЛӘРНЕ ИСКЕ ТАТАР ЯЗМА ЧЫГАНАКЛАРЫ НИГЕЗЕНДӘ ӨЙРӘНҮ

В статье рассматривается история изучения лексико-семантических категорий на основе старотатарских письменных текстов. При изучении данного вопроса ученые обращают внимание на функционально-стилистические особенности употребления многозначных слов, антонимов и синонимов в указанных выше источниках.

**Ключевые слова:** лексико-семантические категории, полисемия, синонимия, антонимия, старотатарские письменные источники, диахронический аспект.

Татар тел белемендә лексик системаның төп категорияләреннән саналган полисемия, синонимия, антонимия, омонимия кебек күренешләр бүгенге көндә фәнни-теоретик яктан традицион формада чагыштырмача яхшы өйрәнелгән дип әйтергә була. Бирегә мисал итеп Ш.С. Ханбикова, Ф.С. Сафиуллина, К.С. Сабиров, В.Х. Хаков һ.б. хезмәтләрен китерергә мөмкин. И.Б. Бәширова хезмәтләрендә шушы проблемалар инвариант-парадигма нигезендә яңача системага салып бирелә. Татар телендә лексик-семантик категорияләрнең язма чыганаклар нигезендә тикшерелешенә килгәндә, өч төрле юнәлешне күрсәтү дөрес булыр:

1. Аерым бер чорда иҗат иткән әдипләрнең, шагыйрьләрнең әсәрләрендә, ягъни теге яки бу язма чыганакта кулланылган лексик-семантик категорияләрне тикшерү. Язма чыганакларның тел үзенчәлекләрен тикшерүне максат итеп куйган галимнәрнең барысы да диярлек лексик-семантик категорияләргә туктталалар. Бер төркем галимнәр аларны махсус алып тикшерсә, кайберләре санап китү белән генә чикләнә. Мәсәлән, Х. Кузьмина Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә кулланылган күп мәгънәле сүзләрнең, антоним һәм синонимнарның стилистик функцияләрен максатчан рәвештә ачыклый, аларның тематик яктан күп кенә төрләрен күрсәтә [Кузьмина, с. 64–77].

Алтын Урда чоры ядкәрләреннән Мәхмүд бине Гали әл-Болгариның «Нәһҗел фәрадис» әсәрен тикшергән Ф.Ш. Нуриева үзенең «Лексические варианты “Нахдж ал-фарадис”» дигән мәкаләсендә әлеге язма истәлектә мәгънәләре ягыннан бер-берсенә туры килә торган берәмлекләрнең, ягъни лексик вариантларның шактый еш очравын искәртә. Галим лексик вариантлар арасында төрки-татар сүзләреннән генә торганнары да (қул – әлик «кул», қудуқ – күтәрдик «кудык» һ.б.), алынма берәмлекләрдән

булганнары (җәмиғ (г.) – җүмлә (ф.) «барысы да» һ.б.) күзәтелүен искәртә [Нуриева, 1986, с. 127–132].

Ф.Ш. Нуриева үзенең башка хезмәтләрендә «сәнгатьле сурәтләү чаралары» дип, синоним, антонимнарның әсәрдә кулланылу үзенчәлекләренә туктала, шул исәптән, күп мәгънәле сүзләрне дә анализлый [Нуриева, 2004, с. 138–142].

Биредә тагын Ә. Алиеваның «Язык жанра “сәяхәтнамә”» хезмәтен телгә алырга кирәк. Автор сәяхәтнамәләрдә кулланылган тел берәмлекләрен анализлаганда, лексик синонимнарны күрсәтеп кенә калмый, аларны тематик һәм генетик яктан төркемләп тә бирә [Алиева, с. 538–540].

Г. Утыз-Имәни әсәрләренең тел үзенчәлекләрен тикшергәндә Р. Мөхәммәтрәхимова Утыз-Имәни иҗатында полисемия күренешенең киң кулланылуына игътибар итә, аларның күп төрләрен күрсәтә: «При изучении состава и роли этой группы слов проявился их полисемантизм, в связи с чем возникла необходимость установить, какие из смысловых оттенков или значений слов были типичны для татарского литературного языка конца XVIII – начала XIX века и какие из них являются продуктом индивидуального словоупотребления Г. Утыз-Имяни» [Мухаметрахимова, с. 545–560].

Ә. Хәлиуллина үзенең «Художественно-изобразительные средства в языке «Кысас Ал-Анбия Н. Рабгузи» мәкаләсендә, әдип кулланган чагыштыру һәм фразеологизмнар белән беррәттән, антонимнарны да анализлый. Автор аларны җөмләләр нигезендә карый һәм 1) контраст нигездә төзелгән җөмләләр, 2) образлы лексик антонимнар нигезендә төзелгән җөмләләр дип, ике төркемгә бүлеп өйрәнә [Халиуллина, с. 272–279].

Шулай ук язма чыганакларның теле тикшерелгән хезмәтләрдән Г.К. Закированың «Синонимы в языке тюрко-татарских письменных памятников периода Золотой Орды» (2009) хезмәте аерым игътибарга лаек. Автор шушы чорның язма чыганаклары Мәхмүд әл-Болгариның «Нәһҗел әл-Фарадис», Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан», Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Сәиф Сараиның «Гөлстан бит-төрки» әсәрләре нигезендә, Алтын Урда язма телендә кулланылган синонимнарны, тематик төркемнәргә бүлеп, җентекләп анализлый.

XIX гасыр башына караган язма чыганакларны тикшергән хезмәтләр арасыннан С.В. Григорьеваның «Словарь к хрестоматии Ибрагима Халфина (начало XIX в.)» дигән мәкаләсен атарга мөмкин. Автор И. Хәлфинның «Дастаннар мәҗмугасы» дигән хрестоматиясенә сүзлек буларак чыгарылган чыганакны тикшерә. Әлеге чыганакның авторы билгесез булуын да искәртергә кирәк. С.В. Григорьева, сүз төркемнәрен, аваз күчешләрен анализлау белән бергә, полисемия күренешенә дә туктала. Полисемик мәгънәгә ия булган сүзләрнең аеруча кызыклы булуын искәртә һәм мисалга түбәндәге сүзләрне китерә:

*төп*: 1) ‘төп’, 2) ‘тамыр, башлангыч’;

*күк*: 1) ‘күк йөзе, һава’, 2) ‘зәңгәр төс’;

*тақыр*: 1) ‘кипкән, корыган’, 2) ‘тигез’;

*кичермәк*: 1) ‘гафу итү’, 2) кич утыру;

*санамақ*: 1) ‘санау’, 2) ‘санлау, ягъни хөрмәт итү, фикерен исәпкә алу’;

*бенмәк*: 1) менү; 2) күтәрелү.

Шунысын да искәртергә кирәк, теге яки бу тарихи чорга караган язма чыганакларның телен тикшергәндә, авторлар күп очракта шул әсәрдә кулланылган тел берәмлекләрен тематик яктан төркемләп бирү белән генә чикләнәләр. И.Б. Бәширова үзенең хезмәтләрендә аерым бер чорда иҗат иткән шагыйрь-әдип кулланган лексик берәмлекләрне атау белән генә чикләнмичә, алар арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләрен, инвариантларын тикшерүгә зур игътибар бирә [Бәширова, 2006, б. 33–96, 124–133; 2010, б. 145–166, 214–227, 290–313 һ.б.]

Икенче юнәлеш – лексик-семантик категорияләрне чагыштырма планда тикшерү. Бу очракта аерым бер тарихи чорның язма истәлегендә кулланылган лексик-семантик категорияләр башка язма чыганаклардагы яки бүгенге әдәби телдә кулланылышта йөргән вариантлары белән бәйләп тикшерелә, яисә шул ук язма чыганакның төрле вариантларында кулланылган лексик-семантик категорияләр чагыштырыла. Мәсәлән, В.Х. Хаковның «Күп мәгънәле сүзләрнең һәм омонимнарның семантик-стилистик үзенчәлекләренә карата» мәкаләсендә бу төр сүзләрнең тарихи яктан үсеш кичерүләре күрсәтелә. Галим мисал итеп бүгенге көндә татар әдәби телендә кулланылган күп мәгънәле сүзләр белән омонимнарның үсеш үзенчәлеген XX йөз башында иҗат иткән әдипләрнең әсәрләреннән китерелгән мисаллар ярдәмендә дәлилли. Шулай ук Мәхмүд Кашгарый, В.В. Радлов һ.б. сүзлекләренә таянып эш итә. Мәсәлән, галим бүгенге көндә *тун, йорт* кебек сүзләрнең мәгънәсе тарайса, *сайлау, җәмгыять* кебек лексик берәмлекләрнең яңа мәгънә төсмерләре барлыкка килүен искәртә [Хаков, с. 3–19].

Я.С. Әхмәтгалиева «Кисекбаш» китабын тикшергән хезмәтендә (1979) берничә исемлектә кулланылган синонимнарны чагыштырып өйрәнә. Шулай ук хәзерге әдәби телдә кулланылган вариантларын да чагыштырма планда биреп бара һәм шушы әсәрдә кулланылган күп кенә лексик вариантларның бүгенге әдәби телдә дә кулланылышта йөрүен расларга тырыша.

XVII гасыр эш кәгазьләренең тел үзенчәлекләрен тикшергән А.Х. Зәйнуллина-Маннапова үзенең «О лексике деловых документов старотатарской письменности XVII века» мәкаләсендә бу чорда иске татар теленең үз сүзләре белән параллель рәвештә угыз, гарәп-фарсы, рус алынмаларының да кулланылуын искәртә. Мисалга *тылмач / тәрҗемән, күп / чук, илче / посланник* һ.б. сүзләрне китерә. Әмма ул әлеге мисалларны «синоним» яисә «лексик вариантлар» дигән терминнар белән атамый, бары тик аларның еш кына үзара янәшә кулланылуын искәртә.

Шуның белән бергә, автор эш кәгазьләрендә очрый торган кайбер лексик берәмлекләрнең бүгенге көндә бөтенләй дә кулланылмавын, ә кулланыла торган кайбер сүзләрнең мәгънәләре я тараюын яки, киресенчә, киңәюен дә ассызыклый. Мәсәлән, ул *хат* сүзенең XVII гасырга караган эш кәгазьләрендә ‘хат, грамота, дәфтәр / исемлек’, *хәзинә* сүзенең ‘байлык, бүләк’ кебек мәгънәләрне дә аңлатуын дәлилли. Хезмәттә кайбер сүзләр хәзерге әдәби телдә күзәтелмәсә дә, аларның диалектларда сакланып калуы күрсәтелеп бара [Зайнуллина-Маннапова, с. 27–34].

Лексик-семантик категорияләрне чагыштырып тикшерү Ә.Н. Нәҗип хезмәтләренә хас. Галим Сәйф Сараиның «Гөлстан бит төрки» әсәрен анализлаган хезмәтендә (1989) чыганакта чагылыш тапкан синонимия, полисемия күренешләрен аңлатып бара. Биредә ул әлеге әсәр белән генә чикләнеп калмыйча, теге яки бу лексик-семантик категориянең башка язма чыганакларда да, мәсәлән, Орхон-Енисей язмаларында М. Кашгарый һәм Ибн-Мөханна сүзлекләрендә, Рабгузый әсәрләрендә дә урын алуын искәртә [Наджип, с. 10].

Лексиканы шушы яссылыкта тикшерү Э.Х. Кадыйрова хезмәтләрендә дә киң яктыртыла. XVI гасыр шагыйре Мөхәммәдьяр әсәрләренең сүзлек байлыгын тикшергән хезмәтендә, галим, максат итеп куймаса да, аерым лексик берәмлекләрнең синонимик, омонимик вариантларын күрсәтеп бара, күп мәгънәле сүзләрне дә ачыклый. Чагыштыру өчен М. Кашгарый, Каюм Насыйри сүзлекләрен, диалекталь лексиканы файдалана [Кадирова, с. 31–126].

Лексик-семантик категорияләрне чагыштырма планда тикшерү И.Б. Бәширова хезмәтләрендә зур урын ала. Башкалардан аермалы буларак, галим теге бу лексик берәмлекне диахроник аспектта тикшерә, ягъни берәмлекнең чордан чорга мәгънәви яктан нинди үсеш-үзгәреш кичерүен иске татар язма чыганаклары мисалында аңлата [Бәширова, 2006, б. 148–183; 2010, б. 405–452]. Шул ук вакытта ул сүзнең когнитив-семантик төзелешен, алар арасындагы бәйләнеш-мөнәсәбәтләрне тикшерү барышында, лексик берәмлекләрнең төрле стильдә дә төрлечә кулланылуын чагыштырып анализлый [Бәширова, 2010, б. 212–226, 248–261). Гомумән алганда, И.Б. Бәширова хезмәтләрендә (2006, 2010) лексик-семантик категорияләр һәрвакыт төрле тарихи чорлар, язма чыганаклар, хәтта халык авыз иҗаты әсәрләреннән алынган мисаллар нигезендә чагыштырып өйрәнелә. Чөнки, галим фикеренчә, «...лексик-семантик категорияләрнең табигате һәм вазифасы да эзлекле рәвештә тарихи планда караганда-тикшергәндә генә объектив дәреслегендә ачылачак» [Бәширова, 2010, б. 261].

Өченче юнәлеш – тарихи сүзлекләрдә теркәлеп калган тел материалы белән эш итеп, лексик-семантик категорияләрне тикшерү. Бу очракта галимнәр, башлыча, аерым бер тарихи чорда төзелгән сүзлекләрдә

теркәлгән лексик материалны файдаланалар, шуның нигезендә лексик-семантик категорияләрне билгелиләр. Мәсәлән, «Каюм Насыйриның лексикографик эшчәнлеге» дигән хезмәтендә (2007) Г.Г. Батыршина галимнең «Ләһҗәи татар» сүзлегендә урын алган парлы сүзләр, фразеологизмнар, термин-атамаларны тикшерү белән беррәттән, аларның лексик вариантларын да күрсәтеп барырга тырыша. Аеруча фразеологик синонимнар һәм антонимнарны барлауга зур игътибар бирә.

Сүзлекләрдә теркәлгән тел материалы белән эш иткән галимнәрдән тагын Ә.Ш. Юсупова хезмәтләре игътибарга лаек. Ул XIX гасырның икенче яртысында дөнья күргән сүзлекләрдә урын алган диалекталь лексиканы тикшерә һәм байтак кына тел берәмлекләрен диалектлардагы бүгенге лексик вариантлары белән чагыштырып бирә. Мәсәлән, 1888 елда миссионерлар җәмгыяте төзегән «Краткий татарско-русский словарь с прибавлением с некоторых славянских слов с татарским переводом» (Казань, 4-е изд-е, 1888) сүзлегендә урын алган *рыскаллы* сүзенең бүгенге көндә дә диалектларда кулланылуын искәртеп, болай дип аңлата: «Рыскаллы бәхетле сүзенең синонимы. Рыскал – гарәп алынмасы. Хәзер бу сүз мишәр диалектының сергач сөйләшендә бар» [Юсупова, б. 304].

Күргәнебезчә, хәзерге татар тел белемендә лексик-семантик категорияләр, башлыча, аерым бер чор, аерым бер чыганак яисә берничә язма истәлек нигезендә тикшерелә. Аларны эзлекле рәвештә, диахроник үсештә карау бүгенге көндә өйрәнүне таләп итә торган актуаль мәсьәләләрнең берсе булып кала.

**Әдәбият**


*Алиева А.Х.* Язык жанра «сәяхәтнамә» // История татарского литературного языка. Казань: Фикер, 2003. С. 515–544.

*Ахметгалиева Я.С.* Исследование тюрко-язычного памятника «Кисекбаш китабы». М.: Наука, 1979. 191 с.

*Батыршина Г.* Каюм Насыйриның лексикографик эшчәнлеге. Казан, 2007. 191 б.

*Бәширова И.Б.* Хәзерге татар әдәби теле. Семасиология: Татар лексикасында системалы бәйләнеш-мөнәсәбәтләр. Казан, 2006. 192 б.

*Бәширова И.Б.* Татар әдәби теле. Семасиология. Казан, 2010. 532 б.

*Зайнуллина-Маннапова А.Х.* О лексике деловых документов старотатарской письменности XVII века // Истоки татарского литературного языка. Казань, 1988. С. 27–34.

*Закирова Г.К.* Синонимы в языке тюрко-татарских письменных памятников периода Золотой Орды. Казань: Казан. гос. тех. ун-т, 2009. 215 с.

*Кадирова Э.Х.* Поэмы Мухамедьяра «Тухва-и мардан» и «Нур-и содур»: лексика. Казань: Фикер, 2001. 230 с.

*Кузьмина Х.Х.* Лексика поэмы «Кысса-и Йусуф» Кул Гали. Казань: Дас, 2001. 104 с.

*Мухаметрахимова Р.* Язык произведений Г. Утыз-Имяни // История татарского литературного языка. Казань: Фикер, 2003. С. 544–562.

*Наджип Э.Н.* Тюркоязычный памятник XIV века «Гулистан Сейфа Сараи и его язык»: в 2 кн. Кн. 1. Алма-Ата: Наука, 1975. 210 с.

*Нуриева Ф.Ш.* Исторические и лингвистические условия формирования тюрко-татарского литературного языка золотоордынского периода. Казань: Казан. гос. ун-т, 2004. 376 с.

*Нуриева Ф.Ш.* Лексические варианты «Нахдж ал-фарадис» // Исследования по лексике и грамматике татарского языка. Казан, 1986. С. 127–132.

*Хаков В.Х.* К вопросу семантико-стилистических особенностей многозначных слов и омонимов // Исследования по татарскому языку. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1977. С. 3–19.

*Халиуллина А.* Художественно-изобразительные средства в языке «Кысас Ал-Анбия» Н. Рабгузи // Татар теле, әдәбияты, тарихы – үткәне һәм бүгенгесе. Казан: Казан дәүләт ун-ты, 2000. Б. 272–280.

*Юсупова Ә.Ш.* XIX гасырның II яртысында дөнья күргән сүзлекләрдә диалекталь лексиканың урыны // Татар теле, әдәбияты, тарихы – үткәне һәм бүгенгесе. Казан: Казан дәүләт ун-ты, 2000. Б. 304–310.

***Вәлиева Миләүшә Зәки кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика*
*бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.141

*Г.С. Кунафин*

# XIX ГАСЫР ӘДӘБИ «БАШКОРТ ҖЫРЫ» ЖАНРЫНЫҢ ИДЕЯ-ХУДОЖЕСТВО ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

В статье рассматриваются идейно-художественные особенности башкирской песни XIX века. Определяется роль песен в развитии национальной литературы башкирского народа.

**Ключевые слова:** песня, поэзия, традиции, народный фольклор, поэтика.

Милли сүз сәнгатендә китаби җыр лирикасы формалашу тарихын тикшерүчеләр билгеләп үткәнчә, әдәби «халык» җыры (әйтик, рус, татар, украин, казакъ, чуваш һ.б.) – кушылма (гибрид) әдәби жанр, ул аңлы рәвештә фольклорга нигезләнгән һәм китап поэзиясе белән халык сөйләм поэзиясе кушылудан барлыкка килгән. Бу жанрның фольклорга юнәлеш тотуы исеменнән үк аңлашыла [Русские..., с. 187–189; Позднеев, с.11; с. 26–27].

«Башкорт җыры» нәкъ шундый ук синкретик характерда. Анда авыз иҗаты традицияләре язма поэзия традицияләре белән кушыла (яраша). Әмма «башкорт җыры»нда фольклор традицияләренең өстенлек алуы күзгә ташлана. Моңа ачык дәлил – халык шигыре строфикасының С. Рыбаков белән М. Өметбаев тарафыннан кәгазьгә теркәлгән схема-модельләре (шаблоннары). Менә аларның берсе:

*Зайдый ғына микән, ай, айхайлүк, (10)*
*Айди ғына микән вайхайлүк. (9)*
*Зайдрай ғына микән зайдарайлүк, (10)*
*Зайдый ғына микән айхайлүк, (10)*
[Кунафин, с. 238]

М. Өметбаев үзенең мәхәббәт турындагы кайбер шигырьләрен («Һағыныу», «Һағыныу хаты») шушы схема буенча иҗат иткән.

Әдәби «башкорт җыры» нинди жанр үзенчәлекләренә ия?

«Башкорт җыры» бик катлаулы булмаган поэтик әсәрдән гыйбарәт булып, нигездә, мәхәббәт (сирәк кенә көнкүреш) темасына язылган, башкорт халык җырының аерым образларыннан, шигъри алымнарыннан һәм лексик әйләнмәләреннән төзелгән бер строфаны тәшкил итә. Моны ачыграк күзаллау өчен, Р.Г. Игнатьев тарафыннан тупланып, 1875 елда нәшер ителгән «Записки Оренбургского отдела императорского Русского географического общества» (вып. 3) басмасының «Сказаний, сказок и песен, сохранившихся в рукописях татарской письменности и устных пересказах у инородцев-магометан Оренбургской губернии» дигән өлешендәге мисаллар белән танышу да җитә. Җыентыкта, «Салават-батыр», «Алиш-батыр», «Бәхтияр-батыр» кебек тарихи сюжетка корылган героик эчтәлекле җырлар белән беррәттән, лирик характердагы җыр-шигырьләрнең дә берничә үрнәге («Парень и девушка»,

«Весенняя песня», «Где моя любимая», «Песня беркута») тәкъдим ителгән. Кызганычка каршы, текстта аларның шигъри нөсхәләре бирелмәгән. Р.Г. Игнатьев әсәрләрнең эчтәлеген чәчмә формада гына бәян итү белән чикләнгән, шуңа күрә аларның шигъри төзелеше үзенчәлекләрен күз алдына китереп булмый. Тел белгече А.И. Харисов фикеренчә, бу әсәрләрне «можно считать и народными... песнями, можно принять их и за стихи» [Харисов, с. 210]. Ә шушы өлкәне өйрәнүче С.А. Галин аларга фәкать фольклорчы күзлегеннән чыгып кына якын килә һәм алар турында, җитәрлек дәрәҗәдә нигезләми торып, халыкның лирик җыр үрнәкләре буларак кына яза [Галин, с. 14]. Чынлыкта исә, алар кушылма (катнаш, гибрид) характердагы әсәрләр, аларда поэзиянең китаби (язма) элементлары фольклорныкы белән кушыла; өстәвенә, үзара керешү процессында фольклор элементлары өстенлек ала. Р.Г. Игнатьев аларның кайберләрен юкка гына романтик эчтәлекле мәхәббәт җырлары дип атамый.

XIX гасыр башкорт поэзиясендә «башкорт җыры» жанры формалаша башлавын мәхәббәт һәм гаилә көнкүреше турында безнең көннәргә хәтле килеп ирешкән кульязма шигырьләр раслый. Аларның күбесенә төгәл строфик форма, халык лирикасында кулланыла торган параллелизм, кушымталар, төрки халыкларның мәхәббәт лирикасындагы традицион элементлар белән уртак рефреннар һәм төрле типтагы чагыштырулар, гадиләштерелгән рифма һ.б.ш. хас. Җыр шаукымы (стихиясе) китап поэзиясенә нигезләнгән, «җыр булмаган» әсәрләргә дә үтеп керә. Җыр бу чор хисси (үзара мөнәсәбәт) лирикасының төп жанры булып санала. Кечкенә бер мисалга тукталып үтик:

*Ҡашың ҡара сызылмышдыр,*
*Дәшең энже тезелмешдер.*
*Йөрәк-бәғрем өзөлмешдер*
*Ғишык тотып сәңа, эй жан.*

Югарыда мисалга китерелгән күп кенә җыр-шигырьләрнең идея эчтәлеге, романтизмның гносеологик алшарты буларак, чынбарлыкны интуитив танып белүгә нигезләнгән [Фохт, с. 78]. Аларда мәхәббәт ниндидер олы, гайре табигый һәм кешеләргә генә хас буларак карала. Лирик геройлар – бер-берсенә гашыйк булган яшь кешеләр бу хиснең көчен, үзенең сөйгәненең гүзәллеген идеаллаштыралар («Уктай керфекләре», «Синең зифа буең», «Гашыйклар бәете» һ.б.).

Бу очрак өчен «Гашыйклар бәете» аерым игътибарга лаек. Ул кыз белән егетнең кара-каршы сөйләшүе формасына корылган һәм читтән караганда, туй йоласы буенча, кәләш белән кияү мәнфәгатьләрен яклаучы кыз белән егетнең такмак-җыр ярышын хәтерләтә. Әмма шигырь эчтәлеге буенча да, функциясе буенча да йола җырларыннан кискен аерыла; анда төп геройлар ролендә үзара сүз көрәштерүче кызлар һәм егетләр төркеме түгел, ә гашыйклар үзләре – «роза» («гөлчәчәк») белән «сандугач» чыгыш ясый. Шунысы да мөһим, исеме билгесез шагыйрь үз әсәре

белән башкорт поэзиясенә яңа мотив – лирик «мин культы» урынына геройның сөйгәне хакына үз-үзен корбан итәргә әзер булуын, хисләр тирәнлеген поэтиклаштыруны кертә. Ул ике яшь кешенең рухи кичерешләрен, аларның ихлас хисләрен, шушы хакта сөйләшүләрен зур осталык белән, көчле яңгырашлы фразалардан һәм гиперболалардан тыш, күз яшьләренә чыланган сентиментальлектән башка гына, реализм рухында бәян итә:

*Егет әйтде:*
*– Өләң әйдеб башладым ғашик*
*җанға, яр, яр,*
*Ғашиҡмыз бу җиһанда ҡыз-угланға,*
*яр, яр.*
*Бу җиһанда туғдыңыз, булдыңыз,*
*яр, яр,*
*Телемездә тәсбих тик булдыңыз сез,*
*яр, яр.*
*– Йөрәгемә дәрт салдың шөйлә*
*егет, яр, яр,*
*Сән дигәндә, мән ҡабул идеб, егет,*
*яр, яр.*
*Ошбу дөнья дәүләте – сән, сән*
*бәнем, яр, яр,*
*Ғәян булыр бу эшне, булса әнкам,*
*яр, яр.*

Чагыштыру теленең гадилеге (кыз – роза, егет – сандугач); эпитетларның аныклыгы һәм төгәллеге («җан дус» – «яр, яр», «кара күзем», «шау чәчәкле бакча» һ.б.); күп кенә төрки халыкларның, аерым алганда, казакъ, үзбәк, башкорт һәм татарларның сөйләм поэзиясендә шактый киң таралган рефрен – «яр, яр» («йәр, йәр»); шартлы символик образларның һәм геройларны чолгап алган тирәлекнең шартлы элементлары булмау; көнкүреш детальләреннән (йорт, тәрәзә, сандык һ.б.) һәм сынамышлардан файдалану; һәр строфаның мәгънәви һәм төзелеше ягыннан бөтенлеге һәм, иң мөһиме, һәркемгә аңлаешлы эчтәлеге; тыңлаучыларны яки укучыларны геройларның кичерешләренә тартырдай ярыммоңсу һәм ярымшаян тон; үзең килеп эләккән тирәлекне, вәзгыятьне табигый кабул итү – барысы да саф әдәби калыпта язылган бу җырны халыкныкына якынайта. Исеме билгесез шагыйрь фразаларны җиңел бәйли, шигырь матур яңгырашлы, эчке кичерешләрнең тирәнлеген, геройларның эш-гамәлләрен, алар сөйләменең интонациясен дөрес тасвирлый. Табигыйлек, хәрәкәтчәнлек, психологик яктан төгәллек белән башкарылган бу диалогны үзендә катнашучы затларның характерларын чагылдырган кечкенә күләмле музыкаль-шигъри рухтагы драматик сәхнә әсәре дип санарга да булыр иде.

Мәхәббәт турындагы җырлар яңа заман һәвәскәр шагыйрьләрен һәм укучыларын кайсы ягы белән җәлеп итә соң? Мәхәббәт лирикасы кешегә үз хисләре белән көчлелеген, бөеклеген тоярга, анда шәхес хисе уятырга, үз-үзен расларга ярдәм итә. Җырда әйтелгәнчә, сөю-ярату – табигый кануннарга иярү дигән сүз. Мәхәббәт ул зур кодрәткә ия. Ул кешене бәхетле дә, бәхетсез дә итә ала, шатландыра яки моңсуландыра, шаштыра яки уйчанландыра, борынгыдан канунлашкан йолаларны, шәригать кушканнарны, аерым катлауларга хас карашларны, башкалар киңәшен кире кагарга этәрә, горурлык һәм төшенкелек хисләре уята:

*Аккош ла атдым, тимәде,*
*Аккошларым китде җелүгә.*
*Гакылсыз бала түгел идем,*
*Гакылларым китде сылуга.*

*Чакырым ярым әрәмә,*
*Әрәмәдән күрдем бән сәне.*

*Илгә чыккан даның белән,*
*Күрмәенчә сәүдем бән сәне*

[Научная..., с. 134]

Китерелгән өзектән аңлашылганча, исеме билгесез һәвәскәр шагыйрь гашыйк кешенең уйларын һәм хисләрен тасвирлауда аңлы рәвештә үз заманының халык җырлары поэзиясеннән файдаланган. Әсәр озын җырлар формасында язылган. Нигездә, ул милли халык җыры лирикасының һәм аның поэтикасын стильләштерүнең анык бер үрнәгенә ияреп иҗат ителгән. Өстәвенә, биредә фольклорның формаль үзенчәлекләре версияләштерү һәм композицияләрнең язма поэзия вәкилләре тарафыннан эшкәртелгән законнарына буйсындырылган. Әйтик, әсәрдә халык җыр лирикасына хас булганча эчтәлеккә эчкерсезлек, хисси һәм элегик төсмерләр өстәүче кечерәйтү-иркәләү суффикслары бөтенләй юк. Ул ритмитик яктан да аксый: ритмитик рәтләре бик күп төрле, шулай ук шигырьләрдәге иҗекләр саны да туры килми. Халкыбызның озын җырларында иҗекләр саны еш кына 10 (1 нче һәм 3 нче юлларда) һәм 9 (2 нче һәм 4 нче юлларда), аерым очракларда 11, хәтта 14 кә җитсә, әйтелгән әсәрдә 9 иҗекле юллар 8 һәм 7 иҗекле юллар белән чиратлаша. Шул ук вакытта аның поэтикасына халык поэзиясенең күп кенә стиль билгеләре дә хас. Анда тәфсилле (киңәйтелгән) сюжет юк, ул беренче зат тарафыннан бәян ителә, ягъни сюжеттагы вакыйгалар герой монологында ачыла.

Икебуынлы параллелизмнар мөһим композицион һәм хиссиэстетик әһәмияткә ия. Алар тискәре характерда һәм символик яктан бик әһәмиятле; җыр сюжетындагы хәл-вакыйгаларны читләтеп бирергә, аларга хисси төсмер өстәргә, геройның рухи халәтен чагылдырырга мөмкинлек тудыралар. Исеме билгесез шагыйрь, бер үк вакытта, халыкның гадәти көнкүреш күзаллаулары белән тыгыз бәйләнгән пейзаж образларына да мөрәҗәгать итә. Җаваплы һәм газаплы мәхәббәтнең нинди озын юл үтүе хакындагы хисләр җырны тыңлаучы яки укучының күңелен биләп алсын өчен, аңа әсәрнең беренче юлларында очып китүче аккошлар һәм чакрымнарга сузылган куаклыкларны искәртеп үтү дә җитә.

Халык җырлары лирикасының әйтеп үтелгән поэтик чаралары комплексын XIX гасыр әдәби җырларының күбесендә очратырга мөмкин. Кайбер шагыйрьләр алардан бик оста һәм мөстәкыйль файдалансалар, икенчеләре ниндидер шартлы үрнәкләргә ияреләр. Нәтиҗәдә, аларның күп кенә шигырь-җырлары фольклорны стильләштерүдә әдәби тәҗрибә булып кына кала. И. Покровскийның башкорт галим-энтузиасты Ю. Әминевтан (2 нче Усергенский волостенда) язып алган татар һәм башкорт җырлары [Покровский, 1870] – моның ачык

мисалы. Аларны әдәбият сөюче, Оренбург чик буе комиссиясе тылмачы С. Батыршин (үзе Стәрлетамак өязеннән) рус теленә тәрҗемә итә [Центральный..., 1754, оп. 1. Ед.хр.67]. «Сборник башкирских и татарских песен» тәүге башкорт галим-мәгърифәтчеләренең берсе – М. Биксурин редакциясендә «Записки Оренбургского отдела императорского Русского географического общества» (вып. 1) битләрендә 1870 елда дөнья күрә. Анда кертелгән әсәрләр эчтәлеге ягыннан да, шигъри формасы буенча да төрлелекләре белән аерылып торалар. Алар арасында ике, дүрт һәм алты юллы җыр-шигырьләр бар. Күбесе робагый формасында язылган. Мәснәви һәм газәл формасындагы строфалар да очрый. Мәхәббәт, тормыш-көнкүреш турындагы бу җыр-шигырьләрдә кешенең якты хисләре, дөньяви хыял-теләкләре, гакылы, мәгърифәтлелеге, тәрбиялелеге, гүзәллек идеалы җырлана; ялгызлык, ташлап киткән җан дусны сагынып искә алу, яратмаган кешене күрәлмау, туган җирне сагыну хисләре тасвирлана. Мәсәлән:

*Менгән атым туры ала, (а)*
*Тубылгыларг урала, (а)*
*Бән тыуып үскән ердә (б)*
*Күк үлән үсеп тә кыуара. (а)*

[Покровский, с 174–175]

Бу мисалдан күренгәнчә, И Покровский тарафыннан тупланып нәшер ителгән җыр-шигырьләрдә фольклор лирика белән язма поэзия традицияләре органик рәвештә бер-берсенә үрелеп бара. Аларның берсендә фольклор элементлары өстенлек итсә, икенчесендә китаби поэзия элементлары көчлерәк чагыла. Шуны да әйтергә кирәк, аларның күпчелеге тирән эчтәлеге, поэтик камиллеге белән аерылып тормый. Бу әсәрләрдә фольклор белән бәйләнеш ныклы иҗади характерда – халык шигъри сюжетын яки образларын үзенчә иркен тасвирлау характерында булмыйча, халкыбызның озын, кыска һәм бию җырларын имитацияләүгә, ягъни гап-гади ияргүгә, аларга охшатып язуга гына кайтып кала. Аларның сөйләм интонацияләрендә, еш кына, сизгерлек җитми, ритм төзеклеге аксый, агиографик әдәбиятка хас булган гарәп, фарсы сүзләре күп очрый. И. Покровский җыентыгы, башкорт җыр фольклорына юнәлеш тоту һәм аны төрлечә интерпретацияләү XIX гасыр башкорт поэзиясенең мөһим сыйфаты, дип әйтергә җирлек бирә. Шуңа күрә, «башкорт җыры»н башкорт поэтик фольклоризмының фәкать үзенчәлекле бер формасы гына, дип кабул итәргә була. «Башкорт җыры»ның жанр үзенчәлеге милли халык җыры лирикасының мәгълүм *үрнәкләренә аңлы рәвештә ияргүдән* һәм аның поэтикасын *стильләштерүдән*, кайвакытта – *имитацияләүдән* дә гыйбарәт.

Халык символикасы системасын үзләштерүгә омтылыш нигезендә барлыкка килгән әдәби «башкорт җырлары» һәм башкорт фольклор җырлары, бигрәк тә аның лирик төрләре структурасының композицион принциплары, билгеле бер әдәби житешсезлекләре булуга карамастан, милли әдәбият үсешендә уңай

роль уйныйлар. Алар башкорт поэзиясенә зур йогынты ясадылар, алга таба аңа халыкчанлык элементлары үтеп керүгә, чынбарлыкны образлы фикерләргә, образ-детальләрне һәм геройның эш-гамәлләре шартларын аныкларга ярдәм иттеләр. Романтик, дини-идеалистик юнәлешләргә нигезләнгән идея-эстетик агым өстенлеге көчле чорда да җыр үзенең рациональ башлангычын саклап кала, һәм ул шигърият жанрларыннан халык тормышына, реаль чынбарлыкка иң якыны, иң «кешелекле»се булып санала.

**Әдәбият**


*Галин С.А.* Песенная поэзия башкирского народа. Уфа, 1979.

*Кунафин Г.С.* Просветитель и писатель Мухаммметсалим Уметбаев. Уфа, 1991.

Научная библиотека АН РБ, рб – 3741.

Песни и романсы русских поэтов / вступ. статья, подг.текста и примечания В.Е. Гусева. М. – Л., 1963.

Песни русских поэтов / вступ. статья, подг. текста и примечания И.Н. Розанова. Л., 1950.

*Позднеев А.В.* Рукописные песенники XVII–XVIII вв. (Из истории песенной силлабической поэзии) // Ученые записки Московского государственного заочного пединститута. Т. I. М., 1974.

*Покровский И.П.* Сборник башкирских и татарских песен // Записки Оренбургского отдела императорского Русского географического общества. Казань, 1870.

Русские песни XIX века / составитель И.Н. Розанов. М., 1944.

Словарь литературоведческих терминов. М., 1974.

*Фохт У.Р.* Некоторые вопросы теории романтихма (Замечания и гипотезы) // Проблемы романтизма. М., 1967.

*Харисов А.И.* Литературное наследие башкирского народа. Уфа, 1973.

Центральный государственный военно-исторический архив, ф. 1754, оп. 1, ед. хр. 67, л. 16 обр. – 17.



***Кунафин Гыйниятулла Сафиулла улы,***
*филология фәннәре докторы, БР ФА мөхбир әгъзасы,*
*Башкорт дәүләт университеты профессоры*

УДК 821.512.122

***В.К. Калижанов***

## КАЗАКЪСТАН ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ БҮГЕНГЕ ЗАМАН

В статье рассказывается о поэтапном развитии казахской литературы, состоянии ее на современном этапе, взаимосвязях казахских поэтов и писателей с авторами литератур других народов. Также речь идет об изучении богатого наследия казахского народного творчества.

**Ключевые слова:** казахская литература, литературный процесс, толерантность, история, наследие, межнациональные связи.

Тугандаш казакъ һәм татар халкы тарихы уртак язмышка ия. Күп гасырлар дәвамында без рухи якынлыкта яшәдек, безне гореф-гадәтләребез һәм төрки тел чыганакларыбыз берләштерә. Ә Казан һәрвакыт мәгърифәтле казакълар күңеленә юл ачучы булды, казакъ милли нәшриятчылыгы башлангычы да шушы шәһәр белән бәйле. Галимнәребез фикеренчә, казакъча беренче басма китап «Кыйссаи Сәйфел-Мөлек» («Кисса-и Сефуль-Мулюк») 1807 елда Казанның «Азиат типографиясе»ндә нәшер ителде. Нәкъ менә шуннан соң, казакъ китаплары даими басыла башлады. Казакъларның революциягә кадәрге басма китапларының өчтән икесе (артыграк та әле) Казанда дөнья күрде.

Әдәбиятларыбызның үзара якынлыгы кардәш халыклар булуыбызда һәм фольклорыбызның аваздашлылыгында гына түгел, ә шагыйрьләребезнең, язучыларыбызның һәм мәгърифәтчеләребезнең иҗатында да якты чагылыш таба. М. Акмулла, Г. Тукай, М. Гафури, Г. Ибраһимов казакъ далаларында үз кешеләр булдылар. Акмулла Мөхәммәдьяров исә казакъ, татар һәм башкорт әдәбиятларының классигы. Ә шагыйрь Габдулла Тукай озак вакытлар Җаекта (Уральскида) яшәде һәм шагыйрь буларак ул шунда формалашты дисәк тә хата түгелдер. Казакъ җырлары аның үзенә бер шигъри мәктәп булды. XIX–XX гасырларда Казан университетында белем алган казакълар арасыннан бик күбесе язучылар, галимнәр, дәүләт эшлеклеләре булып күтәрелделәр.

Казакъ басма китапчылыгы һәм әдәбияты XX гасырда үзе дә зур-зур адымнар белән алга китте. Революциягә чаклы китапларыбыз, нигездә, Казакъстаннан читтә – Казанда, Оренбургта, Уфада, Ташкентта, Троицкида, Петербургта, Мәскәүдә, Әстерханда, Омскида басылып килсә, бүген инде Республикабызның зур үсешкә ия нәшрият базасы бар, һәм күпмилләтле казакъ әдәбияты дөнья киңлегенә чыкты.

Казакъ әдәбиятының чәчәк атуы Бәйсезлек чоры белән бәйле. Бу еллар әдәби процессның алга китүе өчен офыкларны киңәйтеп җибәрде, уңайлы шартлар тудырды һәм заманча милли үзаң

формалаштыруда әдәбиятның ролен һәм әһәмиятен ачыклады. Тарихи күзлектән чыгып фикер йөрткәндә, бу – зур срок түгел, әмма Бәйсез Казакъстан язмышы өчен ул гаять зур әһәмияткә ия. Бу чорда Казакъстан әдәбиятында һәм казакъ әдәбияты белемендә репрессияләнгән шагыйрьләрнең һәм язучыларның, Алаш эшлеклеләренең иҗади мирасы торгызылды. Казакъларның рухи-интеллектуаль элитасы «Милли бердәмлек идеясе»н күтәрде. Алихан Букейханов, Ахмет Байтурсынов, Бахтыйжан Каратаев, Халел һәм Джанша Досмохамедовлар кебек Мәскәү, Петербург, Варшава, Казан, Омск һәм Оренбург шәһәрләрендә югары һәм махсус урта уку йортларын тәмамлаган, үз өлкәсендә танылып өлгергән шәхесләребез Милли-азатлык хәрәкәтен җитәкләүгә алындылар. М.О. Ауэзов исемендәге Әдәбият һәм сәнгать институты Алаш хәрәкәтендә катнашуын, репрессиягә дучар ителгән әдәбият һәм мәдәният вәкилләре Ш. Кудайбердиев, М.Ж. Копеев, А. Байтурсынов, М. Дулатов, Г. Карашев, М. Жумабаев, С. Торайгыров, Ж. Аймауытов, С. Садуакасов һ.б.ны реабилитацияләү һәм алар калдырган иҗади мирасның академик басмаларын нәшер итү эшен башлап җибәрде. Иң элек М.О. Ауэзов әсәрләренең тулы академик басмасы (50 томда) һәм «Мохтар Ауэзов» энциклопедиясе нәшер ителде. 10 том булып «Казакъ әдәбияты тарихы», 8 томлы «Казакъ музыкасы антологиясе», 3 томда «Бөтендөнья фольклористикасы», шулай ук 3 томда «Бөтендөнья әдәбият белеме», 3 томлы «Казакъ сәнгате тарихы» басылып чыкты. «Бабалар сөзі» дигән исем астында казакъ фольклорының 100 томлыгы һәм «Әдәби һәйкәлләр» сериясеннән 20 томлык дөнья күрде.

Казакъстанда башка милләт вәкилләренең дә әдәбиятлары зур үсеш кичерә. Бу – Казакъстан Республикасы Президенты Н.А. Назарбаевның бу өлкәдә алып барган җитди сәясәте нәтиҗәсе. Казакъстанның бүгенге әдәби процессын шуннан башка күз алдына да китерү мөмкин түгел. Республикадагы милли әдәбиятлар эволюцион үсешләренең яңа баскычына күтәрелделәр. Рус, уйгыр, корд, алман, корея, татар әдәбиятларын соңгы 20 елда И. Щеголихин, В. Михайлов, С. Самади, Х. Абдуллин, Д. Ясенов, С. Маматкулов, М. Обылкасымов, Г. Бельгер, Г. Хаджисулейман, Б. Бал, С. Саяди, Н. Веревочкин, Л. Шашкова, Н. Чернова, Л. Сон, Л. Си, А. Кан, Ф. Байгельдинов һ.б.ның әсәрләре баетты. Яңа тарихның олы бер дәвергә хас вакыйгалары милли әдәбиятның йөзен үзгәртте, ул бүгенге чор әдәбиятының колачлы үсеше белән характерлана. Сәнгати фикерләү иреге, иҗади башлангычларга мөмкинлекләр киңәю чынбарлыкны барлык катлаулыгы белән гәүдәләндерергә юл ачты. Казакъстан матур әдәбиятында автобиографик юнәлеш көчле үсеш алды.

Республикабыз әдәби процессының үзенчәлекле күренеше – төрле телләрдә бәян итүче язучыларның һәм шагыйрьләрнең иҗатлары. Рус телле язучылар –

бу ике мәдәният һәм әдәбиятның тоташкан чигендә килеп туган киң әдәби агым. Алар прозасында һәм поэзиясендә милли, рухи башлангыч өстенлек ала. Алар барысы бергә, О. Сөләйманов сүзләре белән әйтсәк, – ике мәдәният арасындагы күпер һәм үзара йогынтыны көчәйтүчеләр. Алар иҗатының мөһим үзенчәлеге: кайсы да булса бер милли мәдәният һәм әдәбият кысаларыннан принципиаль рәвештә читкә чыгу. Шул ук вакытта милли язучылар һәм шагыйрьләр һәркайсы үз иҗатларында дөньяның үзе күзаллаган милли образын тудыра. Алар прозасында вакыйгалар, О. Сөләйманов фикеренчә, хисләр, идеяләр эволюциясен һәм геройларның кичерешләрен, эчке киеренкелеген гәүдәләндерә.

Казакъстанда татар әдәбиятын фәнни тикшеренү нәтиҗәләре, беренче мәртәбә, 2004 елда «Казакъстан халыклары әдәбияты» дигән коллектив монографиядә тәкъдим ителде. Авторлар Казакъстанда татар әдәбияты үсешенә үз өлешләрен керткән язучылардан Казакъстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзалары Сабир Шәрипов (1882–1942), Гайшә Шәрипова (1901–1969), Ибраһим Сәләхов (1911–1998), Әсхәдулла Хәмидуллин (1923–2001) иҗатларын анализладылар. Тикшеренүләрдән мәгълүм булганча, Казакъстан бәйсезлеге елларында татар әдәбияты поэзиясе, проза һәм публицистика өлкәләрендә динамик үсешкә ирешкән. Татар шигърияте һәм публицистикасы күтәрелүдә Гариф Тимерзаһит улы Хәйруллинның роле аерым игътибарга лаек. Ул «Казакъстан татарлары һәм башкортлары ассоциациясе»н җитәкли, «Фикер» газетасының баш редакторы. Тимер Заһит тәхәллүсе белән татар телендә шигырьләр иҗат итә. Соңгы ике дистә ел дәвамында аның шигырьләре белән уннан артык җыентык басылып чыкты. Ә 2011 елда Г.Т. Хәйруллинның Алматы шәһәрендә «Татары в Казахстане» дигән энциклопедик сүзлеге дөнья күрде.

Татар телендә үз җыентыкларын бастырып чыгарырга өлгергән татар шагыйрьләре Рөстәм Әбдессәләмов, Равил Гозәеров, Нәзилә Усманова Республикада зур популярлык яулаган затлар. Ә Казакъстанның рус телендә иҗат итүчеләре арасында шагыйрь, прозаик, эсселәр авторы Фәрит Байгельдинов зур танылуга ирешкән шәхес. Аның әсәрләре Республика журналларында һәм альманахларда басылып килә.

Фәрхәт Тамендаров та тәүге шигырьләре белән үк Казакъстанның әдәби даирәсендә уңай бәяләмәләр яулады. Казакъстан Язучылар берлеге әгъзасы, прозаик, шагыйрь, публицист Тәүфикъ Әкрам улы Кәримовның да матур әдәбиятка караган берничә китабы нәшер ителде. Т. Кәримов иҗтимагый эшчәнлектә дә актив катнаша, ул ике мәртәбә Казакъстанда яшәүче татар һәм башкортларның этномәдәни үзәкләре ассоциациясе президенты булып сайланды.

М. Ауэзов исемендәге Әдәбият һәм сәнгать институтында халыкара мөнәсәбәтләр киңәйгәннән-киңәя бара. Сеул шәһәрендә

үз эченә казакъ эпосларын һәм әкиятләрен туплаган «Kazakhstan» китабы басылып чыкты. Казакъстанда Корея елы кысаларында Корея Республикасы мәдәният, спорт һәм туризм министрлыгы, Казакъстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән берлектә, мәдәни хәзинәләрне тулыландыру максатын күздә тотып, «Бүгенге мәдәният һәм мәдәни мирас» дигән IV Үзәк Азия-Корея киңәшмәсе үткәрелде, анда Таҗикстан, Кыргызстан, Корея һәм Казакъстан галимнәре катнашты.

Алтай дәүләт педагогия академиясе галимнәре белән бергә «Русская словестность в России и Казахстане: аспекты интеграции» (2011) дигән темага Халыкара фәнни конференция уздырдык. Коференция материаллары, шушы ук исемдәге китап булып, Барнаулда басылып чыкты.

Казакъстан Республикасының АКШтагы Гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе, хәзер КР тышкы эшләр министры Ерлан Идрисов ярдәмендә һәм минем кереш мәкаләм белән АКШта «Antholoqy of Kazakh Literature» («Антология современной казахской литературы») дөнья күрде. Бу – АКШның Колумбия университеты белән эшләнгән беренче уртак проект җимеше. Басмага тагын бер китап әзерләнә. Ул проектны Колумбия университеты профессоры Рафис Абазов тормышка ашыра.

Казакъстан нефть, газ һәм башка файдалы казылмаларга гына бай ил түгел, Казакъстан – рухи яктан бай кешеләре белән дә көчле ил, нәкъ менә шушы рухи югарылык бездәге 140 лап төрле этник төркемнәргә үзара дус, тату яшәргә мөмкинлек бирә. Президентыбыз Нурсолтан Назарбаев, бу күренешне бөтен тулылыгы белән аңлап, Республикада яшәүче һәр халыкның иҗатын өйрәнү һәм үстерү бурычын куйды. Чөнки аларның һәркайсы гомуммәдәниятнең бер өлеше, шуның белән бергә һәркайсының (русларның, татарларның, украиннарның, дунган, чеченнәрнең һ.б) үзләренә генә хас «эз»ләре бар.

Без Европа әдәбиятын өйрәнеп тикшерүне башладык. Институт хезмәткәрләренең мәкаләләре төрле илләрдә бастырыла. Безгә Иран илчелегеннән дә хезмәттәшлеккә тәкъдим булды. Алар белән эшләүнең перспективасы да өметле. Институтыбызның кулъязмалар фондында 500 мең язма мирас саклана, шулар арасында 10 том чамасы күләмендәге «Шаһнамә» поэмасының казакъ акын-җыраулары тарафыннан сөйләнгән вариантлар да бар. Бу уникаль әсәрләрне уртак тырышлык белән бастырып чыгара алсак, яхшы булыр иде.

Чит ил белгечләре (Һиндстан, Чехия, Төркия югары уку йортлары әдәбият галимнәре, тәнкыйтьчеләр һәм укучылары) катнашлыгы белән «Очерки по мировой литературе рубежа XX–XXI столетий» китабын әзерләп бастырдык. Россия Фәннәр академиясенең А.М. Горький исем. Бөтендөнья әдәбияты Институты (Мәскәү), Румыниянең Александр Ион Куза дәүләт университеты (Яссы), Молдова Фәннәр

академиясенең Молдова әдәбияты институты (Кишинев) әдәбият белгечләре белән «Литературно-художественный диалог» басмасын кулга алуга ирештек. «Новейшая зарубежная литература» дигән коллектив монографияне чит ил галимнәре «гаҗәп бай материал һәм бүгенге әдәби процесста ориентир» дип бәяләделәр. Бу басманы әзерләп чыгаруда Германия Фәннәр академиясе (Геттинген), Румыниянең Александр Ион Куза исем. дәүләт университеты (Яссы), Болгария фәннәр академиясенең әдәбият институты (София), Словакия Фәннәр академиясенең Словак әдәбияты институты (Братислава), Азәрбайҗанның Бакы славян университеты (Бакы), Молдова Фәннәр академиясенең Молдова әдәбияты институты (Кишенев) һәм Россия Фәннәр академиясенең А.М. Горький исем. Бөтендөнья әдәбияты институты галимнәре катнашты.

Институтта чыгарыла торган фәнни-популяр һәм әдәби-сәнгати журнал «Керуен»да ерак һәм якын чит ил (Германия, Франция, Румыния, Төркия, Корея, Россия, Беларусь, Үзбәкстан, Молдова, Азәрбайҗан, Кыргызстан һ.б.) әдәбият белгечләренең һәм сәнгатькәрләренең фәнни мәкаләләре, аналитик күзәтүләре, рецензияләре басыла. Болар барысы да үзара фәнни элемтәләрне ныгытырга, хезмәттәшлек географиясен киңәйтергә хезмәт итә.

Казакъстанның милләтара бердәмлеккә, толерантлыкка, мәдәниятләрне хөрмәт итүгә корылган сәясәте нәтиҗәсендә, казакъ әдәбияты һәм Республикадагы милли әдәбиятлар үсеш процессында гомумкешелек кыйммәтләренә юнәлеш тота. Алар бөтендөнья мәдәниятенең һәм әдәбиятының тигез хокуклы һәм аерылгысыз бер өлешен тәшкил итәләр, бүгенге заманның көнүзәк темаларын яктырталар.

Казанда уздырылган «Төрки халыклар әдәбияты һәм музыкасы чыганаклары һәм эволюциясе» дигән Халыкара фәнни конференция дә, һичшиксез, иҗади һәм фәнни элемтәләрне ныгытуга хезмәт итәчәк. Бу – төрки дөньяны торгызу максаты белән гамәлгә куела торган процесслар фонында аеруча мөһим.

Бик борынгыдан ук барлык төрки халыкларның да башлангычы Бөек Далага барып тоташа. Безнең каһарман бабаларыбыз бердәмлекне саклаганнар, үзара килешеп яшәгәннәр, шуның нәтиҗәсендә Евразиянең Байкалдан алып Балканга кадәр җәелгән киңлекләренә хуҗа булып, куәтле империяләр төзегәннәр. Бөек Дала гасырларның тарих бишегендә иркен, имин гомерләр дә кичергән; эчке дошманлык, үзара ызгыш-талашлар сәбәпле килеп туган авыр заманнарда үз бәйсезлеген югалтып, башкаларга буйсынып яшәргә дә дучар булган.

Шулай да төрки халыкларның данлы елъязмасында бөек гамәлләре белән горурлык, соклану хисләре уятып, халык хәтеренә сеңгән каһарманнарыбыз да аз түгел. Әйтик, Атилла, Бумын, Бейбарс, Әмир Тимер, Бабыр кебек бөек хакимнәр һәм гаскәр башлыклары дөнья картасын

формалаштыруга гаять зур йогынты ясаганнар.

Изге төрки дала – каһарман батырлары белән генә түгел, ә күренекле галимнәр ватаны буларак та данлы җир. Төрле дәверләрдә яшәгән әл-Фараби, Мәхмүд Кашгарый, Баласагуни, әл-Харәзми, ибне Сина, Әхмәд Ясәви, Улыкбәк, М. Дулати һ.б. дөньякүләм цивилизацияне алга җибәрүдә бәяләп бетергесез өлеш керттеләр. Бөек Дала даһиларының хезмәтләре Европа Ренессансы нигезен тәшкил итте һәм аның күтәрелеп китүенә этәргеч булды. Ә бүген Нәвои, Низами, Мәхмүтколый, Абай, Назыйм Хикмәт, Габдулла Тукай, Анар, Чыңгыз Айтматов, Әбдеҗәмил Нурпеисов һ.б. бик күп шагыйрьләрнең һәм язучыларның исемнәре төрки әдәбиятның символлары булып әверелделәр.

Бәйсезлек шартларында гомер кичергән бу көннәрдә борынгы бабаларыбызның мәдәни-тарихи мирасларын саклау аеруча мөһим. Безнең Институт үзебездә тупланган халык иҗатының мирасын, алга таба тагын да тирәнрәк ачыклау максаты белән, тикшереп өйрәнүне дәвам итә. Без халкыбызның мәдәни ядкәрләрен торгызуда бергәләп эшләрбез дип ышанабыз, чөнки бу безнең уртак рухи байлыгыбыз һәм без аларга иҗади илһам, яңа идеяләр чыганагы буларак һәрдаим мөрәҗәгать итәбез.

***Вәлихан Калижан улы Калижанов,***
*филология фәннәре докторы, Казакъстан Республикасының*
*Милли Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы,*
*М. Ауэзов исемендәге Әдәбият һәм сәнгать институты директоры*

УДК 821.161.1´255

*Л.Г. Хәбибуллина*

# ӘДӘБИ ТӘРҖЕМӘ МӘСЬӘЛӘСЕ
## (Анна Ахматованың «Сайланма әсәрләр»е мисалында)

В статье рассматривается соотношение оригинала и перевода художественного текста в «Избранных произведениях» (2013) Анны Ахматовой.

**Ключевые слова:** художественный перевод, Анна Ахматова, поэтический текст.

Әдәби тәрҗемә – катлаулы иҗади процесс. Ул, беренче чиратта, тәрҗемәченең профессиональ әзерлегенә һәм иҗади индивидуальлегенә бәйле. Шигырьне тәрҗемә итү исә, тәрҗемәченең үзенең дә шагыйрь булуын сорый. Чөнки бу очракта мәгънәне бирү генә түгел, ә хис-кичерешләрне, ритмиканы чагылдыру да таләп ителә. Тәрҗемәчегә өстәмә рәвештә шигырь төзелеше, рифма, кыскасы, шигырь теориясеннән хәбәрдар булу, башка телнең шигъри формасында башлангыч мәгънәне мөмкин кадәр тулы чагылдыру бурычлары йөкләнә. Тәрҗемәченең сәләтенә бәйле рәвештә тәрҗемә әсәре өр-яңа мөстәкыйль, шул ук вакытта оригиналы белән мәгънәви, информацион һәм эстетик яктан бербөтен әсәр буларак формалаша. Рус әдәбияты классигы И.А. Бунин әйткәнчә, сүзләрне түгел, ә көч һәм рухны тәрҗемә итәргә кирәк.

Әлеге мәкаләдә шагыйрә Анна Ахматованың 2013 елда «Мәгариф – Вакыт» нәшриятында дөнья күргән «Сайланма әсәрләр»ендә тәрҗемә мәсьәләсе, оригинал һәм тәрҗемә әсәрләренең эчтәлек гомумилеге, мәгънәви якынлыгы, ягъни эквивалентлыгы каралачак. Тәрҗемә өчен нәкъ менә әлеге шагыйрә иҗаты алыну очраклы түгел. Анна Ахматова исеме рус әдәбиятында гына түгел, дөнья поэзиясендә дә лаеклы урынын алган. Әдәбият елы символикасында аның Пушкин һәм Гоголь белән янәшә урнашуы үзе үк Ахматова шигъриятенә бәһане билгели. Татар шагыйрьләреннән Хәсән Туфан Ахматованың халыкчан традицияләргә тугрылыгын югары бәяли, Рәдиф Гаташ «Сафодан башлап бүгенгәчә килгән бөек шагыйрәләр арасында аның кабатланмас исеме, иҗаты бар»лыгын әйтә [Гаташ, б. 90].

Мәкаләдә каралачак китапка шагыйрәнең, рус телендәге оригинал әсәрләре белән беррәттән, яңа буын иҗатчылары Рифә Рахман, Гөлназ Вәлиева, Рәмис Аймәт, Луиза Янсуар, Илсөяр Иксанова, Лилия Гыйбадуллина, Йолдыз Миңнуллина тарафыннан махсус шул китап өчен татарчага тәрҗемә ителгән шигырьләре кергән. Тәрҗемә өчен Анна Ахматованың төрле елларда язылган (1909–1924, 1935–1940, 1942–

1946, 1956–1958, 1960–1963), шагыйрәнең рухи үсеш-үзгәрешен күзалларга ярдәм иткән шигырьләре, балладасы, танылган «Реквием» поэмасы сайланган.

Әдәби тәрҗемә билгеле бер таләпләргә җавап бирергә тиеш. Беренчедән, тәрҗемә төгәл булырга, тәрҗемәче укучыга автор фикерен мөмкин кадәр тулы җиткерергә тиеш. Икенчедән, фикер ачык булырга, тәрҗемәче күп сүзле булмаска, фикер мәгънә тулылыгына зыян килмәс дәрәҗәдә кыска булырга тиеш. Катлаулы һәм ике төрле аңлау мөмкинлеге булган төзелмәләрне кулланмау яхшы. Өченчедән, тәрҗемә әдәби тел нормаларына җавап бирергә, тәрҗемә әсәре табигый яңгырарга тиеш.

Бөек шагыйрәнең әсәрләрен татар телендә яңгыратуга алынган югарыда санап үтелгән тәрҗемәчеләр – әдәбиятта үз урыннарын тапкан талант ияләре. Гомуми планда караганда, алар татар укучысына Ахматова поэзиясенең тирәнлеген җиткерә алганнар. Әлбәттә, форма һәм эчтәлекнең барлык элементлары да башка телгә төп-төгәл күчерелә алмый. Иң югары дәрәҗәдәге тәрҗемәдә дә түбәндәге кимчелекләр очрый. Хәер, аларны кимчелек дип атау дөрес тә түгел, чөнки чын шигъри тәрҗемә бервакытта да сүзгә-сүз була алмый һәм бу мөһим дә түгел. Киресенчә, еш кына сүзгә-сүз тәрҗемә оригиналның эмоциональ тәэсирен бирә дә алмый. Карала торган китапта оригинал һәм тәрҗемә әсәрләрендә иң еш очрый торган кайбер үзенчәлекләр түбәндәгеләр:

1. Материалның кайсыдыр бер өлеше, аерым сүзләр төшереп калдырыла. Мәсәлән:

*Но душно там, и я пробралась в сад*
***Взглянуть на звезды и <u>потрогать лиру</u>***
(«Ночью»).

*Бөркү анда. Мин бакчага чыктым*
***Төнге йолдызларны күрергә***
(Лилия Гыйбадуллина тәрҗемәсе).

*Потрогать лиру* өлешенең тәрҗемә ителмәвен татар телендә әлеге гыйбарәнең турыдан-туры варианты булмау белән аңлатып була.

*И я закопала веселую птицу*
***За круглым колодцем у старой ольхи***
(«Был он ревнивым, тревожным и нежным...»).

*Ә мин күмдем шаян кошкаемны*
***Зирек агачының төбенә***
(Рәмис Аймәт тәрҗемәсе).

Биредә, гомумән, зирек агачы дип кенә бирелә, аның түгәрәк кое артындагы карт агач булуы конкретлаштырылмый.

*Мне никто сокровенней не был,*
*Так меня никто не томил,*
***Даже тот, кто на муку предал,***
***Даже тот, кто ласкал и забыл***
(«Я не знаю, ты жив или умер...»).

*Бер син генә минем якты серем,*
*Башка беркем болай тилертмәде.*
***Хәтта газапларга салганнар да***
*Бу кадәрле мине тилмертмәде.*
(Илсөяр Иксанова тәрҗемәсе).

Югарыда китерелгән мисалда тәрҗемәче *назлаган һәм оныткан* өлешен тәрҗемә итеп тормый. Бу эчтәлеккә бернинди дә кимчелек китерми, чөнки алар

гомуми планда *хәтта газапларга салганнар* дигән мәгънә эчендә карала ала.

*А я иду – за мной беда,*
*Не прямо и не косо,*
*А в никуда и в никогда,*
***Как поезда с откоса***

(Pro domo mea).

*Минем арттан кайгы йөри –*
*Адымнары елдам,*
*Һәм бушлыкка илтә мине –*
*Убыласы юлдан*

(Луиза Янсуар тәрҗемәсе).

Бу очракта чагыштыру төшереп калдырылса да, шигырьнең тәэсир көче кимеми.

2. Материалның аерым бер өлеше мәгънәдәш сүзләр, формалар белән алыштырып бирелә. Мәсәлән:

*Знаю:* ***брата*** *я* ***<u>не ненавидела</u>***
*И* ***сестры*** *не предала*

(«Помолись о нищей,
о потерянной...»).

*Тик* ***туганым*** ***<u>чит итмәдем</u>****, ышан,*
*Сатканым да аны булмады*

(Луиза Янсуар тәрҗемәсе).

Югарыда китерелгән мисалда рус телендәге *брат*, *сестра* дигән туганлык атамалары терминнары татар теленә гомуми *туган* сүзе белән генә бирелгән. *Не ненавидела* фигыле шулай ук *чит итмәдем* дигән гомумирәк мәгънәдә китерелә. Әйтергә кирәк: бу автор фикеренә бернинди дә хилафлык китерми.

*Вам он бродяга, шуан, заговорщик,*
*Мне он –* ***единственный сын...***

(Черепки).

*Сезгә ул – фетнәче, зимагур,*
*Ә миңа –* ***йөрәгем парәсе...***

(Луиза Янсуар тәрҗемәсе).

Оригиналы белән чагыштырганда *(единственный сын – бер-дәнбер улым)*, тәрҗемәдәге *йөрәгем парәсе* гыйбәрәсе эмоциональ яктан көчлерәк дип уйлыйбыз.

*Ты опоздал на много лет,*
***Но все-таки тебе я рада***

(«Широк и желт вечерний свет...»).

*Син күп еллар соңга калып килдең,*
***Бүләк итеп миңа бу язны***

(Илсөяр Иксанова тәрҗемәсе).

Әлеге очракта да тәрҗемәдә лирик геройның хис-кичерешләре тирәнрәк ачыла дигән нәтиҗәгә килергә җирлек бар. *Но все-таки тебе я рада – шулай да мин сиңа (синең килүеңә) шат* дигәнгә караганда *син миңа яз бүләк иттең* дигәндә шатлыктан зуррак халәт бирелә.

*Все* ***отнято****: и сила, и любовь*

(«Все отнято: и сила, и любовь»).

*Бар да* ***сүнде****: көч тә, мәхәббәт тә...*

(Рәмис Аймәт тәрҗемәсе).

Оригиналдагы *отнято* фигыле татар теленә *сүнде* фигыле белән бирелгән. Әйтергә кирәк: бу очракта тәрҗемә автор әйтергә теләгән фикерне турыдан-туры җиткерми, дип уйлыйбыз. *Отнято – тартып алынды* дигәндә, лирик геройга бәйле булмаган, объектив шартлар, ниндидер тышкы көчләр тарафыннан мәҗбүри рәвештә алынган көч һәм мәхәббәт аңлашыла. Ә көч тә, мәхәббәт тә сүнде дигәндә, субъектив шартлар, кичерешләр сәбәпле барлыкка килгән нәтиҗә күзаллана. Бу очракта тәрҗемәче, шигырьнең рифмасын, ритмикасын саклау өчен, *сүнде* сүзен кулланган.

3. Чыганак әсәрдә булмаган материал өстәп китерелә.

Күзәтүләребездән чыгып, шуны әйтергә була: күп очракта тәрҗемәдә оригинал текстта булмаган, җөмләдә аергыч ролен үтәүче кисәк өстәлә. Мәсәлән:

*Уколола палец безымянный*
*Мне звенящая оса*

(«Я сошла с ума,
о мальчик странный...»).

*Атсыз бармагымны чәнчеп узды*
*Зыңгылдаган* ***ялгыз*** *шөпшә*

(Гөлназ Вәлиева тәрҗемәсе).

*И вот сегодня снова жаркий вечер...*
*Как низко солнце стало над горой...*

(«Еще весна таинственная млела...»).

*Менә бүген җәйнең* ***тып-тын*** *эссе*
*киче...*
*Таулар итәгенә* ***ал*** *кояш эленгән*

(Илсөяр Иксанова тәрҗемәсе).

Күргәнебезчә, аерым сүзләр өстәлү шигырьнең мәгънәсен бозмый.

Татар һәм рус телләренең синтаксик нормаларына бәйле рәвештә дә тәрҗемәдә үзгәрешләр була. Телдәге сүз тәртибе, шигъри сөйләм үзенчәлекләренә карап, тәрҗемә ителгән текстта аерым сүзләрнең, сүзтезмәләрнең, хәтта җөмләләрнең урнашу тәртибе үзгәрә ала. Еш кына тәрҗемә вакытында грамматик формаларны, аерым лексик берәмлекләрне үзгәртү, алмаштыру күзәтелә. Грамматик үзгәрешләргә сүзләрнең формасын, сүз төркемнәрен, җөмлә кисәкләрен, җөмләнең синтаксик структурасын үзгәртү (гади җөмләне – кушма җөмләгә, кушма җөмләне – гади җөмләгә, баш җөмләне – иярчен җөмләгә, иярчен җөмләне – баш җөмләгә, тезмә кушма җөмләне иярченле кушма җөмләгә үзгәртү һ.б.) кертелә. Мәсәлән:

*Ты был испуган нашей первой*
*встречей,*
*А я уже молилась о второй...*

(«Еще весна таинственная млела...»)

*Мин ялвардым сорап кабат*
*очрашулар,*
*Син калганда куркып тәүге*
*күрешүдән*

(Илсөяр Иксанова тәрҗемәсе).

Өлеге мисалда тезмә кушма җөмлә тәрҗемәдә иярченле кушма җөмләгә үзгәртелгән.

Әдәби тәрҗемә – әсәрне бер телдән икенче телгә күчерү генә түгел, ә аңа башка телдә өр-яңа яңгыраш бирү. Анна Ахматова иҗатына хис психологиясен нечкә тоемлау, яшәешнең әхлакый нигезләренә тугрылык, XX гасырның гомумхалык фаҗигасен үзе аша үткәреп, тирән аңлау, шигъри телнең классик стиленә омтылу хас. «Сайланма әсәрләр» җыентыгында урын алган тәрҗемә шигырьләрендә Ахматова поэзиясе үзенчәлекләре сакланган. Гомумән, тәрҗемәнең оригиналга якынлыгы гына аның сыйфатлы башкарылуы күрсәткече була алмый. Иң мөһиме: бер телдән икенче телгә күчерелгән шигырь сәнгать әсәре буларак әдәби кыйммәтен югалтмаска тиеш.

**Әдәбият**

1. *Ахматова А.А.* Избранные произведения = Сайланма әсәрләр / Анна Ахматова. Казань: Магариф–Вакыт, 2013. 168 с.

2. *Гаташ Р.* «Анна апаң Ахматова күк...» / Ахматова А.А. Избранные произведения = Сайланма әсәрләр / Рәдиф Гаташ. Казань: Магариф – Вакыт, 2013. Б. 89–92.

3. *Павловский А.И.* Анна Ахматова: Жизнь и творчество. М.: Просвещение, 1991. 192 с.

***Хәбибуллина Лениза Газинур кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология*
*һәм диалектология бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145'373

*Г.С. Хаҗиева-Демирбаш*

# РАФАИЛ ГАЗИЗ ХИКӘЯЛӘРЕНЕҢ ПОЭТИК ОНОМАСТИКАСЫ

В статье рассматриваются особенности поэтического ономастикона прозы Рафаиля Газизова. Были проанализированы реальная и ирреальная ономастическая система избранных сочинений писателя. Автором подчеркнута тесная взаимосвязь ономастической системы произведений с мировоззрением автора и его литературной логикой.

**Ключевые слова:** проза, поэтическая ономастика, реальная и ирреальная ономастика, мирровоззрение.

Татар прозасы телебезнең камил яшәешен, милләтебезнең рухи көчен арттыруда, халкыбызда милли рух тәрбияләүдә зур вазыйфа башкара. Һәр язучы үз төбәгенең иксез-чиксез байлыгын зур тарихлы телебезгә өсти. Татар прозасы халкыбызның телен, шул исәптән, поэтик ономастикасын өйрәнүдә дә гаять дәрәҗәдә әһәмияткә ия чыганак булып тора. Әсәр тукымасына кертелгән ономастик берәмлекләр тарихи чыганак ролен үти. Шул ук вакытта әсәрнең ономастик системасы авторның дөньяга карашын, әдәби логикасын күзалларга мөмкинлек бирә, контекст эчендә төп факторлардан саналган әдәби бөтенлекнең образлар системасын формалаштыруында катнаша. Әдәби әсәрләрнең ономастик системасы язучы иҗат лабораториясенең фәлсәфәсен һәм психологиясен яктыртуда да кыйммәтле.

Бу җәһәттән Мамадыш районы Кече Кирмән авылында яшәп иҗат итүче Рафаил Газизнең проза әсәрләре игътибарга лаек. Аның әсәрләрендә урын алган ономастик лексика поэтик һәм лингвистик әдәби текст төзелешен формалаштыра торган чараларның берсе булып тора һәм, шул рәвешле, язучының үз стилен барлыкка китерә. Р. Газиз авыл тормышын, хезмәтен тирәнтен аңлап яшәгәнлектән, ул авыл кешеләренең уй-хисләрен, эчке дөньясын яхшы тоемлый һәм иҗатында да шуны ачык чагылдыра. Яшәеш фәлсәфәсе, тормышчанлык, авылның язмышы турындагы борчулар, өлкән буын белән яшь буын арасында бәйләнешнең югалуы турындагы уйлар – болар барысы да язучы, шагыйрь иҗатының чишелү көткән төп проблемаларын тәшкил итәләр. Бу үзенчәлекләр – барысы да әсәр геройларының исемнәрендә, авыл топонимиясендә дә чагылыш тапканнар.

Әдәби текстның ономастикасы уйлап табылган яисә реаль булып, халыкның реаль исемиятендә чагылыш табып, укучыга конкрет исемнәр системасын күзалларга, әдәби әсәр текстының ономастик берәмлекләренең катгый мотивлашуын ассызыкларга, контекст эчендә геройның социаль, милли һ.б. үзенчәлекләрне

ачып бирергә ярдәм итә. Р. Газизнең әсәрләрендә, нигездә, татар исем системасындагы гадәти, реаль исемнәр кулланылса да, бу исемнәр автор идеясен ачуда эстетик функция үтиләр. Хикәяләрендәге исемнәр сүзнең көчен, мәгънә нечкәлекләрен, яңгырашын төгәл тойган әдипнең осталыгын күрсәтүче матур үрнәкләр булып торалар.

Автор, нигездә, прототипларының реаль исемнәре белән эш итә. Аның иҗатында уйдырма топонимик, антропонимик берәмлекләргә мөрәҗәгать итүе аз күзәтелә. Автор татар авылының чын тормышын, гореф-гадәтләрен аның чын, реаль ономастикасы белән дә күрсәтә дияргә нигез бар: «Куша белгәннәр элек чын исемне, *Шәмсекамәр* бит – кояш һәм ай дигән сүз». «Күтәреп мунчага алып барды, сеңлесе *Гандәлифә* юындыргач, күтәреп алып чыгып мамык түшәгенә салды». «*Минегаяз, Ибраһим, Гарифулла, Гафиятулла*, Сыздырып җибәрде өч тальян: *Ибраһим, Хөсәен, Барый абый...*». «Егерме бишенче елгылар байтак: *Һаҗәр апа, әни, Ибраһим абый, Сәлимә апа, Миргазиз абый*, яшьрәк булсалар да, *Хөсәен абый белән Сылубикә апа*». «Сиңа да үпкә зур, *Барыйҗан,* чөнки *Тәхиятуллада* син төзәтеп-көйләп биргән уфалла, артык худлы йөри» («Кичер, кичерә алсаң»).

Язучының кеше исемнәренә *-тай*/*-тәй* иркәләү-кечерәйтү кушымчасын кушуы сөйләмгә чынбарлыкның төгәл палитрасын бирергә ярдәм итә. Бу кушымча төрки телләрдә һәм татар диалектларында берлек сандагы тартым кушымчасы нигезендә ясалган, иркәләү-кечерәйтү мәгънәсендә килгән *тайым* сүзенә бәйләнешле ясалган. «*Нурлыбикәттәегез* пешергән дучмакны өч сынык ашаганнан соң, яхшылап чәй эчеп, эш киемнәрен – халат-мазарларны эләктереп чыктым ишегалдына» («Богзай»). «Фәтхиянең гадәтен белгән *Зәкирәттәй*» («Хөсәен ничек кайткан?»). Каримә карчыкны *Зарифәттәйне* капка төбенә чакырдым («Алтын баганам»). Кайбер очракларда автор *-тай*/*-тәй* кушымчасының кыскартылган формасына да мөрәҗәгать итә: «Кала сулда *Банутти* исәнләшеп, кала уңда Васыйлым кагып». «*Камәрти* урын өстенә менгәч тә, кайбер кеше кызларыннан да күрмәгән кадер-хөрмәт күрсәтте» («Кичер, кичерә алсаң...»), «Эшнең чиста түгел икәнен шундук сизгән *Фатиматти*» («Гаян абый хат укый»). Р. Газизов хикәяләрендә авыл халкында кулланылган реаль кеше исемнәрен генә әсәр тукымасына кертеп калмый, ул күпчелек исемнәрне реаль кушамат белән бергә куллана. Билгеле булганча, авылда кушамат тагу – ул гадәти күренеш. Авылның дөнья картинасын тагы да киңрәк күзаллау, палитраларын тулырак күрсәтү максатында автор бу әдәби алымнан оста файдалана. Шул рәвешле, Р. Газизнең хикәяләрендә авыл колориты тагы да куера төшә. Хикәяләрендәге кушаматлар әдәби геройны формалаштыруда, аны образ ясауда иң тәэсирле берәмлекләр дип саналырга хаклы. Автор әсәрендә күп төрле кушаматларны куллана: «Кичер, кичерә алсаң...» әсәрендә «Әче-

гән Хамис», «Хәллә Шәфыйгы», «Норма Сәми», «Күкәр Нигъмәте», «Бүдәнә Салих», «Чүлмәк Вәгыйзь», «Хабыйк Хөсәен», «Күкеле сәгать», «Герман», «Шәһәр Рәфәгате», «Куян Фазылы», «Дөл-дөл» хикәясендә «Мүки Хөсәене», «Куян Хөсәене», «Мәтә Закиры», «Норма Мөхипулла», «Бүдәнә Салих», «Куян Сәхие», «Печән Гаязы», «Аю Гаяны», «Равил абый әкият сөйли» хикәясендә «Чүлмәк Гамиләсе»; «Түтүт Гарифы» хикәясендә «Түтүт Гарифы», «Куян Вакыйфы», «Норма Ягъфәр», «Кисмәк Камилә», «Аксак Хисам», «Чегән Зарифы», «Әманәт» хикәясендә «Үчтеки Миңнехан», «Сәдака Миңнехан», «Гаян абый хат укый» хикәясендә «Хам-хам Патый», «Бәкер Вафич», «Үчтеки Миңнехан» хикәясендә «Мәгънәви Мәсләвиевич», «Шәвәли Шәвәлиеч», «Сәдака Миңнехан», «Пулый Рәфәгате», «Завхоз» хикәясендә «Мәрдән Хөсәене», «Богзай» хикәясендә «Сәлим Сәйфулласы», «Сәлимеч», «Җиңүчеләр» хикәясендә «Гарәфетдин Нуридәсе», «Шәкүр Хөснурие» кебек геройлар тулы бер образ буларак күз алдына килеп басалар. Язучы кайбер кушаматларның тагылу тарихын әсәр тукымасына кертеп, әсәрнең композицион төзелешен тагын да тулыландыра. Мәсәлән, «Кичер, кичерә алсаң...» әсәрендә геройга кушамат тагылуын болай дип аңлата: «Безнең авылда Вәгыйзь абыйның гына ике кушаматы бар. Берсе – Герман, чөнки бу – аның яраткан сүгенү сүзе. Икенчесе соңгы елларда гына тагылды. Анысы – Күкеле сәгать. Әйе шул. Нәкъ тәрәзәсе шалт итеп ачылып, аннан ялт итеп Вәгыйзь абый башы атылып чыккан, авылдашлары таккан кушамат. Авыл тарихында булмаган байлык, бер кешегә ике кушамат...» («Кичер, кичерә алсаң....»). «Дөл-дөл» хикәясендә Куян Хөсәене кушаматының килеп чыгышы: «Нәселләрендә ишле бала үстергәнгә, Куян кушаматы тагылган. Әнә шул кушаматка хыянәт итмичә яшәүче Хөсәен абый иде инде» («Дөл-дөл»). «Үчтеки Миңнехан» хикәясендә колхоз рәисенә ялганчы булганга һәм хуҗа ягыннан ярсулы нәфрәт белән кире кагылгач тагылган Шәвәли кушаматы турында сүз алып бара.

Р. Газизнең хикәяләрендә кушаматлар геройларның тышкы, физик үзенчәлекләрен: *«Бүдәнә Салих»* («Кичер, кичерә алсаң..»), *«Аю Гаяны»* («Дөл-дөл»); характер үзенчәлекләрен: «*Түтүт Гарифы»* («Гаян абый әкият сөйли»), *«Сәдака Миңнехан*» («Әманәт»), *«Шәвәли Шәвәлиеч»* («Үчтеки Миңлехан»); төбәккә, туган авылга, урынга бәйләнешле: *«Норма Сәми»* («Кичер кичерә алсаң...»), *«Бәкер Вафич»* («Гаян абый хат укый»), *«Норма Ягъфәр»* («Түттүт Гарифы»); нәселгә бәйләнелешле: «*Куян Сәхие»* («Дөл-Дөл» хикәясе), *«Куян Зарифы»* («Түтүт Гарифы»), *«Куян Кәримулласы», «Куян Вакыйфы»* («Җылылык») яктырталар.

Автор тарафыннан исемнәргә фамилия яки отчествоны кушып әйтү әдәби геройларга социаль-тарихи статус төсмере өсти: *партоешма секретаре «Рәхмәтулла Сәлимеч»* («Богзай»), *колхоз председателе «Нәгыйм Исламович», колхоз рәисе «Мәгънәви*

*Мәсләвиевич»* («Үчтеки Миңнехан») һ.б. Татар телендә отчество *-ович*/*-евич*/*-овна*/*-евна* кебек антропонимик кушымчалар ялгану нәтиҗәсендә һәм милли формулага нигезләнеп тә ясалалар: *Хәбыйк Хөсәене* («Кичер, кичерә алсаң...»), *Зариф Гайние* («Ак болыт»), *Сәлим Сәйфулласы* («Богзай»), *Юныс Гаяны* («Иптәш капитан») һ.б. Гади авыл халкын сурәтләгәндә, Р. Газиз отчествоның милли традицион формуласыннан отышлы файдалана.

Р. Газиз, персонажларның официаль эндәшүләрен чагылдырганда, тулы официаль формаларга (*Габдерахманов Барый, Сәлимов Рәхмәтулла Сәлимович*), аерым апеллятив сүзләр ярдәмендә ясалган формаларга (*Рафаил кәкә, Шәкүр абый, Диләфрүз апа, иптәш Сафин, иптәш Гатин*) мөрәҗәгать итә.

Р. Газиз әсәрләренең поэтик антропонимнарында новаторлылык һәм традиционлык юнәлешләрен күрергә мөмкин. Традиционлылык реаль антропонимнарга мөрәҗәгать итүендә билгеләнсә, новаторлылыгы исемнәрне кушаматлар белән бергә бирүендә чагыла.

Р. Газиз иҗатында поэтик топонимнар системасы гаять үзенчәлекле сурәтләнгән. Топонимнар әсәрдәге фонны бөтен нечкәлекләре белән генә барлыкка китереп калмыйлар, шул ук вакытта геройларның дөньяны танып-белүен, тоемлавын сурәтләүдә ярдәм итәләр. Авылның үз киңлеге, үз яшәеш пространствосы бар. Р. Газиз әлеге киңлекне күз алдына китерүдә топонимик материалдан бик уңышлы файдалана. Хикәяләрендә гидронимнар турында язганда, укучы күз алдына китерерлек, сенсорик тоемлауны арттырырлык эпитетлардан да файдалана. Автор чишмәне исеме белән атап кына үтми, ә аңа чагыштырулар ясый, эпитетлар өсти: ...Кирмән алыпсатарлары *Кардон чишмәсе* буена сыгылып-бөгелеп, мәдрәсәдә дога көйләп утыручы шәкертләр сыман атынучы талларга сандугачлар бүләк иткән («Ак болыт»). *Трайт чишмәсеннең* суын эчтек. Су түгел ул, энем, ширбәт («Ак Болыт»). *Сәрдәхуш елгасы* башындагы каеннардан берән-сәрән генә яфрак оча («Ак болыт»), Менә *Яке елгасы* башындагы уяз да артта калды. Хәтерлисеңме, теге Хөснетдин бабайларның Бакырчы чишмәсе юлында күмер яндырганнарын? («Кичер, кичерә алсаң...»); *Сәрдәхуш елгасындагы Сердәш чишмәгә*, исемнәребез уелган каен янына менмичә булмас («Ак болыт»). Шулай ук аның әсәрләрендә топонимнар: «*Кече Кирмән* авылына баруым минем («Ак болыт») «Менә шул Сәми *Ташлы авылдан Краснайга* баручы урысның, менә ул урыс тач Әгъзам абыйга охшаган иде, үзе озын, үзе җирән... («Кичер, кичерә алсаң...»). Барый абыйны *Мамадышка* илтеп салганда инде гангрена узынган була («Кичер, кичерә алсаң...»). Инкыйлабтан соң 1016 йорты булган авыл *Су-Елга, Өләүкә, Хәсәнша* күченгәч тә зур иде («Ак болыт»); микротопонимнар: Икенче көнне *Сукыр урамдагылар* башына бәрхет түбәтәй кунаклаган, аягына затлы читек кигән, ак күлмәге өстеннән затлы камзул эләктергән

кешене танымадылар («Ак болыт»). *Аръяк урамында*гы Латыйфәттәйләргә төш («Ак болыт»). Тагын бер-ике атлауга зират белән *Яке урамы* арасындагы басу күренер... («Ак болыт»). «Бер атна туганында *Аскы урамда* качып яткан («Ак болыт»). Ниһаять, ул *Чегән тавыннан* күтәрелүче тыкырыкка борылды («Ак болыт»). Ай, текә бит ул *Саурыш таулары, Арташ Үрләре* («Ак болыт»). Төшәбез *Кантур тавыннан*, эчәбез чишмә суын («Равил абый әкият сөйли»). «Киттек Минедохаттиләр янындагы таудан төшеп, каршыда *Урыс Юлы* күренде («Ак болыт»). Урыслар авылга менә шушы таудан килеп, китеп йөргәнгә, тауга *Урыс Юлы* исеме бирелгән дә («Ак Болыт»). Кеше аяк басмаган, шомлы *Бурсык урманы* кырыеннан Артыш авылына борылдык («Ак Болыт»). Барып керә *Бурсык урманына* («Равил абый әкият сөйли»). Сезнең Өләүкә янында *Кыз урманы* бармы? («Ак Болыт»). Без ун чакрымлы *Озын Басуны* узып Демьяновкага якынлашабыз («Ак Болыт»). *Арташ чокырын* менгәндә Гаяз абыйның әйткән сүзләре хәтеремә уелды («Ак Болыт»). Тиздән Өчпочмак патшалыгы булачак *Сайкичүдә* үзешчән сәүдәгәрләр йөгерешә («Иптәш капитан»). Беренче булып *Югары Зират* игътибарыгызны җәлеп итәр («Ак болыт»). Су-Елгадан Кече Кирмәнгә теркелдәсәгез, иң беренче булып каршыгызга *Ризван каеннары* чыгар («Ак болыт»).

Әсәрдәге ономастик берәмлек – сәнгатьчә матурлыкны барлыкка китерүдәге чаралар системасының мөһим эстетик компоненты. Рафаил Газиз әсәрләрендәге һәр ономастик берәмлек үзенчәлекле стилистик мәгънәгә ия. Хикәяләрендәге исемнәр эчтәлекне дөрес һәм тулы ачарлык итеп сайланган. Персонаж исемнәренең бай хәзинәсендә татар халкының тарихы, затлы әхлагы, зәвыгы, мәдәни һәм рухи культурасы, хыял-омтылышлары чагыла. Барлык антропонимик категорияләр дә персонажның характер үзенчәлеген тулы ачуда, кеше күңелендәге изге, саф хисләрне уятуда һәм әсәрнең идея-эстетик кыйммәтен сәнгатьле чагылдыруда мөһим чыганак булып торалар. Әсәрдәге топонимик һәм гидронимик берәмлекләр исә, чынбарлыкны, татар авылының бөтен нечкәлекләрен күз алдына китерергә ярдәм итәләр. Нәтиҗә ясап әйткәндә, Рафаил Газиз әсәрләренең ономастик киңлеге гаять дәрәҗәдә зур. Ул – татар әхлагы, традицияләре, тормышының тирән чагылышын тоемларга, татар исемиятенең палитрасын күрергә, туган якның матурлыгын аңларга өйрәтүче талантларның берсе.

**Әдәбият**

*Газиз Р.* Кичер, кичерә алсаң. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998.

*Газиз Р.* Ак болыт: (хикәяләр, шигырьләр, мәкаләләр). Чаллы, 2003. 224 б.

***Хаҗиева-Демирбаш Гүзәлия Сәйфулла кызы,***

*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.*

УДК 398=511.152

***В.И. Рогачев***

# МОРДВА ФОЛЬКЛОРЫНДА ТАТАР ОБРАЗЫ

*Рогачев Владимир Ильич – М.Е. Евсевьев исемендәге Мордва дәүләт педагогика институтының рус, чит ил әдәбияты һәм аларны укыту методикасы кафедрасы профессоры, филология фәннәре докторы, мордва халык иҗатын өйрәнеп, Россия фәненә зур өлеш керткән җитди шәхес. Тарих, әдәбият, фольклор, этнография өлкәләренә багышланган 100 дән артык фәнни хезмәт, шул исәптән дистәдән артык монография һәм уку әсбаплары авторы. Күрше мордвалар фольклоры белән бергә, гомумән, Идел буе угро-фин халыкларының рухи мәдәниятенә, мордвалар һәм төрки халыклар арасындагы тарихи, әдәби-мәдәни бәйләнешләргә гаять игътибарлы галим озак еллар буена үзара аралашып яшәү нәтиҗәләрен җентекле күзәтә килә.*

*Фольклорчы белгеч буларак, В.И. Рогачевның Казан фольклор мәктәбенә биргән бәясе бик югары. Аның белән язышкан хатларның берсендә Казан һәм татарлар турында ул: «Татарлар башкаласы – минем цивилизациямнең туган җире», – ди. В. И. Рогачев үзенең һәм мордва мәдәниятен өйрәнүче башка галимнәрнең остазлары Казан фольклор мәктәбе галимнәре булуы белән чиксез горурлануын белдерә, татар фольклорына багышланган яңа хезмәтләр белән даими кызыксынып, аларга карата үз фикерен белдереп тора.*

*Игътибарыгызга галимнең татар һәм башка төркиләрнең мордва халык җырларында гәүдәләнүен күзәтүгә багышланган кызыклы фәнни язмасын татар телендә тәкъдим итәбез.*

***Лилия Мөхәммәтҗанова,***
*филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

В статье на примере материалов устного поэтического творчества мордовского народа рассматривается изображение татарского народа, его отдельных представителей. Исследуются художественно-изобразительные приемы, языковые, стилистические средства, приемы психологического параллелизма, поэтические тропы, символика, служащие для создания образа представителей татарского народа.

**Ключевые слова:** устно-поэтическое, народное, песенное, творчество, татарский, мордва.

Идел буенда фин-угор һәм төрки этносларның элек-электән яшәүләре мәгълүм. Алар арасындагы актив интегратив, хуҗалык-икътисадый процесслар гасырлардан гасырларга көчә килә, биредә халыкларның бер-берсенә толерант мөнәсәбәте, яшьләр арасында үзара җылы бәйләнешләр формалашкан.

Этносларның дисперс яшәүләре белән бәйле рәвештә, мордва-татар, рус-татар-мордва, татар-мордва-башкорт авылларында кешеләр үзара тату һәм дус күршеләр булып яшиләр. Этнос-

ара чиккә керә торган зоналарда яшәгән мордваларда рус, татар, чуваш, башкорт, казахлар белән катнаш никахлар да күзәтелә.

Идел арты, Самара, Пенза, Саратов, Уфа, Оренбург, Тубыл, Томск губернасы, Төньяк Казахстан кебек төбәкләрдә башка халыклар белән тыгыз аралашып яшәгән мордва яшьләре, эндогам чикләрне җиңел атлап чыгып, еш кына башка милләт вәкилләре белән никахка кергәннәр, бу очракта катнаш туйлар гадәти күренешкә әйләнгән.

Күрше халыклар арасында барган җылы мөнәсәбәт, катнаш никах мотивлары мордва халкының гаилә-көнкүреш фольклорында бик киң чагылыш тапкан. «Цёрась паро Дёма-Дёмуша» («Ару егет Дёма-Дёмуша») исемле җырда буй җиткән егетнең, үз туган гаиләсеннән «Җаек ягына, казах җиренә» чыгып китеп, казах кызына өйләнү мотивы үстерелгән [Евсевьев, с. 32]. «Клёмо» («Клим») җыры да шуңа авазлаш: биредә яшь ир, үзенең бала тапмый торган хатынын ташлап, казах җиренә китәргә теләвен белдерә.

Мон тосто саян казахонь тейтерь,
Сон цера чачты кернек-ленгенек,
Сон тейтерь чачты штернек-
пакарнек
[Евсевьев, с. 37].

Тәрҗемәсе:

Анда мин казакъ кызы алырмын,
Ул миңа менә дигән угыл бала
тудырыр,
Ул миңа менә дигән кыз бала табып
үстерер.

Милләтара туй мотивлары, катнаш никах мәсьәләләре «Руся», «Эй, шинь стямаса, панда пряса» («Аһ, шәрыкта, биектә») җырларында да чагылыш тапкан. Степная Шентала авылында Х. Паасонен тарафыннан 1899 елда Игнатий Зориннан язып алынган һәм «Mordovinische Volkdishtung» җыентыгына, соңрак УПТМН сериясендә чыккан томнарның берсенә кертелгән «Анюрка» дигән җырда башкортларның мордва кызын кодаларга килүләре хакында сөйләнә.

Вай, симизь, сэвизь Анюркань.
Башкирэнь цера Алимка
Анюркань кедьте кундызе
[Устно-поэтическое...,
с. 331–332].

Тәрҗемәсе:

Шулай Анюрканы ярәштеләр, эчтеләр.
Башкорт егете Алим
Анюрканы кулыннан җитәкләп алды.

Күпмилләтле мохиттә тел һәм дини аермалар яшьләр өчен үтеп чыга алмаслык киртәгә әверелмәгән. Моның шулай булуын югарыда китерелгән шушы җырның эчтәлеге үк раслый. Кияү егете Алим, анасына мөрәҗәгать итеп, кәләшнең «хак динне һәм телне белмәвенә карамастан» [Устно-поэтическое..., с. 332], өйләнешер өчен аларга үз фатихасын бирүен сорый. Бу – дустанә этносара мөнәсәбәтләрнең мордва халык иҗатында чагылыш табуы. Туй тематикасына багышланган фольклор әсәрләрендә мордваларның Урта Иделдә яшәүче халыклар, бигрәк тә татарлар белән төрле характердагы тыгыз бәйләнешләре хакында мәгълүматлар теркәлгән. Әйтик, «Кемаля» дигән җырдан шул аңлашыла:

татар егетенең мордва кызына күзе төшкән.

Татаронь цера яки мельганзо,
Татаронь цера – Мишань Кондратей.
[Устно-поэтическое..., с. 239].

Тәрҗемәсе:

Ул кыз артыннан татар егете йөри –
Татар егете Мишин Кондратий.

Этносара мөнәсәбәтләрне, катнаш гаиләләр корылуны, татарлар белән мордвалар арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне тасвирлаган башка җырлар да җитәрлек. Мәсәлән, «Велесь паро Вишка Бозаев» («Зур матур авыл Бозаево») дигән җырда рус, татар, мордва милләтеннән булган кешеләрнең бер авылда яшәве хакында сөйләнә. Шунда берсеннән-берсе сылу тугыз җиткән кызы булган татар гаиләсе бар, авыл халкының һәркайсы шул гаилә белән туганлашырга тели икән:

Вай, мезде козя Макаров татар?
Вай, колмо саень сонзэ поланзо,
Колмо вейксэть тейтерь тяканзо.
Вай, васень поланть,
Вай, вадрят, вадрят тейтерь каканзо,
Омбоце поланть, омбоце вастанть
Седеяк вадрят тейтерь каканзо.
Колмоце поланть, колмоце вастанть
Ещёяк вадрят тейтерь тяканзо
[Евсевьев, с. 39].

Самара өлкәсендә көн күрүче мордваларның поэтик иҗатында кәләшнең татар кызы булуы хакында сөйли торган туй җыры тулы бер цикл тәшкил итә. «Татарава» («Татар кызы»), «Нулы-валы» («Җилфер-җилфер»), «Равжась» («Кара чәчле кыз») – әнә шундыйлардан. Фольклорда мордваларның татарларга карата яхшы, мәхәббәтле мөнәсәбәте, яшьләр арасында әлеге мөнәсәбәтләрнең никах җепләре белән дә бәйләнүе чагыла. Күршеләр булып озак яшәү, дәвамлы этносара бәйләнешләр нәтиҗәсендә мордва халкының шигъри иҗатында татар милләтеннән булган кешенең уңай образы формалашкан. Китерелгән материаллар әлеге тезисны раслый.

Бу яктан караганда Самара өлкәсендә башка халыклар арасында сибелеп яшәүче эрзяларның туй фольклоры гаять үзенчәлекле. Биредәге эрзяларда лирик характердагы туй җырлары цикллардан гыйбарәт. Әлеге җырларда эрзяга кияүгә чыккан татар кызының матурлыгына дан җырлана, ят эрзя гаиләсенә төшкән кызның чын күңелдән борчылулары турында сөйләнә [Чувашев, с. 47–50]. Җырның мордва фольклоры өчен традицион башламнан гыйбарәт беренче юллары түбәндәгечә яңгырый:

Нулы-валы татаравань пацязо,
Шульдерь-кальдерь татаравань грушандо
[Чувашев, с. 48].

Тәрҗемәсе:

Татар кызының яулыгы җилферди,
Татар кызының талир тәңкәләре чыңлый.

Җырның бу өлешендә гапгади тел чаралары ярдәмендә үзе белән бәйле яңа хәлдән дулкынланган кәләш образы тасвирлана. Күз алдына яулыклы кәләшнең сурәтен китереп бастыру белән бергә кәләш толымындагы чулпылар чыңлавын да ишеткән кебек буласың, күреп тә, ишетеп тә була торган образ барлыкка килә

кебек. Мордва милли фольклорында катнаш никахлар тыелмый, киресенчә, алар милли аңда уңай үрнәк сыйфатында ныгып, канун төсен ала.

Кәләш образын барлыкка китерүгә хезмәт итә торган поэтик троплар бик кызыклы. Кызның матурлыгын аерып күрсәтү өчен чагыштырулар, табигать белән янәшә куеп тасвирлаулар кулланыла. Әйтик, җырда шигъри чагыштырулар бер рәт булып тезелә: *Виде килей татаравань сэрезэ, килей тарадт татаравантъ кедьнензэ, килей цицевтт татаравантъ сурнензэ* («Татар кызы-кәләшнең буе төз каендай, бояр кызы-кәләшнең куллары – каенның сыгылмалы ботаклары, татар хатынының бармаклары – каен алкалары») [РФ НИИГН Л-397, с. 35]. Биредә «*килей цицевт – сурнензэ*» («бармаклары – каен алкалары») чагыштыруын гына алсак та, сурәтлелекнең бик югары һәм төгәл булуына игътибар итәрлек. Халык эстетикасы күзлегеннән караганда, мөгаен, моннан да аңлаешлырак чагыштыруны табуы кыендыр. «Килей» лексик кабатлануы кызның тышкы кыяфәтенә игътибарны юнәлтә, аның психологик халәтен характерлап бирә. Әлеге туй җырында кәләш образын тудыруда каен кәүсәсе, каен ботагы, каен алкалары – барысы бергә гаять кызыклы ассоциатив рәт барлыкка китерә [Рогачев, с. 219].

Каен Россия халыклары поэтик символикасында бик еш очрый. Үзенең тикшеренүләрендә бу хакта татар галиме К.М. Миңнуллин әйткән иде: «Идел-Урал төбәгендә яшәүче халыклар өчен каен – бик киң таралган уртак символ ул» [Миннуллин, с. 34]. Әлеге символның барлыкка килүе очраклы түгел. Мәсәлән, чувашларда каен хатын-кыз белән ассоциальләшә, чөнки мәҗүсилек чорыннан аларга *ама-хуран* – каен-ана [шунда ук] билгеле. Мордваларда әлеге образ никах бөтенлеге, гаилә иминлеге сагында тора, үрчем өчен җаваплы символ. Татар халык поэтик иҗатында каен «..матур, сылу кыз, гомумән яшьлек символы буларак чыгыш ясый» [шунда ук]. Сүз уңаеннан әйткәндә, «каен агачы» мәгънәсендәге *килей* (мордва телендә), *каен* (татар телендә), *кайын* (башкорт телендә) сүзләре бер-берсенә аваздаш, димәк, бу сүзләрнең табигате санап кителгән өч телнең өчесендә дә бертөрле булу ихтимаы зур. Кәләш образын бирүдә шушы ук җырдагы башка мисалларга тукталып үтик:

Сиянь копийкат бояравань кенжензэ
[РФ НИИГН Л-397, с. 35].

Тәрҗемәсе:

Бояр хатыны-кәләшнең тырнаклары
көмеш тәңкәләр кебек.

Тырнакларны көмеш тәңкәләр белән чагыштыру да очраклы түгел: мордваларда көмеш иң үтемле металл бизәнү әйбере булып саналган. Җирле зяркяннәр аннан балдак, алка, беләзек, тарак, чулпылар ясый торган булганнар. Шуның өстәвенә мордва хатын-кызларының элек заманда көмеш чыбыктан кисеп ясалган озынча формалы тәңкәләре тырнак пластиналарын хәтерләткән.

Көмешне матурлык символы буларак кабул итү поэтик аңда бик күптәннән формалашкан.

Югарыда китерелгән җырның бер вариантында шәрык гүзәле-кәләшнең кул бизәкләренә игътибар юнәлтелә: *Кетькскеде пешксеть татаравань кедензэ, суронде пешксеть татаравань сурксkеде* («Татар кызының кулына беләзекләр тагылган, татар кызының бармаклары тулы йөзекләр») [РФ НИИГН Л-397, с. 35].

Халык поэзиясендә кәләшнең тышкы кыяфәте генә түгел, күңел халәте дә тасвирлана. Мордва фольклорының үзенчәлеге образны геройның эчке кичерешләре аша ачарга омтылудан гыйбарәт. Безнең очракта исә, чит мохиткә килеп эләккән җиткән кыз бик катлаулы хисләр кичерә, борчыла, елый. Кәләш образы композицион яктан кияү егете образы белән тиңләштерелә:

Вай, ки неизе татарава аварьди,
Вай, эсь полазо татаравань неизе,
Вай, эсь вастазо татаравань маризе.
[РФ НИИГН Л-397, с. 35].

Тәрҗемәсе:

Кем күргән татар-киленнең күз
яшьләрен?
Аһ, аны татар-киленнең ире күргән,
Аһ, татар-киленне (аның елавын)
ире ишеткән.

Диалог формасында төзелгән җырлар – поэтик авыз иҗатында сирәк очрый торган төр. Биредә ул яшь хатынның эчке кичерешләрен тыңлаучыга бөтен тирәнлеге белән төшендереп бирергә ярдәм итүче янә бер персонажны сюжетка кертү максаты белән кулланылган. Җырның тәэсирлелеге адресатка юнәлтелгән сүзләрнең уңай мөнәсәбәтле булуын аңлауны тәэмин итә. Экспрессия җырга теләктәшлек күрсәтү, хөрмәтләү обертоннары өсти. Әсәр өчен сайлап алынган тел-сурәтләү чаралары сәнгатьчә куелган бурычларны җиренә җиткерергә булыша. Җырда очрый торган *поланякай*, *вастынем* кебек синоним сүзләр иркәләү-кечерәйтү формасында бирелгән һәм ирнең хатынын яратуын, аны кайгыртуын ассызыклыйлар. Яшь хатынының чит гадәтләрне белмәм инде, дигән зарына каршы ир үз диненең һәм анасы гадәтләренең икмәк кебек, җирдә крестьян тормышы кебек үк бик тә гади, һич катлаулы түгеллеген аңлата, хатынына ипләп кенә үзендәге тәртипләрне төшендерә:

Уштыкая сонзэ писи пецьканзо,
Пидикая сонзэ свежа ямонзо,
Паникая сонзэ чевте кшининзэ.
Ацыкая сонзэ чевте тарканзо,
Мацтикая чокшне позда толнензэ
[РФ НИИГН Л-397, с. 35].

Тәрҗемәсе:

Мичен ягып җибәр син аның
(анамның),
Аш пешереп куй син аңа,
Йомшак икмәк пешерерсең,
Ә миңа йомшак итеп урын җәеп бир,
Кич җиткәч, утын сүндерерсең.

Тирән фәлсәфи фикер белән сугарылган мордва халык җырында героиняның тышкы кыяфәте, милли үзенчәлекләре, кием һәм бизәнү әйберләренең үзенчәлеген ачык итеп күрсәтү генә түгел, ә аның катлаулы хәле, эчке кичерешләре, күңел халәте дә

чагылыш тапкан, моңа ирешү өчен адекват сәнгать-сурәтләү чаралары файдаланылган [Рогачев, с. 221]. Җырда әйтелгән төп фикернең тыңлаучы көткән нәтиҗәләргә яраштырып төзелгән эчтәлеге вакыйгаларны барлык тулылыгы белән ача.

Туй фольклорында милләтара никахлар темасын киң планда ачып бирү мордва тел-авыз поэтик иҗатында татарларның объектив сурәтләнүен күрсәтә, мордвалар белән янәшә Идел буенда гасырлар буена дус-тату яшәүче этносның уңай образы тудырылуы хакында сөйли. Бу исә мордваларның күрше этнослар тормышына табигый рәвештә керешүләрен, аларның рухи культурасында җиңел ориентлашуын, тел каршылыгы булмауны, диннәрен, гореф-гадәт, йолаларын, милли кыйммәтләрен хөрмәт итүгә дәлил булып тора [Рогачев, с. 221].

**Әдәбият**


*Евсевьев М.Е.* Народные песни мордвы // Евсевьев М.Е. Избр. тр.: в 5 т. Саранск, 1963. Т. 2. 528 с.

*Миннуллин К.М.* Общая символика в песенной поэзии народов Поволжья и Приуралья // Типология татарского фольклора. Казань, 1999. С. 32–48.

*Рогачев В.И.* Свадьба мордвы Поволжья: обряд и фольклор (историко-этнографические, мифологические, региональные и языковые аспекты). Саранск: Мордов. кн. изд-во, 2004. 384 с.

РФ НИИГН Л-397.

Устно-поэтическое творчество мордовского народа: в 18 т. Эпические и лиро-эпические песни. Саранск: Мордов. кн. изд-во, 1963. Т. 1. 400 с.

*Чувашев М.И.* Духовное наследие народов Поволжья: живые истоки / М.И. Чувашев, И.А. Касьянова, А.Д. Шуляев и др. Самара: Изд-во СамГПУ, 2001. 536 с.



***Рогачев Владимир Ильич,***

*М.Е. Евсевьев исемендәге Мордва дәүләт педагогика институты профессоры, филология фәннәре докторы*

*e-mail: rogachev-v@bk.ru*

УДК 398=512.145

***Л.Х. Дәүләтшина***

# ХАЛКЫБЫЗНЫҢ ДИНИ-МИФОЛОГИК КҮЗАЛЛАУЛАРЫ
## (материал туплау өчен сораулык)

Публикуется вопросник для сбора материала по традиционным религиозно-мифологическим представлениям татар, освещающий основные термины; категории мифологических персонажей, их функции; представления, связанные с окружающим миром, смертью, душой, магическими практиками. Основа вопросника – собственный полевой опыт автора и опубликованные источники.

**Ключевые слова:** традиция, обряд, мифология, мифологические представления, мифологический персонаж, верования.

Мифология халык иҗатының иң борынгы катламын тәшкил итә. Күп гасырлар элек, кешенең әйләнә-тирә дөнья, тирәлек турындагы фантастик күзаллаулары нигезендә, күпсанлы ышанулар, йола-ритуаллар туган. Кеше әле бу вакытта үзен табигать дөньясыннан аерып карамаган һәм әйләнә-тирәсендәге барлык җанлы һәм җансыз әйберләрне «җанландырган», аларны үзе кебек яши, кайгыра, көлә, сөйләшә белә дип исәпләгән. Утның да, суның да, җирнең дә җаны бар дип уйлау төрле аллалар һәм ияләр турындагы ышануларның барлыкка килүенә сәбәп булган.

Фольклористикада татар халкының мифологик мирасын югары мифологиягә һәм түбән мифологиягә бүлеп карау кабул ителгән [Бакиров, Урманчеев]. Югары мифология мәҗүси Аллалар (Тәңре, Җир-Су, Умай, Алас һ.б.) турындагы ышанулар һәм хикәятләр берлегеннән гыйбарәт булса, түбән мифология Алла статусына ия булмаган ияләрне, кара көчләрне һәм рухларны берләштерә. Ияләр табигать объектларының, кеше яши торган торак урыннарының хуҗасы буларак кабул ителә һәм, күңелләрен күрә белсәң, кешегә файдалы затлар буларак күзаллана. Җен, албасты, убыр, өрәк, шүрәле һ.б. шундый түбән рухлар адәм баласының тормышында туган күңелсезлек, бәхетсезлек, акылдан язу, адашу кебек күренешләрнең сәбәпчесе итеп уйланыла.

Бүгенге көндә югары мифологиягә караган аллалар турындагы ышануларның бик аз сакланган булуы татар халкының мифологик системасын өйрәнүчеләр алдында кыенлыклар китереп чыгара. Халыкның мифологик күзаллауларын ачыклау юнәлешендә төп чыганак булып түбән мифологиягә караган ияләр, рухлар турындагы ышанулар, әйләнә-тирә дөнья турындагы карашлар төп чыганак ролен үти. Татар халкының гына түгел, башка халыклар мифологиясе дә мифологик персонажлар турындагы күзаллаулар, алар белән бәйле мотив, функцияләрне үз эченә алган катлаулы система

буларак билгеләнә. Өйрәнү объектын тәгаенләштерү материалның чикләрен дә киңәйтеп җибәрә. Мифологик персонажларга бәйле традицион рәвештә өйрәнелә торган жанрлардан (сөйләкләр, әкият, риваять, легенда) тыш, эзләнүләр барышында ырым текстларын, йола гадәтләрен (йорт иясен яңа йортка күчерү, йорт иясенә ризык кую, җен алыштырган баланы кайтару, йорттан җен куу һ.б.), көндәлек тормыш белән бәйле гадәтләрне (су аркылы чыкканда җеп ташлау; мунчада әйбер калдырып чыгу, җен түкермәсен өчен ризык өсләренә ябу һ.б.) ышану, тыюлар, табышмак, мәкаль, әйтем кебек жанрларны исәпкә алу да бик мөһим.

Бер локаль традициягә хас булган мифологик күзаллауларны туплаганда, персонажның (күренешнең) исеме, кыяфәте, җенесе, күренү урыны, вакыты, танып булу мөмкинлеге, аның функцияләре, кешегә булган мөнәсәбәте, кешенең аңа карата кылган гамәлләре һ.б. барланырга тиеш. Мифологик персонажны бу юнәлештә өйрәнү схемасы 1980 елларда Россия Фәннәр академиясенең Славян белеме һәм балканистика институты галимнәре тарафыннан эшләнгән иде [Виноградова, с. 40–44]. Эзләнүләрне әлеге юнәлештә алып барганда, билгеле бер локаль традиция өчен хас булган күзаллаулар системасын ачыклау мөмкинлеге туа. Бу, үз чиратында, чагыштырма анализ өчен җирлек булып тора һәм татар халкының билгеле бер этник төркеменә караган фольклорда барлыкка килгән төрки нигезле һәм алынма элементларны ачыкларга мөмкинлек бирә.

Биредә тәкъдим ителә торган сораулык югарыда әйтелгән үзенчәлекләрне истә тотып төзелде, һәм ул экспедицияләрнең уңай тәҗрибәсенә нигезләнгән материалларны үз эченә ала. Әлбәттә, әлеге сораулар татар халкының мифологиясен тулаем бер система буларак өйрәнүдә беренче адым гына, аны алга таба җыелачак материалларга таянып тулыландырырга, татар халкының башка этнотерриториаль төркемнәренә яраклаштырырга кирәк. Кулланылыш даирәсе ягыннан сораулык Урта Идел буенда яшәүче татарларны күз алдында тотып төзелгән. Бу, әлбәттә, татарлар яшәгән башка төбәкләрдә аны кулланырга ярамый дигән сүз түгел, әмма башка төбәкләрдә эш алап барганда, сораулар исемлеген җирле үзенчәлекләрне истә тотып тулыландыру сорала.

**Әйләнә-тирә дөнья**

1. Дөнья кайчан һәм ничек барлыкка килгән?

2. Без яши торган дөнья барлыкка килгәнче нәрсә булган?

3. Дөнья ничә өлештән тора? Күк, җир, җир асты дөньялары юкмы?

4. Күктә кем дә булса яшиме? Күкнең хуҗасы бармы? Күктә булган кешеләр турында сөйләмиләрме?

5. Күкне җир белән нәрсә тоташтыра?

6. Күк капусы нәрсә ул? Күк капусы ачылса, нәрсә була?

7. Яңгыр, кар, күк күкрәү кебек табигать күренешләрен кем

булдыра? Күк хуҗасымы ул, әллә аларның һәрберсенең хуҗалары бармы? Күккә атап нәрсәләр әйтәләр?

8. Кеше яңгырны, карны туктата аламы? Бик куркыныч килә торган яңгырны ничек дип атыйлар? Аны туктатыр өчен нәрсәләр эшләргә кирәк? (ишек алдына көрәк, табагач ташлау, таяк белән селтәнү, догалар уку). Яңгыр булмаса, кояш чыкмаса, балалар нәрсәләр әйтәләр?

9. Яшен суккан кешеләр турында сөйлиләрме сездә? Яшен суккан кешене нишләтәләр? Яшен кайдан килеп чыга? Кемне сугарга мөмкин? Гөнаһлы кешене түгелме?

10. Беренче яшенне ишеткән кеше нишләргә тиеш (җирдә тәгәрәү, таш ату, юыну һ.б.)? Яшеннән курыкмас өчен нишлиләр? Яшен суккан агачның аерым исеме булганмы? Андый агачтан йорт салырга ярыймы? Яшеннән кайда качып була? Ничек сакланырга кирәк (ишек, тәрәзәләрне ябу, тәрәзәләргә ботаклар элү һ.б.)?

11. Озак вакытлар яңгыр яумаса, нишләргә кирәк? Яңгыр боткасы пешерү, авылны әйләнеп җир сөрү, кырмыска оясына су сибү һ.б. Аларны ничек башкаралар?

12. Корылык булса, үлгәннәргә мөрәҗәгать итмиләрме? Зиратта дога кылу, үз үлеме белән үлмәгән кешеләрнең каберләренә су салу гадәте юкмы? Корылык булмасын өчен нәрсәләр эшләргә кирәк?

13. Аҗаган нәрсә ул? Аны күргән кеше юкмы? Күргән кеше белән берәр хәл булмыймы? Ни сәбәпле була ул?

14. Яңгырдан соң чыккан салават күперен ничек аңлаталар? Ни өчен чыга ул? Аның өстендә кем дә булса йөрмиме? Ике башында Хозыр белән Ильяс утыра дип әйтмиләрме?

15. Җир асты дөньясы бармы? Анда кереп буламы? Тере кешеләр керә аламы анда? Үлеләрне ни өчен шунда күмәләр? Җир астына төшеп кире кайткан кешеләр турында сөйлиләрме сездә?

16. Җир асты дөньясының хуҗасы бармы? Аны ничек атыйлар? Нәрсәләр эшли ул? Җир тота дип әйтмиләрме сездә?

17. Җир Анасы бармы? Беренче тапкыр чәчүгә чыкканда, аңа мөрәҗәгать иткәннәрме? Җиргә нәрсә сипкәннәр (йомырка, ипи һ.б.)? Беренче буразна алдыннан суканы май белән сөртәләрме? Чәчүгә иң алдан чыккан кешегә авыл кешеләре йомырка бүләк иткәннәрме? Игенче нинди сүзләр әйткән?

18. Утның җаны бармы? Аның иясе бармы? Утның балалары бармы? Утка атап берәр нәрсә әйтмиләрме? Утны үрләтер өчен нәрсә дигәннәр? Утка тырнак якканда нәрсә дип әйтәләр? Утка ризык салмыйлармы? Утны йолаларда кулланалармы (яшьләрне ут аша сикертү, кешене җирләп кайтканнан соң мичкә ягу, яшь киленнең мичкә кагылуы һ.б.)? Ут җеннәрдән саклыймы?

19. Кеше кайдан барлыкка килгән? Кем ясаган аны? Хәзерге кешеләргә хәтле Алыплар булган дип әйтмиләрме сездә? Кешегә җанны кем өргән? Яхшы һәм начар кешеләрне, ир-ат һәм хатын-кызларны аерым ясамаганнармы?

**Иялəр, түбəн рухлар**

20. Табигатьтəге төрле күренешлəрнең иялəре бармы? Нəрсəлəрнең иялəре була? Алар ничек барлыкка килə? Таш, кое, чишмə иялəре бар дип əйтмилəрме сездə?

21. Сездə йорт иясен ничек атыйлар? (йорт иясе, йорт хуҗасы, нигез хуҗасы, кырсут). Ул кешегə күренəме? Нинди кыяфəттə күренə? (кеше, хайван, əйбер). Йорт җыланы бар дип əйтмилəрме сездə? Йорт иясен ничек танып була? (яше, буе, киеме, тышкы кыяфəте, тəн зəгыйфьлеге)?

22. Йорт иясе кайда яши (идəн асты, мич, йорт почмаклары)? Сез аны ашатасызмы? Ашатсагыз, нəрсə ашатасыз (ботка, ипи һ.б.)? Ризыкны ничек əзерлисез, аның кулəме? Аны ничек ризалатасыз? Аңа атап дога кыласызмы, сəдака бирəсезме?

23. Кайсы вакытта кешегə күренə ул? Төнлə чыгып нəрсə дə булса эшлəп йөрмиме (савыт-саба шылтырата, йон эрли, елый, бəла килəчəген хəбəр итə һ.б)? Ул йөргəндə нинди авазлар ишетелə?

24. Йортта ызгышсаң, сызгырсаң, йорт иясе ташлап китə дип əйтмилəрме?

25. Йорт иясенең гаилəсе, балалары бармы? Йортта ул ничек барлыкка килə? Аны үстереп буламы? Ата-бабаларның үлгəннəн соң кайткан җаны түгелме ул?

26. Яңа йортка күчкəндə йорт иясен күчерəсезме? Ничек күчерəсез? Иске йорттан чыгып китəр алдыннан сез аны ничек чакырасыз? Үзегез белəн нəрсə дə булса аласызмы? Көннең кайсы вакытында күчерəсез? Аны алып барганда сөйлəшергə ярыймы? Яңа йортта нигез боткасы пешерəсезме? Йорт иясен күчермəсəң, нəрсə була? Төп йорттан башка чыкканда, яңа өйдə йорт хуҗасы ничек барлыкка килə? Күчермəсəң, ташландык нигездə елап утыра дип əйтмилəрме аны?

27. Йорт иясе кешегə ярдəм итəме? Ничек ярдəм итə (көтүгə уята, килəчəкне юрый, йорт эшлəрен эшли, авырулардан саклый)? Йорт иясе нəрсəгə кирəк? Ул булмаса, йорт нишли?

28. Кешегə зыян салмыймы ул? Йоклаганда баса дип əйтмилəрме аны? Хатын-кызлар белəн яшəмиме ул? Югалган əйберне эзлəргə булышмыймы?

29. Мунча иясе бармы? Аның кыяфəте нинди? Елан, мəче кыяфəтендə күренмиме ул?

30. Мунчада ул кайда яши? Кергəндə, аның белəн исəнлəшергə кирəкме? Чыкканда рəхмəт əйтəлəрме? Аның өчен чиста сөлге элеп куймыйлармы? Мунчаны чиста тотарга кирəкме? Нинди утын яксаң, мунча иясенең ачуын чыгарасың? Мунчага кайсы вакытта керергə ярамый? Ярамаган вакытта керсəң, мунча иясе нишлəтə? Элек баланы мунчада тапмаганнармы? Мунча иясе балага тимиме? Җен алыштырган баланы кире кайтарыр өчен мунча тупсасына салып кыйнамыйлармы?

31. Мунча иясе үзен ничек белдерə? Ул мунчада нəрсəлəр эшли? Мунча иясенə ризык куялармы?

32. Кияү мунчасы кергəннəн соң, мунча иясенə бирəр əйбер

калдыралармы? Мунча иясенә атап сүз әйтәсе түгелме?

33. Мәетне мунчага алып керергә ярыймы? Аны юар өчен кирәк булган әйберләрне мунчадан алырга ярыймы? Мунчада дога кылырга ярыймы? Элек озак авырган кешене мунчага кую гадәте булмаганмы?

34. Ташландык мунчаларда җеннәр җыелмыймы? Алдагы тормышны юрау ырымнарын мунчада башкармыйлармы? Мунчада кычкырышырга ярыймы?

35. Хозыр Ильяс кем? Нинди кыяфәттә була ул? Аның Хур кызы исемле сеңлесе бар дип әйтмиләрме?

36. Кайда очрый ул кешегә? Хозыр Ильяс юлда йөри дип әйтмиләрме? Юлчыларга ярдәм итәме ул?

37. Хозыр Ильяска корбан бирү гадәте юкмы? Бәрәңге казыганда берничә төпне казымыйча калдырмыйлармы? Җир сөргәндә, әйбер утыртканда Хозыр Ильяска мөрәҗәгать итәләрме?

38. Хозыр җир иясе, Ильяс су иясе түгелме? Хозыр Ильяс ул бер үк кешеме? Хозыр Ильяс йорт хайваннарын саклыймы? Ул абзарда яшәмиме?

39. Хозыр Ильяс камчысын селтәсә, яз килә дип әйтмиләрме? Су аркылы чыкканда, Хозыр Ильяс кырга ташласын, дип әйтмиләрме?

40. Беренче көтү куганда, Хозыр Ильяска мөрәҗәгать итмиләрме? Хәер биреп (сөт өсте, сөт, йомырка) дога кылу гадәте юкмы?

41. Юлчыларга ул кайсы вакытларда очрый? Ничек ярдәм итә?

42. Йортыңа карт кеше, хәерче килеп керсә, аны борып чыгарырга ярыймы? Куып чыгарган кешеләрне Хозыр Ильяс каргый икән дип әйтмиләрме?

43. Су хуҗасы, Су иясе бар дип әйтәләрме? Ул нинди кыяфәттә була? Ир-атмы, хатын-кызмы? Су иясе кеше, хайван кыяфәтенә керә аламы? Су сыеры, я Кара Үгез бармы? Судан хайван кыяфәтендә чыгалармы алар? Кайда яшиләр? Кеше йөрмәгән елгаларда түгелме? Төнлә тавышы ишетелсә, нәрсә аңлата?

44. Су аркылы чыкканда, нәрсә дип әйтәсез? Яшь киленгә су юлы күрсәтәләрме?

45. Су иясе нәрсәләр эшли (үзенә тартып ала, кешене су тота)? Су тотканда кайсы урын авырта?

46. Су иясен ничек ризалатасыз (дога кылу, суга җеп, яфрак агызу, суга корбан бирү, тоз, ярма сибү)?

47. Елга буена чыгамы ул? Чәчен тарарга чыкканын күргән кеше бармы? Күргән кешегә нәрсә була?

48. Төнлә су коенырга, су эчәргә ярыймы? Кызларга кояш баегач, елга ярына төшәргә ярыймы?

49. Су иясе кайда яши? Кыш көне кая китә? Су иясенең гаиләсе, балалары бармы?

50. Суга әйбер салу, корбан бирү гадәте бармы? Корбан бирмәгән кешегә нәрсә була? Яз көне ташу киткәннән соң, суга корбан бирәсе түгелме? Су коена башлагач, Су иясе бер кешене үзенә ала дип әйтмиләрме?

51. Суга беренче тапкыр яңа көймә төшергәндә, Су иясенә әйбер бирү гадәте бармы? Балык күп тотылсын өчен нишләргә

кирәк? Балыкчы балыкны башкалардан күбрәк тота торган булса, ул кеше турында нәрсә диләр?

52. Мал иясен ничек атыйлар (мал иясе, сарай иясе, Пәша Ана, Зәнги баба, Гамбәр Ана һ.б.). Кош-кортларның, эре терлекнең ияләре аерыммы?

53. Мал иясе кайда яши? Абзарга кергәндә, исәнләшеп керәсе түгелме?

54. Мал иясенә атап корбан чалмыйсызмы? Аңа ризык куймыйсызмы? Маллар кысыр калса, иягә атап әйбер бирәсезме?

55. Зәнги бабага атап угыз боткасы пешермисезме? Хайваннарга ашатыламы ул?

56. Гамбәр ана бар дип әйтмиләрме сездә? Кошка әверелә, хатын-кызларны яклый димиләрме аны? Кош рәвешендә улын эзли икән дип әйтмиләрме? Аңа дип, яз көне киртә башларына ризык куеп чыкмыйлармы?

57. Мал иясе йортта ни өчен кирәк? Ул хайваннарга нинди очракларда ярдәм итә? Нинди очракларда зыян сала? Хайван килешә-килешми дип ничек юрыйсыз?

58. Яңа йорт салып чыкканда яисә яңа абзар төзегәч, Мал иясен күчермисезме?

59. Йорт хайваннары ничек барлыкка килгән? Алар арасында изгеләре бармы? Ашарга ярамаган хайваннар бармы?

60. Урман иясе буламы? Ул нинди кыяфәттә, кайчан күренә?

61. Урманга кергәндә Урман иясе белән исәнләшү, аннан рөхсәт сорау гадәте бармы? Урманга кергәндә Урман иясенә атап теләкләр әйтелмиме? Урман иясенә ауга баргач, бүләк калдыру гадәте юкмы? Аңа бирәр әйбер калдырасы түгелме (сәдәп, җеп)?

62. Урман иясе аучыга күренәме? Урман иясе кешеләрне адаштырмыймы? Урманда кычкырып сөйләшергә ярыймы? Аучыларга бер-берсенең исемен атарга ярыймы? Хайваннарның исемен әйтергә ярыймы?

63. Урманда ятып йокларга ярыймы? Кече йомышны йомышларга ярыймы? Урманда кунарга кирәк булса, Урман иясеннән рөхсәт сорарга кирәкме? Башны капламыйча урманга керергә ярыймы?

64. Урманда җиләк җыйганда әйтелә торган махсус сүзләр юкмы?

65. Шүрәлене күргән кеше юкмы? Шүрәле кем ул – Урман иясеме? Шүрәледән ничек качып була? Очраса, кешеләрне нишләтә ала?

66. Шайтан нәрсә ул? Нинди кыяфәттә? Кайда очрый? Нинди гамәлләр кыла? Су өсләрен төнгә ачык калдырсаң, шайтан төкергән димиләрме?

67. Шайтан кешеләргә, йорт хайваннарына тимиме? Кайда очрый? Йорт хайваннары авырса, аларга шайтан тигән димиләрме?

68. Албасты нинди кыяфәттә була? Кайда очрый? Аны ничек танып була? Ул кешегә зыян кыламы? Бала тапкан аналарның балаларын алмыймы ул? Йоклаган кешеләрне нишләтә? Авырлы хатыннарга тияме?

69. Албастыдан ничек котылырга мөмкин? Бастырылганда нәрсә дип әйтергә кирәк?

70. Сездә адаштыра торган урыннар бармы? Кем адаштыра анда? Кайсы вакытта очрый ул?

Нинди кыяфәттә очрый? Берәр тавыш чыгармыймы? Аны ничек дип атыйлар? Бу урынның исеме ничек? Нинди ул? (юл чаты, урман уртасы). Җен белән очрашкач нишләргә кирәк? (киемне әйләндереп кияргә, сүгенергә). Нинди кыяфәттә күренә ул? (ут, печән чүмәләсе). Кешегә очрагач, ул аны нишләтә? Бозамы, чирләтәме?

71. Баланы ана карыныннан урлау очраклары булганмы? Аны ничек дип атаганнар? «Җен алыштырган» димәгәннәрме? Кире кайтарыр өчен нәрсә эшләргә кирәк? «Алмаштырылган» бала үзен ничек тота? Ул яши аламы? Тумаган баланы анасының карыныннан урлау очраклары булганмы? Булса, халык аны кем урлаган дип әйтә? Баланы җен алыштырмасын өчен нәрсә эшләргә кирәк? Карында үлгән бала яисә үле туган бала турында нәрсә диләр? Ул җенгә әйләнмиме? Алыштырган баланы кире кайтарып буламы?

72. Төнге уникедә мунча керергә ярыймы? Җеннәрнең кешене мичкә тыгып кую очраклары булмаганмы? Зәхмәт кагылган дип әйтмәгәннәрме? Җеннәр мунчада пәри туе үткәрмәгәннәрме?

73. Җен ничек барлыкка килә? Бәдрәфтә туалар, дип әйтмиләрме? Хайван күмелгән урын зәхмәтле урын түгелме? Канлы, әшәке урыннарга җеннәр җыела дип әйтмиләрме?

74. Төнлә урамда йөрергә ярыймы? Кемнәрне очратырга мөмкин?

75. Урамдагы җил өермәләрен җен туе, пәри туе дип әйтмиләрме? Кеше яши торган йортка җеннәр керә алмыймы? Керсә, аны ничек куып чыгарырга мөмкин? (мылтык ату). Җен кермәсен өчен нишләргә кирәк? (ризыкның өстен каплау, тәрәзәләрне каплау, морҗа тишекләрен ябу).

76. Урамда тузан өермәсен күрсәң, аны нәрсә дип әйтәләр? Җен өермәсе дип атамыйлармы?

77. Убыр бар дип әйтмиләрме сездә? Ул нинди кыяфәттә була? Кайчан күренә? Убыр сихерчеләр яисә үз-үзләрен үтерүчеләрнең җаны түгелме?

78. Убыр кешеләрнең, хайваннарның канын эчмиме? Аның белән очрашсаң, исән калып буламы? Кешеләрне бозмыймы ул?

79. Сыерларның сөтен имә димиләрме аны? Балаларны ана карыныннан урламыймы? Ирләргә бәйләнмиме? Юлларда кешеләргә очрап, аларны адаштырмыймы?

80. Убыр женнәр белән очрашмыймы? Белемнәрен кайдан ала? Кеше ничек Убырга әйләнә? Убырны ничек танып була? Ул хайван кыяфәтендә йөрмиме? Ут кыяфәтендә морҗа тишегеннән чыгып йөри димиләрме?

81. Убыр кайсы вакытта кешегә күренә? Хатын-кызмы, әллә ир-атмы ул? Хатыны Убыр икәнен ире белеп яшиме? Убыр аңа зыян салмыймы?

82. Убырдан ничек сакланып була? Аны күрсәң, нишләтергә кирәк? Үлгәннән соң Убыр нишли? Яңадан чыгып йөри аламы ул? Үлгәч, кем Убырга әйләнергә мөмкин (сихерчеләр, кеше үтерүчеләр, балаларны яратмый торган кешеләр)?

83. Үле кешенең Убыры чыга, дип әйтмиләрме? Убыр тереннеке, үленеке булмыймы?

84. Зират иясе бар дип әйтәләрме? Зиратта кем дә булса яшиме (җен, гаип ирәннәр)? Зиратка кергәндә нәрсә дип әйтергә кирәк? Көлергә, кычкырып сөйләшергә ярыймы? Төнлә зиратка керсәң, нәрсә була? Хатын-кызга кайсы вакытта керергә ярамый? Зираттан чыкканда, нәрсә дип китәргә кирәк? Борылып карарга ярыймы? Адашкан кешене, атны керәшен зираты тирәли әйләндермиләрме?

**Гадәттән тыш сыйфатларга ия кешеләр**

85. Сездә кешеләргә бозым сала торган, чир китерә торган кешеләрне ничек атыйлар? Алар нинди була? Белемнәрен кайдан ала? Кешеләргә карата нинди гамәлләр кыла? Сихерчеләр хайваннарга әйләнә аламы? Кешеләрне, хайваннарны боза аламы алар? Бозсалар, нәрсә белән боза? Кемнәрне боза? Кемне дә булса бозган очраклар бармы? Бозымны ялгыш кына алган кешеләргә нәрсә була? Белемнәрен ничек итеп икенче кешеләргә тапшыра? Үлә алмый азаплана дип әйтмиләрме аларны? Нинди дә булса хайванга әверелә алмыйлармы алар? Сихерче җил өермәсе белән очып йөрмиме?

86. Төрле авырулардан дәвалый торган кешеләрне ничек атыйлар? Имче карчык димиләрме аларны? Алар кешеләрне, хайваннарны терелтәме? Авылга корылык, пожар, куркыныч авырулар килсә, ул ничек ярдәм итә ала? Бозымны кайтара аламы ул? Берәр әйберне югалтсаң, хайван югалса, табып бирәме? Алга таба нәрсә булачагын әйтә аламы? Андый кешеләрне күрәзәче димиләрме? Кешеләргә ничек ярдәм итә ул? Төшләрне юрый беләме?

**Җан, үлеләр дөньясы**

87. Кешенең җанын ничек атыйсыз? Кеше үлгәч, аның җаны кая китә? Җан кайда була (каш арасында, йөрәктә)? Кеше исән вакытта аның җаны чыгып йөри аламы? Кешенең ничә җаны бар? Кот нәрсә ул?

88. Үлгән кешенең җаны ничек чыга? Җан чыкканын ничек белеп була? Җан чыккач, кая китә (соңгы тамчы су белән)? Теге дөньяга җан китәме, тәнме? Җан да үлә аламы?

89. Мәетнең җаны кайтып йөри дип әйтәләрме? Нинди кыяфәттә кайта (кош, күбәләк)? Кайчан кайта? Нәрсә өчен? Кайсы вакытта?

90. Карындагы баланың җаны бармы? Ул аңа кайчан иңә?

91. Күләгә нәрсә ул? Күләгә кеше тугач барлыкка киләме? Ул кешедән башка яши аламы? Кеше үлгәч, ул кая китә?

92. Йокы нәрсә ул? Йоклаганда кешенең җаны чыгып йөриме? Кеше йоклаганда ни өчен йөри? Аңны югалту вакытында нәрсә була? Мәрткә китү нәрсә ул?

93. Ни өчен игез балалар туа? Аларның икесенә бер җан, дип әйтмиләрме? Игез бала туса, аларны нишләтәләр? Куш багана төбенә куймыйлармы, тәрәзәдән бирмиләрме һ.б.

94. Ни өчен кеше авырый? Авыруны төрле чир ияләре кешегә кертә, дип аңлатмыйлармы? Нинди авырулар ияле була?

95. Үлем нәрсә ул? Ул күзгә күренәме? Аерым зат түгелме ул? Кешенең яшәү вакытын кем билгели?

96. Үлгән кешене ничек атыйсыз (әрвах, мәет)? Кеше үлгәч, я хайванга, я кошка әверелә, дип әйтмиләрме? Кеше берничә тапкыр туа аламы?

97. Үлгән кеше төшкә керәме? Ни өчен керә? Кермәсен өчен нишләргә кирәк (киемнәрен тарату, сәдака бирү)?

98. Мәеттән куркырга кирәкме? Ул кешегә зыян сала аламы? Күмәргә алып барганда, артыннан хатын-кызга барырга ярыймы? Таяк ташлап калдыра дип әйтмиләрме? Авылны чыккач мәетнең юлын бутау гадәте юкмы? Мәетне озатып кайткач, өйдә нинди гамәлләр кылырга кирәк (утын алып керү, мич ягу, моржа ачу һ.б)?

99. Үле туган баланың җаны буламы? Үлгән баланы кем өйдән алып чыга? Анасына зиратка барырга ярыймы? Үлгән балаларның җаны кая китә? Үлгән баланың җаны изге дип әйтмиләрме? Бала тапканда үлгән хатын-кыз кайтып йөрмиме? Кешеләргә начарлык кылмыймы ул?

100. Карындагы баланың җаны бармы? Аңа җан кайчан иңә? Аның махсус атамасы юкмы? Үле туган баланың яисә тугач та үлгән баланың җаны кайтып йөрмиме? Аның елаган тавышы ишетелмиме? Туганда башка кешеләргә кайсыдыр ягы белән охшамаган кеше, үлгәч явыз рухка әйләнмиме (ике йөрәкле, күлмәктә туганнар, кыпкызыл булып туганнар)?

101. Үлгән кеше кире кайтып йөриме? Кемнәр кайта? Ни өчен кайта? Үлгән кешенең җаны кайтуга ризык әзерлисе түгелме? Ишекләрне ачып куясы түгелме? Ничә көн кайтып йөри ул? Йорт капкасына җан адашмасын өчен билге куясы түгелме?

102. Мәет юган суны кая түгәргә кирәк? Мәет үлгәч, кайтып йөрмәсен өчен, нишләргә кирәк (киемен кире ягы белән тегәргә, тәрәзә, көзгеләрне капларга, идәнне түргә таба юарга, өйдән алып чыкканда, аягын алга каратып алып чыгарга)? Кеше үләргә ятканда, ишекләрне бикләргә ярыймы? Әрвахлар кешеләргә яхшылык эшлиме, начарлыкмы? Сихерчеләрнең, үз-үзләрен үтерүчеләрнең җанын ничек атыйсыз?

103. Үз үлеме белән үлмәгән кешеләр кемнәр алар? Аларны ничек атыйлар? Әгәр дә мәете табылмаса, аның урынына хайван күмү гадәте булмаганмы? Кеше үлгәч, корбан чалмаганнармы? Югалган кешене ничек эзләгәннәр? Кемнәр кайтып кешеләргә начарлык кылып йөри? Нинди очракларда кайталар (үлгәннән соң елап искә алынган, дөрес итеп күмелмәгән, киеме белән күмелмәгән, үз-үзенә кул салган кешеләр, кемдер тарафыннан үтерелгән кешеләр). Андый кешеләрнең җаны куркыныч дип әйтәләрме? Аларны күмгәндә балаларга, хатын-кызларга яннарында торырга ярыймы?

104. Үлгән кеше үзе кайтамы, җанымы, яисә үлгән кеше сурәтендә җен килеп йөриме? Кайчан кайтып йөриләр (40 көн, 6 атна, 1 ел яисә төнлә, 12 дә һ.б.)? Кире кайткан мәетләр кайда очрый? Өйдә, юлда, үтерелгән җирендә? Тереләр дөньясына ни-

чек керәләр (мич торбасыннан, кабер тишегеннән һ.б)?

105. Нинди кыяфәттә киләләр (кеше, хайван, өрәк, утлы елан, пәри һ.б.)? Киемнәре буламы? Алар арасында яхшылары бармы? Аналары үлсә, балалары янына кайта, дип әйтмиләрме?

106. Кайткач нишлиләр (куркыталар, ярдәм итәләр, тынычлык бирмиләр)? Җен булып үлгән ире кайтмыймы? Ул Утлы елан кыяфәтендә күренмиме? Кайтып йөрмәсен өчен нишләргә кирәк (иреңнең эчке киемен кию, өйгә әйберләр элү, ярма сибү, юл бутау, кабергә тишек тишү, төнге уникедә чәч тарау)? Кайткан мәеттән ничек сакла免алар (өй тирәли, кабер тирәли тары сибү, үлән белән төтәсләү, көмеш әйберләр кую, кабергә усактан ясалган таяк тыгу, хәер бирү)?

107. Өрәк кем ул? Үлгән кешенең канынннан барлыкка килмиме ул? Үлгән кеше кыяфәтенә кереп йөрүче җен түгелме ул? Ул нинди кыяфәттә була? Нинди киемнән йөри? Йоклаган кешеләргә тимиме ул?

**Әдәбият**

*Бакиров М.Х.* Татарский фольклор. Казан: Ихлас, 2012. 400 с.

*Виноградова Л.Н.* К проблеме идентификации и сравнения персонажей славянской мифологии / Л.Н. Виноградова, С.М. Толстая // Славянский и балканский фольклор. Верования. Текст. Ритуал. М., 1994. С. 16–44.

*Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда. Казан: Мәгариф, 2008. Т. 1 (А–Г). 303 б.

***Дәүләтшина Ләйлә Хәсән кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*халык иҗаты бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 93/94

*Н.А. Кореева*

# XIX ГАСЫРНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЯРТЫСЫНДА ТАТАР ЭШМӘКӘРЛӘРЕ ЭШЧӘНЛЕГЕНДӘ ВЕКСЕЛЬ ХОКУКЫ

В статье на основе изучения маклерских книг с копиями векселей и заемных писем рассматривается влияние векселя на развитие торговых отношений и торговли. Татарские купцы активно пользовались кредитом на Нижегородской ярмарке. Вексельное право использовалось татарским купечеством для избежания рисков, связанных с отсутствием покупательской активности приезжающих на ярмарку торговцев, и позволяло уменьшить долю непроданных товаров, что было крайне важно для развития промышленности. Обращение к векселям и заемным письмам позволяло сократить потери от непроданного товара и вложить средства в расширение производства.

**Ключевые слова:** вексельное право, кредит, вексель, татарское купечество, кредитное письмо, заемное письмо.

Вексель ул – бурычка алган акчаны билгеләнгән срокка кире кайтару турында бирелгән язма рәвештәге йөкләмә. Беренче вексель уставы Россиядә 1729 елда кабул ителә. Ул көнбатыш үрнәкләренең күчермәсе рәвешендә эшләнгән [Вексельное право..., с. 12]. Әлеге закон ни өчен кабул ителә соң? Тимер акчаларны сәүдә операцияләре башкару өчен төрле шәһәрләргә илтү юлда талауларга, өстәмә чыгымнарга китерә, чит илләр белән коммерция эшләрен башкарганда алтын һәм көмешне исраф итә, бигрәк тә акча ясар өчен әлеге кыйммәтле материалларга болай да кытлык булганда.

Закон чыгаручылар вексель хокукын кертергә кирәклеген болай аңлаталар: «Вексельный устав сочинен и выдан вновь ради того, что в Европейских областях вымышлено, вместо перевоза денег из города в город, а особо из одного владения в другое, деньги переводить через письма, названные векселями, которые от одного к другому даются или посылаются, и так действительны есть, что почитаются наипаче заемного письма, и приемлются так, как наличные деньги» [ПСЗ–1, т. VIII, № 5410, с. 148].

1832 елда беренче вексель уставы басыла [ПСЗ–2, т. VII, № 5462, с. 405–420]. Ул шул заманның тормыш шартларына һәм теләкләренә туры китерергә тырышып эшләнгән. Аны әзерләгәндә төрле сәүдә катламнарының фикерләре исәпкә алынган [Вексель и вексельное обращение в России..., с.19]. Акча күчерү инструменты буларак барлыкка килгән вексель исәп-хисап ясау, кредит бирү һ.б. вазифаларны үти башлый.

Гади һәм күчерелә торган вексельләр була. Гади вексель билгеле бер күләмдәге акчаны,

срогы җиткәч, бернинди бурычларга нигезләнмичә түләүне аңлата. Ә күчерелә торган вексельләр вексель хуҗасының язма рәвештәге приказы нигезендә гамәлгә ашырыла. Россиядә гади вексельләргә күбрәк өстенлек бирелгән. Бу мәсьәләне өйрәнүчеләр моның сәбәпләрен илебезнең географик үзенчәлекләре, товар әйләнешенең аерымлыклары, мәдәни традицияләр кебек факторларның җыелмасы буларак аңлаталар [Соколов, с. 176–180].

Сәүдәгәрләр арасында заем акчаларына сәүдә итү аларның матди хәле озак еллар дәвамында шәптән түгеллеген күрсәткән. Өстенлек үз мөмкинлекләренә, үз акчасына гына бирелгән, ә бу исә күчерелә торган вексельләрнең әйләнешенә тискәре йогынты ясаган. Күчмә вексель Европада түбәндәге схема буенча күчерелгән: «эре фабрикант – күпләп сатып алучы – азлап сатып алучы – исәп-хисап ясаучы банк». Фабрикант, җитештерү циклын туктатмау максаты белән, чималга түләү өчен акчаны бурычка алган, аның өчен вексель әзерләгән, әмма аны күпләп сатып алучы түләргә тиеш булган. Ә ул исә, үз чиратында, вексельне вак сәүдәгәрләргә күчергән.

Россиядә сәүдә операцияләрен башкару өчен төрле социаль группаларга законда чикләүләр кертелгән булган. Алар күчерелә торган вексельләрнең киң таралышына тоткарлык ясаган: күпләп сатып алу хокукы дворяннарга гына бирелгән (үзләре җитештергән товарны гына сата алганнар), 1 нче һәм 2 нче гильдия сәүдәгәрләр (үз мануфактураларындагы продукцияне күпләп сата һәм сатып алынган товарны да сата ала), ә 3 нче гильдия сәүдәгәрләргә күпләп эчке сәүдә итү хокукы бары тик сатып алынган товарларга гына рөхсәт ителгән. Ваклап сату белән бөтен сәүдәгәрләр да шөгыльләнә алганнар (1 нче, 2 нче гильдия – сатып алган товарлар белән, ә 3 нче гилдия – фәкать шәһәрдә бер сәүдә урыны (лавка) тотарга һәм үзләренең остаханәләрендә эшләнгән продукцияне генә сата алганнар. Шунысы кызык: 1 нче һәм 2 нче гильдия сәүдәгәрләргә үз предприятиеләрендә җитештерелгән продукцияне ваклап сатуга чыгару рөхсәт ителмәгән [Свердлова, с. 117]. Сәүдәгәрләр һәм мещаннар авыл җирендә сәүдә мәйданчыгы ача алмаганнар. Шулай итеп, фабрика товарын вак сәүдәгәрләр, спекулянтлар гына сата алган, ә бу исә сәүдә әйләнешенә дә, күчмә вексельләрне куллануга да тискәре йогынты ясаган.

Әлеге чорда җитештерүченең үз товарларын турыдан-туры сатуы капиталистик җитештерүнең төп нигезен тәшкил иткән. Фабрикантлар товарларын үз сәүдә челтәрләре аша сатканда, эре сәүдәгәрләр арадашчылыгыннан саклана алганнар. Алар ярминкәләргә үз товарларын чыгаруга өстенлек биргәннәр. Ярминкәләрдән бу товарлар сәүдә итүче крестьяннар һәм 3 нче гильдия сәүдәгәрләр аша авылларга таратылган.

Вексельләрнең кулланылыш схемасын өйрәнүгә дә, аларны билгеле һәм популяр итүдә дә ярминкәләр зур роль уйнаган. Татар

эшмәкәрләре үз товарларын сату өчен иң кулай урын итеп данлыклы Мәкәрҗә (Макарьевско-Нижегородская) ярминкәсен санаганнар.

1804 елда Казанда 40 татар сәүдәгәрләре була [Хасанов, с. 87]. Аларның якынча 34 е Мәкәрҗә ярминкәсенә йөргән [ЦАНО. Ф. 489, оп. 286, д. 13, 14, 15, 48]. 1809 елда 35 татар сәүдәгәренең 26 сы ярминкәгә барган [ЦАНО. Ф. 489, оп. 286, д. 169]. Тире эшкәртү белән шөгыльләнүче предприятияләрнең хуҗалары Нәзир Баязитов, Йосыф Шатунов, Муса Апанаев, Мортаза Борнаев һәм башкалар 1806–1820 елларда Мәкәрҗә ярминкәсендә икешәр сәүдә мәйданчыгы тотканнар [ЦАНО. Ф. 489, оп. 286, д. 116; Ф. 489, оп. 286, д. 378]. Татар эшмәкәрләре катламын формалаштыруда да, вексель функциясе үсешендә дә ярминкәләр мөһим роль уйнаганнар. Безнең карамакта 1812 елгы вексельнең төп нөсхәсе бар. Ул 25 июльдә Мәкәрҗә ярминкәсендә Казан сәүдәгәре Мәҗит Сапколовка 500 сумлык күләмдә, бер ел срок белән бирелгән булган [НА РТ. Ф. 26, оп. 1, д. 22]. Кредит бирүче – Арча сәүдәгәре Нәзир Баязитов.

Татар сәүдәгәрләре Мәкәрҗә ярминкәсендә вексель хокукыннан бик актив файдаланганнар. 1817 елда Казан мещаны Хәйбулла Әбләев вексельләргә, ягъни кредитка, 1 мең сумлык товар, ә сәүдәгәр Муса Измайлов Апанаев 7 мең сумлык, ягъни ярминкәгә китергән товарларының 47% ы күләмендә товар саткан. Арчадан Нәзир Баязитов Усманов 40 мең сумлык товарын әҗәткә биргән (150 мең сумлык товар алып килгән), бу 27% тәшкил итә. Арча сәүдәгәре Мөхәммәтрәхим Вәлитов, ярминкәдә күмәчләр белән сату итүче, үз товарының 15% күләмендәгесен вексельләргә биргән. Вексель хокукыннан шулай ук Казан сәүдәгәре Хәмзә Мәмәшев тә файдаланган (товарының 33% күләмендәгесе вексельләргә сатылган). Арча сәүдәгәрләре Габделвәли Хуҗасәитов (50%), Мәхмүт Нәзиров (56%), Усман Хуҗасәитов (20%) Казан сәүдәгәре Гобәйдулла Сөяров (83%) шулай ук товарларын вексельгә алмаштырганнар. Ярминкәдәге товарларның шактый өлеше сатылмавын исәпкә алганда, товарны кредитка бирү җитештерүчеләрне бөлгенлеккә чыгудан саклаган һәм нинди генә очракта да файда китергән.

Вексельләргә һәм заем хатларына мөрәҗәгать итү сатылмаган товардан килгән зыянны киметергә һәм акчаны җитештерүне үстерү өчен тотарга мөмкинлек биргән. Мәсәлән, Габделвәли Хуҗасәитовның, товарны әҗәткә биргәннән соң, сатылмаган товары калмаган, ә Усман Хуҗасәитовның 25 мең сумлык (50%), Муса Апанаевның 30 мең сумлык (20%) товары калган. Димәк, вексель сәүдә әйләнешен киңәйтүгә зур булышлык иткән. Вексель кулланган очракта акча белән исәп-хисап ясаганда киткән чыгымнар кимегән, коммерция предприятиеләренең нәтиҗәлелеген арттырырга мөмкинлек тудырган, чөнки вексельләрнең күчеше акча әйләнешен алыштырган, кеше һәм

товарларның хәрәкәтенә ярдәм иткән [Криничанский, с. 8].

Татар коммерсантлары вексельләрне күп очракта бер елга (29%), 13 айга (8%) биргәннәр [НА РТ. Ф. 26, оп. 1, д. 1232]. Кайбер вексельләрнең түләү срогы ел саен үткәрелүче ярминкәләргә туры китерелә торган булган. Мәсәлән, 1 нче гильдия сәүдәгәре Муса Мөхәммәтов Якупов 2 нче гильдия сәүдәгәре Василий Федорович Подошвенниковка булган 2150 сум күләмендәге вексель әҗәтен Эрбет ярминкәсендә кайтарырга дип йөкләмә алган [шунда ук, л. 23об.]. Арча сәүдәгәре Усман Сөләйман улы Хуҗасәитов сәүдәгәр Василий Максим улы Киселевтан ике вексельгә товар алган (5 мең һәм 1730,6 сумлык) һәм аны Ростов ярминкәсендә кайтарырга вәгъдә биргән [шунда ук, л. 26]. Казан сәүдәгәре Мортаза Муса улы Апанаев шул ук Киселевтан 2480 сумлык товарны вексельгә алып һәм аны Нижегород ярминкәсендә Россия акчалары белән кайтарырга дип сүз биргән [шунда ук].

Татар коммерсантларының вексельләре Казан маклерында 1824 елның декабрь аенда 29%, сентябрьдә – 25%, ноябрьдә – 13% теркәлгән, ягъни алар илдәге мөһим ярминкәләр алдыннан яисә алар төгәлләнгәч гамәлгә ашырылган. Мәсәлән, Эрбет ярминкәсе – 6–20 январьдә, Нижегород ярминкәсе – 15–25 августта узган [Остроухов, с. 211]. Татар коммерсантлары кредитны Россиядә әйләнештә булган акча белән (вексельләрнең 42%), банк ассигнациясе ярдәмендә (12,5%) һәм товарлата (46%) алганнар. Бурычны я әйләнештәге акча белән (вексельләрнең 79%), я банк ассигнациясе аша кире кайтарганнар.

Ярминкәләрдә сәүдә, башлыча, күпләп сатуга нигезләнгән, ә азлап сату исә күпсанлы арадашчылар (аларны прасоллар, ягъни ит, балык, терлек белән сату итүчеләр дип йөрткәннәр) аша башкарылган [Мельников, с. 16–20]. Алар товарларны азлап яки партиясе белән алганнар һәм шунда ук ярминкәләрдә сатканнар, я инде үзләренең шәһәрләренә алып кайтып, анда күпләп яки ваклап сату оештырганнар. Чистай прасоллары, мәсәлән, үзләрендә булган 100–500 сум акчага товар ала һәм аны тиз генә арттырып сатып җибәрә торган булганнар.

1800 елдагы банкротлык турындагы Устав нигезендә, вексель килешүләрен төзү бары тик сәүдәгәрләргә генә рөхсәт ителгән. Чиновник һәм дворяннарга андый хокук бирелмәгән [ПСЗ–1, т. XXVI, № 19692, с. 461]. Крестьяннарга 1761 елда ук вексельләр белән эш итүне тыйганнар, ләкин алар «заем хатлары» яза алганнар. Моның өчен төп шарт булып икенче катламдагылардан яки помещиктан рөхсәт алу тиеш булган [ПСЗ–1, т. XV, № 11204, с. 649–650]. Соңыннан бу карар гамәлдән чыгарылган һәм сату-алу эше белән шөгыльләнүче крестьяннар вексельдән файдану хокукына ирешкәннәр [ПСЗ–1, т. XXXII, № 25731, с. 1085].

1824 елда Казанда маклерда кредит бирүче 9 татар теркәлгән. Без 7 кешенең социаль

чыгышын ачыклый алдык. Кредит бирү өлкәсендә беренчелекне сәүдәгәрләр алып тора (4 кеше), аннан мещаннар һәм сәүдә итүче татарлар. Кредитның күләме 250 сумннан 4 мең сумга кадәр. 250 сумлык кредитны иске татар бистәсендә яшәүче Бикбов Мөхәммәтов Клоков, ә 4 мең сумлык кредитны сәүдәгәрләр Йосыф һәм Корбангали Әхмәровлар бирә. Акчаны әҗәткә алуны документ нигезендә рәсмиләштерүчеләр авыл җирләрендә дә була. 1824 елның 20 гыйнварында 402 сумлык гади вексель 4 айга дип төзелә. Бу акчаны Лаеш өязе Елагино авылыннан Бикмөхәммәт Бәширов Түбән Тимерлек авылындагы үзе кебек үк ясаклы татардан алып тора [НА РТ. Ф. 26. Оп. 1. Д. 1232].

XIX гасырның беренче яртысында төрле катлам кешеләр өчен кредит бирү күләменең рөхсәт ителгән чиген билгеләгән закон кабул ителә. Бу 1 нче гильдия сәүдәгәрләргә кагылмый, алар чикләнмәгән күләмдә кредит алырга хокуклы. 2 нче гильдия сәүдәгәрләр 50 меңнән дә артык булмаган суммага вексель алу хокукына ия булсалар, 3 нче гильдия сәүдәгәрләргә 20 меңгә, сәүдә итүче мещаннарга 4 меңгә чаклы гына кредит бирелгән [ПСЗ–1, т. XXXIX, № 30115, с. 589–591].

Вакытлар узу белән трансферт, исән-хисап, клиринг функцияләрен үтәгән вексельгә кредит функциясе дә өстәлә. Бу нәрсә белән бәйле соң? XVIII гасырда ук вексель әйләнеше сәүдә өлкәсен товарлар, шул исәптән чит илнекеләр белән дә тутыра; ә сәнәгать, инвестецияләр кертмичә генә, үсеш кичерә алмый, чималны финанслау, хезмәткәрләргә түләү, предприятиенең эшен өзлексез тәэмин итү өчен кредитка мохтаҗ була. Шуңа күрә вексельнең кредит функциясе сәнәгать секторы белән бер вакытта барлыкка килә [Криничанский К.В, с. 8].

1786 елдагы закон нигезендә кредит бирүдән кергән табыш бирелгән акчаның 5% нан [ПСЗ–1, т. XXII, № 16407, с. 614], ә 1808 елдагы канун нигезендә 6% тан артмаска тиеш була [ПСЗ–1, т. XXX, № 23317, ст. 1, с. 653–654]. Бу процент ставкасы банклар өчен дә, кредит бирү белән шөгыльләнүче шәхси затлар өчен дә бер төрле була. Әмма гади вексельләрдә кредит буенча процент ставкасы беркайчан да күрсәтелми.

Ул чорда вексель тексты бер төрле генә була: анда вексель бирүче, күчерүче, түләүченең исеме язылырга, вексельне тутыру көне һәм вакыты чыгу белән мәгълүм сумманы процентлары белән кайтару срогы күрсәтелергә тиеш. Кайбер очракларда вексельләрдә түләү срогын күрсәтмәскә дә мөмкин булган, ул чагында «белдерү буенча түләргә» дип язылган (ягъни вексельне кайтару вакытында). Мондый вексельнең срогы чикләнмәгән. Вексель буенча кайтарылырга тиешле акчаны кредит бирүче үзе, шулай ук аның ышанычлысы да алырга хокуклы булган. Болар да вексельдә язылган булырга тиеш. Шулай ук вексельне тутыру урынын, түләүнең күләмен һәм аның кайда бирелүен дә күрсәтү

мәҗбүри булган. Барлык мәгълүматлар да вексель тотучының кулы белән имзаланган. Менә бер мисал: «Макарья 1812 г. августа 1 числа вексель на 500 рублей. Двенадцать месяцев считаемо от сего тысяча восемьсот двенадцатого года августа первого числа посему моему одинакому векселю повинен я заплатить арскому купцу Букмену Таирову Хозясеитову или от него кому приказано будет получить государственными банковыми ассигнациями пятьсот рублей, ибо я толикую сумму получил сполна» [НА РТ. Ф. 26, оп. 1, д. 22, л. 248].

Бу вексельдә заем буенча процентларның күләме дә, әҗәтне кайтару урыны да күрсәтелмәгән. Мондый вексель гадәти расписка, ягъни алучының кулы куелган документны хәтерләткән. Законда мондый вексельләр «процентсыз вексельләр» дип аталган.

Вексельне маклерлар алдында бирергә киңәш ителгән. ТР Милли архивында 1824 елда Казан шәһәр магистраты тарафыннан маклер Иван Варнавинга бирелгән «На записку векселей и заемных писем» дигән махсус китап сакланган. Вексельне маклерда тутырган өчен пошлина күләме кредитның суммасыннан һәм герблы кәгазьнең бәясеннән чыгып исәпләнелгән. Герблы кәгазьнең хакы даими үзгәреп торган. 1812 елда вексель әҗәте 500 сум булганда, герблы кәгазьнең бәясе 2 сум, 1001 дән 3 мең сумга кадәр – 6 сум, 25001 дән 30 мең сум булганда – 40 сумны тәшкил иткән [ПСЗ–1, т. XXXII, № 24992, с. 188]. 1830 елда гербլы кәгазьнең хакы киметелә һәм 500 сумлык барлык актлар өчен дә 1 сумга гына кала [ПСЗ–2, т. V, № 3700, с. 498].

*Күчерелмә вексельләр турында.* Вексельләрнең бу формасыннан сәүдәгәрләр Кяхтада сәүдә иткәндә таможня пошлинасын түләгәндә файдаланганнар. Залог итеп вексельнең тулы суммасы, мал-мөлкәт, йорт-җир алынган. Таможняга пошлинаны закон нигезендә 50 мең сумнан артмаган вексельләр белән түләү дә рөхсәт ителгән. Пошлина түләүне кичектерү өчен магистрат, ратуша яки шәһәр думасы тарафыннан бирелгән аттестатны таможняга күрсәтергә кирәк булган [ПСЗ–1, т. XXXIX, № 29751, с. 36]. Аттестат бирүчеләр, теге яки бу хәл килеп чыгу сәбәпле купец пошлинаны түли алмаса, җаваплылыкны үз өсләренә алырга әзер булган поручительләр билгеләгән. Әгәр аттестатта бу җаваплылык күрсәтелмәгән икән, Кяхта таможнясы рус яки чит ил товарларының өчтән берен үзендә калдыру хокукына ия булган [Журнал мануфактур и торговли, с. 10–16]. Түләүләрне кичектерү мөмкинлеге тудырган өчен томожня процентлар (6%) алган [ПСЗ–1, т. XII, № 10537, с. 741].

1820 елда Казан татар ратушасы 1 нче гильдия сәүдәгәр Гобәйдулла һәм Мостафа Сөеровларга Кяхтага рус, немец, азиялеләрнең товарларын җибәргән өчен пошлина түләүләрен кичектерергә аттестат биргән [НА РТ. Ф. 22, оп. 1, д. 64, л. 206 об.–207]. Поручительләре булып, Казанның 1 нче гильдия сәүдәгәрләре Муса Апанаев,

Габделкәрим Юнысов һәм Бәшир Аитов керәләр һәм пошлина җаваплылыгын үз өсләренә алалар.

Күчерелмә вексельләрнең әйләнешенә сәүдә пунктларының географик яктан уңайсыз урнашулары да кыенлыклар тудырган. Вексель тотучы акчасын бирү турында килешергә, әгәр дә кире кага икән, вексель хуҗасына кире җибәрергә тиеш була. Ә бу исә вакыт һәм юлларның яхшы булуын таләп итә.

Вексель буенча бурычларны кичектергән өчен законда штраф санкцияләре дә каралган. Вексель уставы нигезендә, 1729 елда вексель тотучыга финанс җаваплылыгы каралган. «От момента дачи векселя до того числа, когда он протестован, нестойку брать, считая по 8% со ста со всей написанной в векселе суммы, затем, упуская месяц после протеста в неплатеже, на незаплаченную сумму на каждый вперед месяц по 1,5%» [ПСЗ–1, т. VIII, № 5410, с. 171]. Бу 18% еллык түләүне аңлата. 1763–1768 елларда алардан алынган сумманың 8% ын казнага күчерәләр [ПСЗ–1, т XVI, № 11988, ст. 5, с. 460; т. XVIII, № 13197, с. 768]. Килешү шартларын үтәмәгән өчен түләнергә тиешле штраф, ягъни неустойка, вексельдә язылган сумманың 8%ы күләмендә итеп билгеләнгән. 1832 елда килешүне өзгән өчен әҗәтнең 0,5% ы күләмендә штраф салына башлый. Дәүләт органнары аша бурычларны кайтарткан өчен дә шуңа киткән чыгымнарны капларга тиеш булалар. Полиция файдасына капиталның 2% ы күләмендә, суд өчен 4% күләмендә акча тотып калынган [ПСЗ–2, т. VII, № 5462, с. 417–418].

Закон нигезендә, дворян, чиновник, сәүдәгәрләрнең вексельләре түләнмәгән очракта, моны нотариуска яки маклерга җиткерергә, яисә бер ел дәвамында билгеләнгән урынга килергә кирәк була. Шушы срокка өлгермәгән очракта вексель юк ителгән [ПСЗ–1, т. XXXII, № 25341, с. 535]. Нотариус исә, бурычлыны эзләү һәм аңа әҗәтне түләтү турында таләп куйган; үзенең күрсәткән хезмәтләре өчен, нәтиҗәнең нинди булуына карамастан, кредит бирүчеләрнең һәр сум бурычыннан 0,5% акча алган һәм аны шәһәр казнасына җибәргән.

Вексельләр буенча бурыч түләтүнең үз кыенлыклары да булган – бурычлы югалган, ә кредит бирүчеләр аны барлык ярминкәләр буенча эзләгәннәр. ТР Милли архивында акчасы түләнмәгән вексельләр буенча төрле суд эшләренә караган язулар сакланган. Шуларның берсе – Казанның 1 нче гильдия сәүдәгәрләре Ибраһим һәм Исхак Гобәйдуллиннар, абыйлы-энеле Юнысовларның суд эшләре [НА РТ. Ф. 26, оп. 1, д. 783, л. 1]. 1845 елда алар 5 тапкыр төрле срок белән (12, 24, 36, 48, 60 айларга) кредит биргәннәр. Степан Максим улы Тушков алардан 3 тапкыр 1400 сумлык һәм 2 тапкыр 15 мең сумлык кредит алган. Шул ук елда Тушков Нижегород ярминкәсендә Санкт-Петербург сәүдәгәре Семен Козловтан 6 ай һәм 20 көнгә 686 сумлык товар алган [шунда ук, л. 11]. Козлов Малмыждагы 1 нче гильдия сәү-

дәгәре Әхмәтшах Габдулла улы Үтәмешевка вексель бирә; ул, кыйммәтле кәгазьнең хуҗасы буларак, бурычлыны эзләргә керешә. Үтәмешевның кушуы буенча җирле нотариус Григорий Овчинников Тушковны Эрбет ярминкәсеннән эзләп караса да, уңай нәтиҗәгә ирешә алмый. Архивта сакланган суд эшендә бу эзләүнең шаһитлары Эрбет мещаны Василий Ипитов, Төмән өлкәсе крестьяны Александр Словинның имзалары куелган язу бар. Шул ук елны (1846 ел) вексель алучыны Нижегород ярминкәсендә нотариус Петр Голубев та эзли, әмма таба алмый.

Әҗәткә алучы табылмаса яки аны эзләүләрнең нәтиҗәсе булмаса, кредит бирүчеләр полициягә мөрәҗәгать иткәннәр. Махсус әзерләнгән чакыру кәгазе белән бурычлыны полициягә чакыртканнар. Полиция хезмәткәрләренә берничә тапкыр вексель иясенең өенә барып, үзен яки аның ышанычлысын эзләргә туры килгән. Полициягә беркем дә килмәгән очракта бурычлының өенә ратман (шәһәр идарәсе әгъзасы), квартал күзәтүчесе, кредитор (теләге буенча) килеп, әҗәт өчен сатарга туры килсә дип, андагы мал-мөлкәтне исәпләгәннәр.

Кайчагында кредиторлар бурычлыга ташлама да ясаганнар; әҗәтнең үзен кайтару шарты белән кредит буенча процентларны «гафу иткәннәр». Мәсәлән, 1847 елда Казанның 1 нче гильдия сәүдәгәре Мөхәммәт Апанаев Тугиновтан процентлар алмый [шунда ук, л. 76].

1849 елда процентларны бернинди чикләүләрсез күчерергә рөхсәт ителә [ПСЗ–2, т. XXIV, № 23112, с. 168–169]. Вексель бурычын кайтармаган очракта бурычлының мөлкәте сатылган. Мөлкәте әҗәтне кайтару өчен җитмәгән очракта, бурычлы кешене, кредит бирүченең үтенече буенча, сак астына алырга рөхсәт бирелгән: 100 сум бурыч өчен – 2 айга, 100–250 сум өчен – 4 айга, 250–500 сумга – 6 айга, 500–1000 сумга – 1 елга, 1000–5000 сумга 2 елга төрмәгә утыртканнар. Кредит бирүче төрмәдә утыручының чыгымнары өчен төрмә хуҗаларына бер ай алдан акча түләргә тиеш булган. Түләмәгән очракта бурычлыны төрмәдән чыгарып җибәргәннәр [ПСЗ–2, т. VII, № 5462, с. 417–418]. Коммерсантлар өчен бу кулай ысул түгел, шуңа да алар күп вакытта бурыч түләүне кичектерү юлын сайлаганнар.

Россия сәүдәгәрләре бу чорда кредитны шәхси затлардан гына түгел, дәүләт заем банкларыннан да алырга хокуклы булганнар. Ссуданың бер өлешен кредит билетлары белән бирергә кушылган. Кредит билетларына Россия империясенең һәр төбәгендә дә көмеш акчалар белән бер дәрәҗәдә әйләнештә булырга рөхсәт ителгән. Кредит билетлары белән ссуда алганда процент ставкасы 5% тәшкил итеп, шуның 1% ын кредит оешмасы үз чыгымнары, ә калган 4% фәкать фондны үстерү өчен генә тотылган [Постановления и распоряжения правительства. Об учреждении кредитных билетов..., с. 1–7].

1848 елның 2 гыйнварында Казан иҗтимагый банкы (беренче

шәһәр банкы) ачылу купецларга кредит бирү һәм вексель хокукыннан файдалану өчен мөмкинлекләрне киңәйтә, үз товарыңны сату, алыпсатарлыкны үстерүгә киң юллар ача. Банк җирле гражданнарга ссуда биреп, аннан килгән процентлар хисабына хәерчеләр һәм картлар йортларын асрау максатын күздә тоткан [Положение об общественном банке в г. Казани..., с. 13–34]. Банк төп өч операция башкарган: кертемнәр (вкладлар) кабул итү, вексельләрне исәпләү һәм ссудалар бирү (залогка мөлкәт салынган).

Банк билгеле бер күләмдәге мөлкәткә ия булган, завод һәм фабрикалар тоткан, сәүдә иткән. Казан, губерния сәүдәгәрләре, мещаннарыннан гына вексель кабул итеп алган һәм кредитлар биргән. Исәпкә алынучы вексельләр билгеле бер таләпләргә туры килергә: законлы формага ия булырга, срогы 1 елдан күбрәк һәм 1 айдан азрак булмау, хакы 15 мең сумнан да (көмеш белән) артмаска тиеш булган. Вексель бурычы булганнарга (вексельне бирүчегә дә, алучыга да кагыла) кредит бирү күләмен банк ныклы күзәтүгә алган. 1 нче гильдия сәүдәгәрләр 4 мең сум, 2 нчеләр – 3 мең сум, 3 нче гильдия сәүдәгәрләр – 2 мең сум, ә мещаннар 500 сумнан артык бурычка ия булсалар, алар кредит алу хокукыннан файдалана алмаганнар.

Вексель буенча акча биргәндә банк бирелгән акчадан 0,5% ын үзенә алып калган, шулай ук ярдәмгә мохтаҗ булган махсус йортларга булышлык итәргә чакырган. Клиент риза булса, хәйрия акчасының күләме махсус китапка язып куелган.

Казанда яшәүче барлык социаль катлам кешеләренә дә, үз мануфактураларын залогка салу исәбенә кредит алу хокукы бирелгән. Моның өчен Казан шәһәр магистратының кредит оешмалары өчен махсус басылган таныкнамәсен күрсәтергә кирәк булган. Соңыннан присяжныйлар кредит алучының мөлкәт бәясе хакында язма рәвештә мәгълүмат тапшырганнар. Банк кредитны мөлкәтнең яртысы күләмендә генә бирә алган. Банк ачылган вакытта, ягъни 1848 елда, мөлкәтне залогка биреп, 2 мең сум кредит алырга мөмкин булган. Кредит 3 елдан да артык срокка бирелмәгән. Беренче ел өчен процентлар (6%) кредит биргәндә үк тотып калынган, ә калганнарын заемчы бер елга алдан түләгән. Алтын, көмеш, бакыр, энҗе-мәрҗән, тимер кебек кыйммәтле товарларны залогка алып та кредит биргәннәр.

Банк ачылган елда кертемнәр аша банкка 101001 сум 7 тиен акча кергән, 97940 сум 79 тиенгә вексельләр исәпкә алынган, таш биналарны залогка алып, 13094 сум 57 тиенлек ссуда бирелгән. Процент ставкасы кредитлар буенча 6%, кертемнәр буенча 4% [История Казани..., с. 352–364]. 1849 елда – 91700 сумлык, 1859 елда – 604200 сумлык, 1869 елда 2238200 сумлык вексельләр исәпкә алынган [шунда ук, с. 380–381].

Сәүдәгәр ярминкәдә үз товарын вексельгә биргәч, аны ябуның срогы чыкканын көтеп тормыйча да, бу кыйммәтле кәгазьдә

күрсәтелгән сумманы банктан акчалата алу хокукына ия булган. Вексель бирүче сәүдәгәргә түгел, ә банкка тиеш булып калган. 1848 елда андый коммерсантларның саны 76 [НА РТ. Ф. 144, оп. 1, д. 5], 1855 елда 562 кеше була. [НА РТ. Ф. 144, оп. 1, д. 18].

1855 елда банкның заемчылары арасында 30 татар коммерсанты (барлык заемчыларның 5% ы) була. Шуларның фәкать берсенең генә социаль чыгышын ачыклап булмады. Калганнары: 26 сәүдәгәр (3 нче гильдия – 21 кеше, ягъни 81%, 2 нче гильдия – 1 кеше (4%), 4 сәүдәгәр гильдиясен ачыклап булмады), 2 «купец улы», 1 мещан. Заемчыларның зур күпчелеге Казаннан (27 кеше, ягъни 90%), 1 әр кеше – Арчадан (3%) һәм Зөядән [НА РТ. Ф. 144, оп. 1, д. 18, л. 1 об.–129].

Бурычларны түләүнең төп гарантиясе булган вексельләр, спекуляция объектына да әйләнәләр. Шул сәбәпле вексель бирүчеләр еш кына банкның бурычлылар исемлегенә эләгә. Казан сәүдәгәре Гаврила Чепарин үзенә бурычлы булганнарның вексельләрен банкка тапшырган. Банкта бер тәүлек эчендә вексельләрне акчага әйләндерү мөмкинлеге булган.

Вексельләрне банкта ссудага алмаштырган сәүдәгәр вексель бирүчене һәм үзенә бурычлы кешене кисәтеп куярга тиеш була, чөнки ул банкка бурычлы дигән сүз. Бурычларны срогы килеп җиткәнче түләү ихтыяҗы булган очракта, алдан түләнгән процентлар клиентка кире кайтарылмаган.

Вексель тапшыручы банк белән исәп-хисапны үз вакытында ясарга һәм вексельне алып, вексель хуҗасыннан кирәкле сумманы үзе дә сорый алган. Икенче вариант та булган – банк вексель хуҗаларын үзе эзләп тапкан һәм аларга законда каралган чараларны кулланган. Бурычны кайтару өчен 10 көн срок билгеләнгән. Бу срок чыкканнан соң, вексельне нотариуста яки маклерда теркиләр, бурычлының мөлкәтенә мөһер сугу я арест салу өчен ратуша яки магистратка мөрәҗәгать итәләр. Ике атна вакыт узганнан соң, йозак салынган мөлкәт аукционда сатылган һәм бурыч банкка кайтарылган. Мондый бурычлыларга алга таба кредит бирмәс өчен банк «кара китап» булдырган һәм аларның исемнәрен шунда теркәп барган.

Вексельләрдән тыш янә бер кыйммәтле кәгазь – заем хатлары, алар да кредит функциясен үтәгән. Заем хатлары вексельләр белән бергә кулланылганнар, ләкин вексель гадәттән тыш таләпчәнлеге белән аерылып торган [Мейер, с. 21].

1824 елда Казанның маклерлык китабында вексель һәм заем хатлары теркәлгән. Анда 167 кредит алу һәм шуларның 69 ы вексель (41,3%) һәм 98 е заем хатлары (58,6%) икәнлеге язылган. Заем хатларының 29ы татар коммерсантлары тарафыннан язылган. Татар коммерсантлары 19 очракта кредитор сыйфатында үзләре катнашалар [НА РТ. Ф. 26, оп. 1, д. 1232, л. 1–26].

Заем хатының текстын бирәбез: «Я, нижеподписавшийся мамадышский купец Хамит

Бакиров сын Уразов[а], занял у господина коллежского асессора Павла Самсонова Волкова денег указною российскою монетою 1000 рублей за указные проценты сроком впредь на 13 месяцев, то есть будущаго 1825 г. февраля по пятое число, на которое и должен всю ту сумму сполна заплатить, а буде чего не заплачу, то волен он, господин Волков, просить о взыскании и поступлении по законам; заемного письма датель мамадышский купец Хамит Бакиров сын Уразов» [НА РТ. Ф. 26, оп. 1, д. 1232, л. 1].

Эшмәкәрләр арасында вексель эшләрен төзүнең үз үзенчәлекләре булуы да игътибарга лаек: татар эшмәкәрләре әҗәткә акча алып торганда күбрәк рус сәүдәгәрләренә мөрәҗәгать иткәннәр (18 вексельнең 13 е, ягъни 11%; фәкать 3 вексель (17%) генә татарларның үз араларында төзелгән). Рус эшмәкәрләре, киресенчә, кредитны үз милләт вәкилләреннән алырга тырышканнар (69 вексельнең бары тик 4 е генә (6%) татарлардан) [шунда ук].

Заем хатлары буенча эш башкачарак була: татар-мөселманнар күбрәк үз өммәтендәгеләр белән заем алыш-биреше ясаганнар (29 хатның 14 е (48%), руслар – 12 (41%), бохара сәүдәгәрләре – 3 (10%).

Архив чыганаклары буенча (маклерлык китабы) заем күбрәк Россиядә әйләнештә булган акча белән гамәлгә ашырылган (65%), 29% ы дәүләт ассигнацияләре, 6% ы – көмеш белән. Заем сроклары 2 айдан 4 елга чаклы булган. Татар коммерсантлары арасында аеруча киң таралган заем срогы – 12 ай (24%), 11 ай (15%), 4 ай (12%) булган [шунда ук].

Заем хатлары буенча суд эшләре өчен хатның төп нөсхәсе кирәк булган, күчермәләре кабул ителмәгән.

Әлеге материалдан чыгып кайбер нәтиҗәләр ясарга була:

Татар сәүдәгәрләре вексель хокукыннан һәртөрле уңышсызлыктан качу өчен файдаланганнар. Ул аларга, ярминкәдә товарны сатып алучыларның аз булуы сәбәпле, сатылмаган товарның күләмен киметергә мөмкинлек тудырган, ә бу исә сәнәгать үстерү өчен мөһим фактор булып тора.

Вексельләр мөстәкыйль, бәйсез сәүдә берәмлегенә әйләнәләр, ә аның буенча түләнгән процентлар сәүдә-сәнәгать эшчәнлеген уңышлы алып бару, товарны әҗәткә алып тору өчен зур мөмкинлекләр ача. Эшләрен яңа гына башлаган сәүдәгәрләргә вексель эшмәкәр булып китәргә дә юллар ачкан.

Татар коммерсантлары процентка акча бирү-алу системасында үз урыннарын алалар, вексель хокукыннан актив файдаланалар.

Россиядә вексель хокукы таралу һәртөрле көтелмәгән хәлләр белән бергә барган: мәсәлән, әҗәткә алучының югалуы һәм бурычның кайтарылмавы. Әмма сәүдәгәрләр барыбер аннан файдалануны өстен күргәннәр.

Казан сәүдәгәрләре, банк һәм кредит өлкәсендәге үзгәрешләргә яраклашып, вексельдән файдалануның аерым механизмын булдырганнар.

**Әдәбият**

*Богородицкая Н.А.* Нижегородская ярмарка – карман России: учебно-методическое пособие. Н. Новгород: ННГУ, 2008. 133 с.

*Виденеева А.Е., Грудцына Н.В.* «Мир и клир»: ростовское духовенство на Ростовской ярмарке // Ярославский педагогический вестник. 2010. № 1. С. 10–16.

Вексель и вексельное обращение в России: практическая энциклопедия / Волохов А.В., Ефимова Л.Г., Ильин В.В. и др.; науч. ред. Б.А. Жалнинский. 3-е изд. М.: Банковский деловой центр, 1997. 294 с.

Вексельное право. Общие положения и юридический комментарий / В.В. Ильин, А.В. Макеев, Е.А. Павлодский. М.: Банковский деловой центр, 1997.

История Казани в документах и материалах. XIX век: промышленность, торговля, финансы / под ред. И.К. Загидуллина. Казань: Магариф, 2005.

*Криничанский К.В.* Эволюция коммерческих ценных бумаг. Функциональный аспект // Журнал экономической теории. 2009. № 2. С. 188–200.

*Мейер Д.И.* Очерк русского вексельного права: чтения Д.И. Мейера в Казанском университете. Казань: Университетская типография, 1857.

*Мельников С.* Прасолы и косники в г. Чистополе и его уезде // Журнал Министерства внутренних дел. 1857. Ч. 23. Кн. 3. С. 16–20.

*Остроухов П.А.* Нижегородская ярмарка в 1817–1867 гг. // Исторические записки. 1972. № 90. С. 209–243.

Постановления и распоряжения правительства. О порядке обеспечения казны в пошлинах, переводимых по векселям, выдаваемым купечеством на Кяхте // Журнал мануфактур и торговли. 1839. № 10. С. 10–16.

Постановления и распоряжения правительства. Об учреждении кредитных билетов // Журнал мануфактур и торговли. 1841. № 7. С.1–7.

Постановления и распоряжения правительства. Об учреждениях сберегательных касс // Журнал мануфактур и торговли. 1841. №11. С.161–172.

Положение об общественном банке в г. Казани // Журнал мануфактур и торговли. 1847. № 7. С.13–34.

*Свердлова Л.М.* Казанское купечество: социально-экономический портрет (кон. XVIII – нач. XX в.) Казань: Татар. кн. изд-во, 2011. 319 с.

*Соколов А.В.* Особенности формирования вексельного права в России // Фундаментальные и прикладные исследования кооперативного сектора экономики: Научно-теоретический журнал. 2012. № 1. С. 176–180.

*Хасанов Х.Х.* Формирование татарской буржуазной нации. Казань: Татар. кн. изд-во, 1977. 328 с.



***Кореева Наталья Анатольевна,***
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*
*Урта гасырлар бүлеге аспиранты*

УДК 130.12=512.1

***Б.С. Корганбеков***

# КҮЧМӘ ТӨРКИЛӘРНЕҢ РУХИ ЯШӘЕШЕНДӘ ХУҖА ӘХМӘТ ЯСӘВИ КАРАШЛАРЫ

*Болат Корганбеков – казакъ халкының эпик фольклорын өйрәнүне төп фәнни юнәлеше итеп алган белгеч, филология фәннәре кандидаты, Лев Гумилев исемендәге Евразия университеты доценты. Ул өч монография, берничә коллектив монография, ун дистәгә якын фәнни мәкалә авторы, күпсанлы җыентыклар, күптомлыклар төзү эшендә катнашкан тәҗрибәле галим. Әхмәт Ясәви (2011) һәм казакъ фольклорына (2012) багышланган, «Шора батыр эпосы: тарихилыгы, нөсхәләре, генезисы» исемле (2014) монографияләре дөнья күргән. Хезмәтләренең барысы да казакъ халык иҗаты өлкәсенә, дастаннарга, күчмә төркиләрдә эпик иҗатның үсеш тарихын өйрәнүгә багышланган, мәкаләләре инглиз, төрек, урыс, үзбәк телләрендә дөнья күргән. Суфи шагыйрь Әхмәт Ясәвинең күчмә төркиләрдә рухи белем үсешенә йогынтысын өйрәнүгә багышланган әлеге мәкаләсе татар телендә тәүге кат дөнья күрә. Мәкаләдә язма мәдәният аша килә торган һәм күңел халәтенең, дөресрәге, Аллаһ тарафыннан йөрәккә иңдерелгән сакраль белемнәрнең төркиләрнең рухи үсешенә тәэсире турында сүз бара. Чыннан да, бу белемнәрнең икенчесе хакында фәндә аз сөйләнелә. Чынлыкта бу бөек бүләк хакында зур тикшеренү эшләү – төрки дөнья өчен дә, гомумән, фәндә фольклористика өлкәсе өчен дә гаять актуаль мәсьәлә, шуңа күрә казакъ кардәшебез Болат Корганбековның әлеге юнәлештәге эшчәнлегеннән бер өлешне игътибарыгызга татар телендә бирүне кирәкле гамәл дип таптык.*

***Лилия Мөхәммәтҗанова,***
*филология фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*халык иҗаты бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

Автор излагает собственное видение истории развития духовного мира кочевых тюрков и определяет роль поэта-суфия Ахмета Ясави в этом процессе.

**Ключевые слова:** кочевые тюрки, духовное знание, ислам, суфизм, святые, мудрецы, народ, хикметы, Ясави.

Төрки халыклар рухи белеменең үсеш тарихы аларның исламга килү чорына ук барып тоташа. Әлеге рухи белемнең нигезендә борынгы мистик гыйлем – суфичылык – ята. Суфичылык тәгълиматы, гарәпләр һәм фарсылар аркылы төркиләр арасына үтеп кереп, биредә төркиләргә генә хас милли үзенчәлеккә ия булды. Утрак тормыш рәвешенә күчү сәбәпле, төркиләрдә хезмәт бүленешенең социаль системасында үзгәрешләр башлана һәм суфичылык поэзиясе дә шушы чорда ике зур юнәлештә үсә башлый. Аның беренчесе – укый-яза белүче сарай хезмәткәрләре арасында популярлыкка ирешкән диван әдәбияты,

икенчесе – гади халык арасында киң таралган дәрвишләр поэзиясе [Джавелидзе]. Боларның беренчесе – төп һәм әһәмиятле поэтик чара буларак, гаруз ритмикасы кулланылган язма әдәбият белән бәйле юнәлеш. Гаруз шигыренең ритмик сурәте кыска сузык авазларның озынаюы һәм кабатлануы принцибына көйләнгән. Ә бу исә төрки телнең табигатенә бөтенләй туры килми. Шуңа да диван әдәбияты вәкилләре гарәп сүзләре күп кулланылган фарсы теленә өстенлек биргәннәр. Шунлыктан алар поэзиясендә төрки сүзләр бик сирәк очрый. Бу стильнең ачык мисалы – Җәләлетдин Руми яисә Низами иҗаты. Дәрвиш поэзиясе исә, нигездә, гади халыкка аталганлыктан, төрки телдә язылган һәм аны халык җыручылары, башкаручы-ашуглар халык уен коралларына кушылып, тыңлаучыларга җиткерә торган булганнар. Хәзерге төрек әдәбияты күзлегеннән, дәрвишлек поэзиясенең иң күренекле вәкиле буларак, әйтик, Юныс Әмрене күрсәтергә мөмкин.

Күчмә тормыш барган далаларда хәл бөтенләй башкача булуны танымый мөмкин түгел. Монда социаль системадагы үзгәрешләрне, хезмәт бүленешен әллә ни дәрәҗәдә динамик барган дип әйтеп булмый. Мал асраучылык белән бәйле тормыш рәвеше антогонизмның үсешенә тоткарлык ясый, шуңа хезмәт бүленешенә дә ихтыяҗ тумый. Күчмә җәмгыять тормышын өйрәнгән Д. Кшибеков, мәсәлән, аларда колбиләүчелек этабының бөтенләй булмавы турында яза [Кшибеков, с. 93].

Шул сәбәпле, монда кабиләчелек, социаль, тел һәм дөньяга караш мәсьәләсендә каршылыклар була да алмый. Бу исә Хуҗа Әхмәт Ясәви хикмәтләренең төрки телдә язылып, телдән телгә күчеп, дала буйлап халык арасында таралуына һәм язучының исемен популярлаштыруга китергән. Аның «Дивани хикмәт» җыентыгы ислам кабул иткән төркиләрнең динен һәм телен, аның чисталыгын саклауга хезмәт итте. Алай гына да түгел, кайбер галимнәр Хуҗа Әхмәт Ясәвине төрки теленең мәртәбәсен күтәрү җәһәтеннән, Алишер Нәваидан да өстенрәк куялар. Мәсәлән, татар галиме Г. Сәгъди 1922 елда язылган мәкаләсендә болай ди: «Димәк, төрки теленә карата булган фарсы басымына каршы торуда, төрки теленең тамырларын тирәнәйтеп, аны үстерүдә төп рольне Нәваи түгел, бәлки Ясәви башкарган» [Саъдий, с. 16]. Төрки галиме Н.К. Зейбек, Ясәви үз заманында икенче дәрәҗәгә калдырылган төрки теленең мәртәбәсен күтәрү өчен үзенең хикмәтләрен максатчан рәвештә төрки телендә язган, дигән фикер әйтә [Зейбек, с. 51]. Шулай да Хуҗа Әхмәт Ясәви нәкъ шундый максат куйган, дип үк әйтүе кыен. Безнеңчә, аның төрки телендә язуының максаты тагын да югарырак. Ул максат – гади халыкка үзенең хикмәтләрен аңлаешлы телдә җиткерү. Кешелек дөньясындагы кыйммәтләр өчен көрәшүче бөек зат буларак, ул халыклар арасында фетнә тарату максатын һич тә куя алмас иде. Моннан тыш, гомуми фарсылашу утрак тормышлы төркиләргә,

Сәлҗүкләр дәүләтенә генә кагылды. Ә Ясәви яшәгән даирәдәге вәзгыять – бөтенләй башка. М.Ф. Күприле, мәсәлән, Хуҗа Әхмәт Ясәвинең төрки һәм согди телләрендә сөйләшүче аргулар арасында гомер кичерүен, аргуларга исә чит телләрнең тәэсире зур булуы хакында яза [Көпрүлү, с. 196]. Ләкин шунысы ачык билгеле: Ясәви үзенең хикмәтләрен аерым кабиләләр өчен генә түгел, ә бөтен халык өчен язган. Ул заманда төркиләрнең күпчелеге күчмә тормышта яши, язу кулланмый, Ясәвинең төрки телле хикмәтләрен исә, фольклор поэзиясе принципларын кулланып, бер-берләренә тараталар. Шул рәвешчә, Ясәви хикмәтләре халык арасында бик тиз популярлаша, бу, үз чиратында, төрки теленең мәртәбәсен күпкә күтәрә һәм халыкта яңага омтылуның, әдәби танып-белүнең үсешенә бик нык тәэсир итә.

Суфичылык идеяләрен төркиләргә аңлатып бирүдә, халыкның аң-белемен күтәрүдә Хуҗа Әхмәт Ясәвинең төркиләр дөньясында язма да, телдән дә киң таралган «Дивани хикмәт» әсәренең өлеше тиңдәшсез. Әлбәттә, күчмә төркиләр элек тә мистик хезмәтләр белән таныш булганнар. Бу сүзләрне Йосыф Баласагуниның «Котадгу белек» һәм Әхмәт Югънәкинең «Хакыйкать сые» хезмәтләре куәтли. «Дивани хикмәт»нең шулай зур таралышка ия булуының төп сәбәбе – аның эчтәлегенең тирән мәгънәле булуында һәм халык авыз иҗатына якын сәнгатьчә эшләнешендә. М.Ф. Күприле: «Х.Ә. Ясәви әсәренә, элек әйтелеп үткәнчә, ике төп үзенчәлек хас: исламчалык, ягъни аның әсәрләренең дини-суфичылыгы һәм халыкчанлык, ягъни халык иҗатыннан килә торган сәнгатьчәлекнең булуы. Исламчылык үзенчәлеге әсәрнең исемендә, эчтәлегендә, мәгънәсендә чагылыш тапса, милли үзенчәлек исә шигырь төзелешендә, үлчәмендә, ритмикасында чагылыш таба. Исламны яңарак кабул иткән һәм бу диннең асылына төшенергә омтылган төркиләр формасы һәм эчтәлеге ягыннан үзләренә һич тә ят булмаган әлеге әсәрләргә югары бәя бирәләр. «Дивани хикмәт» халыкның аңына сеңә, хәтта халык арасында чын-чынлап изге сүзләр дип кабул ителә башлый», – ди [Көпрүлү, с. 225]. Бик тә урынлы әйтелгән фикер. Шулай да «Дивани хикмәт»нең халык арасында киң таралуына аның фәкать фольклор стилендә иҗат ителүе төп сәбәп булды дисәк, бу фикер берьяклы булыр иде. Катлаулы әсәрне җиңел үзләштерү, аны кабул итү өчен моңа әзер мохитнең булуы шарт. Ясәви гомер сөргән заманда нәкъ менә шундый вәзгыять туган була. «Дивани хикмәт» ислам кабул иткән дәүләтләрдә генә түгел, буддизм хөкем сөргән каракытайлар арасында да киң тарала. Шәригать законнарын катгый формаларга салырга омтылган догматизмлы урыннарда түгел, ә тәрикать һәм хакыйкать әдәпләрен бик үк исәпкә алмый торган, дин кагыйдәләреннән хәбәре аз булган кавемнәргә нәкъ шундый язылыш кирәк булган. Бу бер, ә икенчедән шушы өлкәләрдә суфичылыкта элеккеге гореф-гадәтләрнең

эзләре күп иде. Суфичылык юлының билгесез бер вәкиле болай ди: «Суфилык орлыгы Адәм атабыз заманында сибелеп, Нух пәйгамбәр заманында үсеп, Ибраһим пәйгамбәр заманында чәчәк атып, Муса пәйгамбәр заманында тармакланып, Гайсә пәйгамбәр заманында пешеп, Мөхәммәд пәйгамбәр заманында көчле шәрабкә әверелде» [Қазақстан республикасындағы...]. Бу сүзләр суфичылык тарихы турында мул хәбәр була ала. Һәр пәйгамбәргә килгән диннең хакыйкате төрләндерелеп, шуннан төп формага китерү хаҗәте туганлыктан, киләсе дин килгәнгә хәтле руханият тазалыгы өчен көрәшкән суфилар кешелек тарихының һәр чорында булган. Анахарсис (Анык Арыс), Тонъюкук, Коркыт атаның суфилык юлыннан рухи куәт алганлыгы, аларның әүлиялыгы шик тудырмый. Моны аларның могҗиза аркасында гына диярлек сакланып калган кайбер уй-фикерләре раслый, алар, нигездә, суфи поэзиясе вәкилләренең сүзләренә тәңгәл. Ходай илчесе саналган пәйгамбәрләрнең, хакыйкать өчен көрәшкән суфиларның күчмә төркиләргә йогынтысы бик көчле булганын күпләгән тарихи мәгълүматлар раслый. Бу шулай ук Ясәви хикмәтләренең халык арасында киң таралуына уңай шартлар тудырган фактларның берсе.

Күчмә төрки кабиләләренең ислам динен ни рәвештә кабул иткәне турында моңа кадәр төпле фикерләр әйтелгәне юк дияргә була. Күп кенә галимнәр бу фактка шул чордагы карашлардан, иҗтимагый-сәяси вәзгыятьтән чыгып, үз фикерләрен белдерделәр. Мәсәлән, далабызга ислам дине килеп керү факты турында сөйләгәндә «гарәп экспансиясе», «гарәп баскынчалыгы» кебек терминнар кулланылган булу – бәянең иҗтимагый-сәяси вәзгыятьтән чыгып бирелгән булуына ачык дәлил. Мөхәммәд (с.г.с.) пәйгамбәр һәм Гарәп хәлифәтенең башында торган аның сәхәбәләрен «баскынчылар», ә алар яшәгән тарихи чорны «баскынчылык» дип атау бөтенләй дөреслеккә туры килмәве ачык аңлашыла.Киң күңеллелек, гуманлылыкка нигезләнгән идарә итүне илдә төп идарә ысулына әверелдерергә омтылган, шуны бөтен дөньяга таратырга тырышкан пәйгамбәрнең гамәлләрен «баскынчылык сәясәте» дип атау мантыйкка сыешмый. Әлбәттә, мондый ялгыш карашны пәйгамбәребез белән аның күренекле сәхәбәләренең гаҗәеп рухи дәрәҗәгә ирешкәнлегең һәм көнчелек, мәкер кебек төшенчәләрнең алар күңеленә гомумән ят булганлыгын аңларга теләмәгән атеистик карашлы кешеләр алга сөрә. Фәкать рухи яктан алга киткән кеше генә – ә алар киң күңеллелек һәм сафлыкның гәүдәләнеше – бу күренешне бөтен тулылыгы белән аңлый ала. Аның өстенә, күчмә төркиләр яшәгән далада гарәпләр белән нинди дә булса хәрби бәрелеш булуы хакында мәгълүмат бирә торган бер генә документ-таныклык та юк. Гарәп миссионерларының казакъ далаларына күпләп килеп, мәктәп-мәдрәсә ачып, халык арасында аң-белем таратулары турындагы мәгълүматларга

шулай ук ия түгелбез. Далага вакытлыча килгән берничә гарәп сәяхәтчесе турында гына аз-маз мәгълүмат бар. Шуннан чыгып, кайбер галимнәр «төркиләр ислам динен үз ирекләре белән кабул иткән» дигән фикергә килгәннәр. Бүгенге көнгә кадәр төркиләрнең исламны нилектән шулай тиз кабул итүе хакында тирән фәнни анализ ясалганы юк.

Чыннан да, төркиләрнең ни өчен исламны кабул итүен дөрес төшендереп бирердәй, материалистик карашларга нигезләнгән фәнни бәяләмә әлегәчә юк. Күчмә кабиләләр арасында исламга кадәр дә, аннан соң да руханият бөеклегенә җиткән әүлияләр һәр заманда – исламга кадәр дә, аннан соң да – күп булган. Бу белемнәрне үзләштерү өчен мәктәп-мәдрәсәдә озак еллар буе белем алу шарт түгел. Язу-сызуны белмәсә дә, даны белән бөтен галәмне таң калдырган хәзрәти Мөхәммәд (с.г.с.) пәйгамбәрнең гомер юлы моның ачык мисалы була ала. Аллаһының үзе белән элемтәгә керү нәтиҗәсендә алынган рухани белем аңа баш ияргә мәҗбүр итә. Коръәннең «Бәкара» сүрәсе 31 нче аятендә Аллаһы тәгаләнең Атабыз Адәмгә ничек итеп белем ирештерүе хакында сөйләнә. Моннан шундый нәтиҗә ясарга була – рухи, изге белем кайсыдыр бер мизгелдә Аллаһ тарафыннан бирелә һәм аңа ия булыр өчен ниндидер вакыт аралыгы үтү тиеш тә түгел. Әмма моннан чыгып, рухи белемгә ирешү җиңел генә башкарыла икән дигән нәтиҗә ясарга ярамый. Ул берөзлексез эзләнү, армый-талмый эшләү нәтиҗәсендә килә. Эзләнү, кагыйдә буларак, мондый этапларны үз эченә ала: иң элек үз-үзеңне танып-белү – «кем мин, каян мин, һәм кая барам» кебек сорауларга җавап табу, аннан – бар итүче Аллаһны тану һәм аны беркайчан да истән чыгармыйча, аның белән даими бәйләнештә тору халәтенә омтылу, аңа табынып яшәү. Күчмә халыкларга мондый нәтиҗәгә ирешү өчен сәбәпләр җитәрлек булган. Рухи эзләнүдә иң нык киртә – матди байлык артыннан куу. Әмма күчмә тормыш рәвеше алып баручыларга мондый куркыныч янамаган. Мондый төр хуҗалыкны алып баруда әйберләрнең күплеге файдага караганда күбрәк зыян китергән. Шунлыктан күчмә тормышта яшәүчеләр арасында милек аермалылыгы әллә ни күп булмаган.

Күчмә тормыш белән яшәүчеләрдә мәктәп-мәдрәсә салып, ел әйләнәсендә анда балалар укыту мөмкинлеге дә булмый. Алда әйтеп узганыбызча, бу хәл рухи белем алуда киртә тудырмый. Исламда белем ике типка бүленә: батини (эчке, йөрәк белеме) һәм захири (тышкы), ягъни язу-сызу белән бәйләнешле белем. Укый-яза белгән мөселманнар күп очракта фикх, шәригать белемнәренең тоткынлыгында калып, йөрәк белән бәйле изге белемнән күп очракта ераклашалар. Семиотека белгече Ю. Лотман авыз иҗаты һәм язма мәдәниятләрне чагыштырып, язма мәдәниятнең адәмнәрне эгоист итеп тәрбияләвен, ә авыз иҗаты, ягъни сөйләмгә нигезләнгән мәдәниятнең кешеләрне киң күңеллелеккә, гаделлеккә өндәве хакында әйтә

[Лотман, с. 246–247]. Чыннан да, китаптан белем алган суфый, үзүзе белән генә калганда, үзе турында югары фикергә ия булу хисләре белән яши башлый. Күчмә җәмгыятьтә исә, халык авыз иҗаты зур үсеш алу нәтиҗәсендә, башкалардан аерылып тору, зирәклек, әңгәмә коруга омтылу һәм шәхси үрнәк күрсәтү бик югары бәяләнгән. Ләкин монда рухани белем күчмә тормышта яшәүчеләр арасында гына тарала ала һәм шуның белән утрак тормышка күчүнең кирәге юк дигән фикер калырга тиеш түгел. Ул утрак кабиләләрдә дә киң таралган һәм язма мәдәният әлеге өлкәгә бәяләп бетергесез файда китергән. Биредә фәкать күчмә тормыштагыларның рухи үсеше өчен кирәкле булган алшартлар турында гына сүз бара. Һәм бу вәзгыять үзенең куанычлы нәтиҗәләрен бирде: күчмәләр арасыннан чыккан әүлияләр сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да шактый.

Югары рухи белемгә ирешкән әүлияләр барысы да Хакыйкатьне аңлаучылар булганнар. Сиземләү, тою кебек сенсор сыйфатлар барлыкка килү сәбәпле, алар башкаларга билгеле булмаган яшерен дөньяларны күрә һәм аңлый алганнар. Шул сәбәпле, бөтен дөньядагы әүлияләрнең сүзләрендә һәм гамәлләрендә, кагыйдә буларак, Аллаһның барлыгына һәм берлегенә мөнәсәбәттә бердәм караш булган. Әгәр ислам хак дин икән, хакыйкатьтә язу-сызуны белмәүче кешеләр дә (шулай ук укый-яза белүчеләр дә) Изге китаплардан башка да хикмәт нигезләренә ирешә алганнар, дигән сүз. Төркиләрнең исламны уңай кабул итүенең сәбәбе дә шушыннан килеп чыга. Ислам пәйда булып, бөтен дөньяга тарала башлаган чорда ук инде төркиләр арасында изгеләр, әүлияләр булган һәм алар рухи белемне максатчан куллану нәтиҗәсендә зур уңышларга ирешкәннәр. Ә. Диваев язган бер риваятьтә мондый вакыйга китерелә: «Мөхәммәд (с.г.с.) пәйгамбәр үзенең сәхәбәләре белән Өхед тавында дингә каршы дошманнары белән сугышып ятканда бик авыр хәлдә калалар, чөнки дошманнарына төрле яклап ярдәм килә. Сәхәбәләр Ходайдан ялварып ярдәм сораганда, билгесез бер кабилә кешеләре көтмәгәндә мөселманнар ягына чыга. Пәйгамбәребез (с.г.с.) алар белән башта гарәпчә, аннан фарсы телендә сөйләшмәкче була, ләкин алар аны аңламый. Аннан Әбү Бәкер аша ул аларның Төркестан ягыннан килгән кешеләр икәнен белә һәм үзенең әмерләрен төрки телдә бирә башлый. Төркиләр исә әлеге яуда дин дошманнарын тар-мар итә» [Диваев, с. 218–219]. Бу риваятьнең чынлыкка якын яклары күп. Төрки кабиләләрдән чыккан, хәзер безгә исемнәре билгесез әүлияләрнең исламны әүвәл баштан хуплаганын, ярдәм күрсәткәнен дәлилли торган фактлар да бар. Мәхмүд Кашгарыйның «Диване лөгат-эт төрк» хезмәтендә мондый кызык бер мәгълүмат бар: «Бар итүче Аллаһның төркиләр яши торган җиргә махсус йолдыз – иминлек оясы җибәргәнен һәм гарешнең (космос) юнәлешен биредә алар идарә иткән заман өчен уңай якка юнәлтүен

күрдем мин. Аллаһ аларны «төркиләр» дип атады. Шуннан аларны мәмләкәтле (дәүләтле) итте. Заманыбыз идарәчеләрен төркиләр арасыннан сайлады; дәвер, халыкларның акыл-ирек тезгенен аларның кулына тоттырды; аларны адәмнәргә баш кылды; хак эшләрне аларның кулына тапшырды, алар белән бергәләп көрәшкәннәрне изге итте һәм төркиләр тотынган һәр эшне максатына җиткереп, яманнардан, залимнәрдән яклады».

Шәйх Әбүбәкернең ахырзаман турында язган бер китабында пәйгамбәребезнең мондый хәдисе бәян ителә: «Олуг бар итүче: «Минем бер төркем гаскәрем бар, аларны «төркиләр» дип атадым, аларны көнчыгышка урнаштырдым. Берәр халыкка ачулансам, төркиләрне шуларга каршы җибәрермен», – диде» [Егеубай, с. 7]. Хәзерге тарихчыларның күп кенә тарихи вакыйгаларның төп максатын, мәсәлән, төркиләрнең Көнбатышка ясаган хәрби яуларын, Идел патша (Атилла), Чыңгыз хан яуларын әлегәчә төгәл генә аңлатып бирә алмаулары сер түгел. Орхон язмаларында да, «Монголның күчермә шәҗәрәсе»ндә дә, халык авыз иҗатында да төрки каганатларның хәрби һөҗүмне Аллаһ әмере белән башлаулары турында әйтелә. Аларны үз заманындагы халыклар «Аллаһ кылычы», «Аллаһ камчысы» дип атаган. Көнбатыш чыганакларындагы тарихи мәгълүматларга таянып, Идел патшага бәйләнешле шушы хакыйкать турында С. Өтениязов мондый нәтиҗә ясый: «VIII гасыр риваятьләрендә Атилланың Галлияга (хәзерге Франция җире) яу чабуы, бер генә корылманы, храмны, шәһәрне дә калдырмыйча, барысын җир белән тигезләве хакында сөйләнә. Биредә үк Атилланың гадел, акыллы, данлыклы дәүләт эшлеклесе, бөек полководец булуы да бәян ителә. Шунлыктан аны Аллаһның җирдәге илчесе итеп таныган төрле мифлар да таратылган. Аны Европа халыклары латин, француз, испан, немец, инглиз һ.б. телләрендә «Аллаһ камчысы (урысча «Бич Божий») дип атады» [Өтенияз, с. 154]. Шушындый ук сүзләрне Чыңгыз хан турында да сөйлиләр. Ислам дөньясы аны галиҗәнаб Раббы үзе җибәргән һәм ул Хозыр Ильясның ярдәмчесе дип исәпләнгән. Моны ислам ияләренә яхшы танылган «Тазкират әл-әүлия» («Әүлияләр турында истәлек») исемле язмалар җыелмасы калдырган Фәрит эд-дин Гаттарның тормыш юлы һәм эшчәнлеге турындагы хикәяттән дә аңларга була. «Чынгызхан Нишапурга басып керде һәм аның каты әмере буенча, яугирләр калада яшәүчеләрне аяусыз кыра башлады. Халык ярдәм сорап Гаттарга килде. Ул алдындагы касәсен әйләндергән иде, гаҗәп хәл булып, Чынгызханның гаскәре күрмәс булды. Кан кою тукталды. Чыңгыз хан ачуланып, гаскәрне сугышырга боерды. Икенче көнне яугирләр кабат кан коюга керешкәч, шәһәр кешеләре янә Гаттарга ярдәм сорап бардылар. Ул касәсен янә бер әйләндерде, гаскәрнең күзе янә күрмәс булды, кан кою туктады. Өченче көнне Чыңгыз хан үзе җәзалауда

катнашырга карар кылды һәм аның әмере буенча янә кан кою башланды. Шәһәр халкы кабат Гаттарга барырга мәҗбүр булды. Гаттар касәсенә кулын суза башлаган гына иде, күз алдына Хозыр Ильяс килеп, болай диде: «Синең Аллаһ эшенә тыкшынырга хакың юк. Сиңа ансыз да алда кылган гамәлләрең өчен җавап бирергә туры киләчәк, әгәр бу юлы да тыкшынсаң, аның ахыры синең өчен бик начар тәмамланачак» [Фарид ад-дин Аттар, с. 23]. Моннан соң Гаттар Чыңгызхан яугирләренең кулыннан һәлак буладыр [Фарид ад-дин Аттар, с. 23, 24]. Билгеле тарихчы Л.Н. Гумилев Чыңгызханның оныгы Батыйны урысларның «шәфкатьле хан» дип атаулары турында яза [Гумилев, с. 124–125]. Бу хакыйкать Мәхмүт Кашгарый китабында китерелгән хәдис белән дә туры килә. Ходайның әмерен төгәл үтәү һәм аның белән туры элемтәдә тору өчен рухани белемнең булуы шарт. Барлык пәйгамбәрләрнең, сәхәбәләренең, алардан соң килгән тәбигыйннарның, әүлияләрнең тормыш нигезен күктән иңгән рухи белем тәшкил иткән. Кыпчак даласында гомер кичергән әүлияләр үзләренең рухи белемнәрен халыкка түкми-чәчми тараткан. Аларның тормыш юлы, яшәү рәвешләре халык тарафыннан югары ахлакый үрнәк итеп кабул ителде һәм соңыннан милли гореф-гадәт, традицияләргә әйләнде.

Алда әйтелгәннәрдән күренгәнчә, беренчедән, күчмә тормышта яшәүчеләр арасында рухи белем киң таралган һәм аңа нигез салучы булып Хуҗа Әхмәт Ясәви тора һәм, икенчедән, аның хикмәтләре халык фольклоры белән тыгыз бәйләнештә. Рухи белемнең кыпчак даласында киң таралуының тагын бер сәбәбе – Ясәви заманында булган толерантлык һәм дини иркенлек. Тарихи мәгълүматлар күрсәткәнчә, ул чорда каракытайлар һичнинди динне кысмаганнар [Мыңҗан, с. 124–125]. Каракытайлар – борынгы күчмә төрки халыкларның традицияләренә тулаем тугры кабиләләр. М. Кашгарыйның «Диване лөгат-эт төрек» хезмәтенә таянып, галимә Ш. Шәмсетдинова болай дип яза: «Каракытайлар – хәзерге каракалпак милләтенә нигез салучы алты төрки халыкның берсе. Кытайлар – борынгы (Чин) дәүләтен төзүчеләр. М. Кашгарый аларның Урта һәм Югары Чинда яшәгәнлекләре турында яза. Төркия тикшеренүчесе З. Куртер гарәпләрнең XI–XII гасырларда каракалпакларны шушы кабилә исеме белән «кытай», йә «каракытайлар» дип атауларын искәртә» [Шәмсетдинова, с. 189]. Шәригать законнары өстенлек алып, догматизм тамыр җәйгән җәмгыятьтә изге рухи белемне үстерү дә, тарату да бик авырга туры килер иде. Хуҗа Әхмәт Ясәви хикмәтләрендә һәм халык авыз иҗаты әсәрләрендә еш кына дини фанатикларның суфыйларга каршы торганлыгы хакында сөйләнә. Алар чыгышлары буенча, башлыча, чит дәүләтләрдән була һәм аларның суфиларга каршы алып барган эшчәнлеге, нигездә, уңышсыз тәмамлана. Мәсәлән, Хуҗа Әхмәт Ясәвине дин бозучы

дип исәпләп, аны туры юлга күндерү нияте белән, Төркестанга ислам дәүләтләреннән Баба Машын белән Имам Меруазид исемле кешеләрнең килүе мәгълүм. Әмма аларның өйрәтүләре уңыш китерми һәм ахырда алар үзләре Ясәвинең шәкертләренә әйләнәләр. Бу хакта Хикмәтләрдә дә, халык иҗатында да әйтелә.

Димәк, рухи белемнең кыпчак даласында таралуының төп сәбәбе – бу белемне үзе дә нык үзләштергән Хуҗа Әхмәт Ясәвинең хезмәтләре. Хәзерге көндә «Ясәви юлы» дигән төшенчәнең төркиләр арасында киң таралган булуы – моның ачык мисалы. Алай да моны Ясәви үзе уйлап тапкан юл дип уйлау зур ялгышлык булыр иде. Ясәви юлы – пәйгамбәрләрнең, изгеләрнең, әүлияләрнең озын, авыр хакыйкать юлы. Ясәви өйрәтүләре буенча, бу юлның юлбашчысы – Мөхәммәд (с.г.с.) пәйгамбәр. Үзбәк әдәбияты белгече, суфичылыкны өйрәнүче галим, профессор Н. Комилов яза: «Ясәви фикерләре буенча галәмнең нигезендә Мөхәммәд (с.г.с.) нуры ятадыр. Аллаһы әүвәл шул Нурны, аннан бөтен галәмнең төзелешен бар итте. Бу Нур – галәм сылулыгы белән тән камиллеге. Ясәви үз рухын да шушы Нурга тәңгәл дип саный. "Мигъраҗ кичәсендә хак Мостафа рухым күрде", – дип яза ул. Бу – Мигъраҗ төнендә Пәйгамбәр күктә күргән Нурга ишарә. Хәзер мин дә шушы Нурдай пакъмен, шушы Нурдан яратылганмын, мин Пәйгамбәрнең эшен дәвам итүчемен, минем көчле яратуым Пәйгамбәрнең көчле яратуының дәвамыдыр. Ахыр килеп, Ясәвинең остазы, юл күрсәтүчесе Арстанбаб, 400 ел буена үзенең тел астында Пәйгамбәр биргән хөрмә җимешен саклап, соңыннан аны Әхмәткә биргән иде, ягъни Ясәви Мөхәммәд (с.г.с.) фикеренең, Мөхәммәд (с.г.с.) сөннәтенең һәм Мөхәммәд (с.г.с.) тәрәккыятенең мирасын дәвам итүче булып чыга» [Комилов, с. 84]. Димәк, Ясәви юлы – аның үзе салган юл түгел, аның юлы – үзе йөргән һәм үз артыннан халыкны дөрес юлга алып барган юл. Ясәви үзе тараткан рухи белемне «Хал белеме» (Учением Хал) дип атады. Ул галимнәрнең «каля» фәнни өйрәнүләре белән параллель рәвештә бара. Каль сүзе гарәпләрнең «каля», ягъни «әйтү» дигән сүзеннән килеп чыккан. Суфиларда каля – әйтү, сөйләшү, аңлату юлы белән җиткерергә мөмкин булган белем, ягъни адәм өйрәтә ала торган белем булса, «хал»ны тел белән генә аңлату мөмкин булмаганлыктан, монда инде белемгә остазлыкны Аллаһ үзе кыла. Бу турыда Ясәви юлының күренекле вәкиле Мәшһүр-Җосуп Копейулы болай дигән: «Гыйлем ике төрле була: каля белеме һәм хал белеме. Бәндәдән бәндә сабак алып, күз белән күреп, тел белән аңлатып уку «каля белеме» була. Бер бәндәдән бер бәндә мең ел өйрәнсә дә, аның нәтиҗәсе булмый. Күңел белән сабак алуның бер юлы бар, ул «хал белеме» дип атала. Күңелдәгесен җиткерүнең остазы – Аллаһы тәгалә үзе һәм хал белеме аның гыйлем сыйфатларының берсе буладыр. Якты нурның асылы Аллаһтан булса, гыйлем нурыннан яктырак,

гыйлем нурыннан көчле Нур бармы? Аллаһ тарафыннан җибәрелгән гыйлем нуры бер бәндәнең күңеленә керсә, «хал гыйлеме» шушы бәндәдә була [Мәшһүр-Жүсіп Көпеев, с. 327]. Каля белеменең максаты халыкка җиткерү булса, халның максаты – Аллаһка җитү. Хал фәненең казанышларына төшенмичә, каля гыйлеменең тоткынлыгында калу – суфи өчен иң аянычлысы, чөнки каля аша гына төп максатка ирешеп булмый, каля белеме белән генә ул кабергә кергәч алыначак сорауларга да җавап бирә алмаячак.

Мөнкир-Нәнкир: «Раббың, нәбиең кем?» – дип сорагач, Каля гыйлеменең бер ноктасы да эшкә ярамас, – диде бу турыда Хуҗа Әхмәт Ясәви [Иасауи Қожа Ахмет, с. 184]. Шунлыктан, әүлияләр солтаны кирәкле вакытта каля гыйлемен куллана белергә чакыра:

Каля гыйлемен укып,
Хал гыйлеменә җитеп, –

диде [Иасауи Қожа Ахмет, с. 202].

Хуҗа Әхмәт Ясәви өйрәткән хал гыйлеме йөрәктәге Раббыга булган мәхәббәтне уятырга ярдәм итә. Шуның аркылы ул халыкта кешелеклелек сыйфатлары тәрбияләде. Төрки халыкларның мәдәнияте белән сәнгатендә, әдәбиятында Хуҗа Әхмәт Ясәви һәм аның шәкертләре калыплаштырган традицияләрнең урыны түрдә. Ясәви өйрәткән хал гыйлеме төрки халыкларның рухи үсешен тизләтте. Бу үсеш теле, дине башка булган халыкларга да үзенең уңай тәэсирен җиткерде. Димәк, казакъ даласында рухи белем Ясәвигә кадәр дә булган, аннан соң да үсешен дәвам иткән.

Казакъ җәмгыяте һәм аларның борынгы бабалары булган саклар, хуннар, күк төркиләре белемнәрен арттыра барганнар, дини законнар чыгарганнар, әмма шул ук вакытта үзләре шушы законнар һәм догмалар тоткынына да әверелмәгәннәр. Алар Аллаһтан әмерләрне турыдан-туры әүлияләр генә ала дип исәпләп, бары тик рухи принципларга таянып эш иткәннәр. Әлбәттә, бу – күчмә кабиләләрнең һәр әгъзасы да әүлия булган дигән сүз түгел. Әүлияләр алдында баш иеп, мин-минлеккә салынмыйча, аларның әйткәннәрен хакыйкать рәтендә кабул кылып, чиксез багыну нәтиҗәсендә, фәкать үзләре кабул иткән рухани белемгә генә таянып эш итүләре кабиләнең барлык халыкларына да хас булган. Даланың һәр сүз остасы-ораторы рухани белемгә ия кеше булганлыгы мәгълүм. Аларны күчмә халык «әүлия» дип үсендергән. Моңа мисал итеп күренекле акыл ияләреннән Төле бинең псевдонимы «Карлыгач-әүлия», ә Бохар жырауның – «Бугаз-әүлия» булганлыгын әйтсәк тә җитәдер. Хакыйкать юлына басып, хак юлга килмәгән адәм кискен мизгелләрдә дөрес юл күрсәтә һәм ил белән лаеклы идарә итә алмый. Хәтта Европаның билгеле философлары да мондый югарылыкка ирешә алмаганнар. Рухи белемгә ирешү нигезләре какшау, хал белеме югалу сәбәпле, казакъ җәмгыятендә соңрак гадәттән тыш мөмкинлекләргә һәм ораторлык осталыгына ия булган кешеләр дә кимеде. Күренекле язучыбыз С. Муканов, андыйларны үз күзе белән

күргән кеше буларак, болай ди: «Казакъларда шәригатьтән бигрәк тәрикать үсеш алган булган» [Мұқанов, с. 62]. Бу сүзләргә зур мәгънә салынган. Совет язучысы, үз заманының күп кенә сәбәпләре аркасында, суфичылык темасы буенча иркенләп сөйли, яза алмаган.

Борынгы Анахарсисттан башлап, казакъ даласының мәшһүр акыл ияләре – Абай, Шәкәрим һәм Мәшһүр Җосупка кадәр – барысы да үзләренең күңел чисталыклары аркасында рухи, изге белемнәргә таянып эш иттеләр. Аларның хезмәтләре нәтиҗәсендә, кешеләр арасындагы көндәлек тормыш кирәк-яракларыннан башлап, эре социаль мәсьәләләргә кадәр, шулай ук традицияләр, гореф-гадәтләр, җәмгыятьтә нормалар да формалашты. Рухи өлкәдә зур эшчәнлек алып барган олы шәхесләргә һәм даланың фикер ияләре сызган юлга хөрмәт күрсәткән халык өчен күп нәрсәләр тормышка ашты. Шуңа да казакъларда, вакыт һәм пространство төшенчәсеннән караганда, традицияләрдә, телдә, дөньяга караш өлкәсендә аермалыклар әллә ни сизелмәде. Кайбер галимнәр моны күчмә тормыш рәвеше алып баруга бәйли. Әлбәттә, бу фактны да истән чыгарырга ярамый. Бигрәк тә соңгы гасырларда бер-берсе белән сәяси, мәдәни һәм икътыйсади бәйләнешләре өзелгән, төрле дәүләтләрдә яшәгән казакъ диаспоралары үзләренең телләрен, этник, дөньяга караш берлеген саклап кала алдылар, гәрчә моның күчмә тормыш рәвешенә бернинди катнашы булмаса да. Димәк, халык бердәмлегенең нигезендә алар таянган рухи белем ята, дип, ышаныч белән әйтә алабыз.

**Әдәбият**


*Гумилев Л.Н.* От Руси до России: Очерки этнической истории. М.: Айрис-пресс, 2004.

*Джавелидзе Э.Д.* У истоков турецкой литературы II. Юнус Эмре. Тбилиси: Мецниереба, 1985.

*Диваев Ә.* Тарту (Құрастырған, алғы сөзін жазған Ф. Оразаева). Алматы: Ана тілі, 1992.

*Егеубай А.* Махұт Қашқари. «Диуани луғат-ит-түрк» (XI) // Махмұт Қашқари. Түрік тілінің сөздігі: (Диуани лұға-ит-түрік): 3 томдық шығармалар жинағы (Қазақ тіліне аударған, алғы сөзі мен ғылыми түсініктерін жазған А. Егеубай). Алматы: ХАНТ, 1997.

*Зейбек Н.К.* Қожа Ахмет Йасауи жолы және таңдамалы хикметтер (аударған Д.К. Тұрсынбайұлы). Анкара: Бойут-Таң, 2003.

*Иасауи Қожа Ахмет.* Диуани хикмет (Даналық кітабы). Жинақты баспаға әзірлеп, қазақшаға аударғандар: М. Жармұхамедұлы, С. Дәуітұлы, М. Шафиғи. Алматы: «Мұраттас» ғылыми-зерттеу және баспа орталығы, 1993.

*Комилов Н.* Тасаввуф. Иккинчи китоб. Тавхид асрори. Тошкент: Ғафур Ғулом номидаги Адабиёт ва санъат хамда «Узбекистон нашриётлари», 1999.

*Көпрулу М.Ф.* Қожа Ахмет Ясауи танымы мен тағылымы. Зерттеулер (Баспаға дайындаған – К. Коч). Шымкент: 1999.

*Кшибеков Д.* Кочевое общество: генезис, развитие, упадок. Алма-Ата, Наука, 1984.

Қазақстан республикасындағы «Әзірет Сұлтан» мемлекеттік тарихи қорық-мұражайының №1068/5 ғылыми көмекші қоры.

*Лотман Ю.* Мәдениеттер типологиясы // Әлем. Альманах. Алматы: Жазушы, 1991.

Мәшһүр-Жүсіп Көпеев. Шығармалары. 9 т. Павлодар, 2006.

*Мұқанов С.* Таңдамалы шығармалар: 16 томдық. Т. 15 Халық мұрасы. Тарихи-этнографиялық шолу. Әдеби портреттер. Алматы: Жазушы, 1979.

*Мыңжан Н.* Қазақтың көне тарихы (Дайындаған М.Қани). Алматы: Жалын, 1994.

*Өтенияз С.* Аттила (ғылыми зерттеу). Алматы: Арыс, 2000.

*Саъдий А.* Ахмад Яссавий // Яссавий ким эди? (Мақолалар ва «Хикматлардан» парчалар) / туплаб нашрга тайёрловчи ва сузбоши муаллифи Б. Дусқораев. Тошкент: Абдулла Қодрий номидаги халқ мероси нашриёти, 1994.

Фарид ад-дин Аттар. Тазкират ал-аулийа, или Рассказы о святых / перевод Ольги Васильевой. М.: САМПО, 2005.

*Шәмшетдинова С.* М. Қашғарлының «Деуаны луғат-ит түрк» мийнетиндеги этнонимлер // Национальный фольклор народов Центральной Азии и проблемы духовного обновления общества: материалы международной научно-практической конференции. Нукус, 27–28 ноября, 2008 год. Нукус: 2008.

***Корганбеков Болат Сагынбек улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Л.И. Гумилев исемендәге*
*Евразия дәүләт университеты доценты, Астана*
*e-mail: bolat64@mail.ru*

УДК 517.3

*Ә.Ф. Галимҗанов, Ч.Б. Миңнегалиева*

# ГОМУМИЛӘШТЕРЕЛГӘН ИНТЕРПОЛЯЦИОН ПОЛИНОМИАЛЬ ОПЕРАТОР

В данной статье описывается построение оператора, который ставит в соответствие произвольной $2\pi$ -периодической функции с нулевым средним значением тригонометрический полином. Найден вид оператора, выведены соответствующие формулы. Приближение функций при помощи полученного полиномиального оператора проверено с помощью пакета Wolfram Mathematica.

**Ключевые слова:** дробное интегрирование, дробный интеграл Вейля, линейный оператор, тригонометрический полином, интерполяционный полином, полиномиальный оператор

## 1. Кереш

Интеграл исәпләүне вакланма тәртиптәге интегралларга да киңәйтү мәсьәләләре күптән өйрәнелә һәм аңа карата хәзерге вакытта зур кызыксыну күзәтелә. Вакланма тәртиптәге интегралларны исәпләү һәм вакланма тәртиптә дифференциаллау төрле өлкәләрдәге күренешләрне модельләштергәндә кулланыла [Горская, Галимзянов; Корчагина; Tenreiro].

Периоды $2\pi$ булган $\varphi(x)$ функциясе бирелсен, һәм ул түбәндәге рәвештә Фурье рәтенә таркатылсын: $\varphi(x) \sim \sum_{k=-\infty}^{\infty} \varphi_k e^{ikx}$, $\varphi_k = \frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi} e^{-ikx}\varphi(x)d\,x$. Уртача кыйммәте 0 булган функцияләр карала: $\varphi_0 = 0$. $\varphi^{(n)}(x) \sim \sum_{k=-\infty}^{\infty}(i\,k)^n \varphi_k e^{ikx}$ булганда, Вейль буенча вакланма тәртиптәге интеграл түбәндәгечә билгеләнә:

$$I_{\pm}^{\alpha}\varphi \sim \sum_{k=-\infty}^{\infty}\frac{\varphi_k e^{ikx}}{(\pm i\,k)^{\alpha}}.$$

Бу билгеләмәне башкача аңлатып була:

$$I_{\pm}^{\alpha}\varphi = \frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}\varphi(x-t)\Psi_{\pm}^{\alpha}d\,t\,,\ \alpha > 0,$$

биредә $\Psi_{\pm}^{\alpha}(t) = \sum_{|k|=1}^{\infty}\frac{e^{ikt}}{(\pm i\,k)^{\alpha}} = 2\sum_{k=1}^{\infty}\frac{\cos\left(k\,t \mp \frac{\alpha\,\pi}{2}\right)}{k^{\alpha}}$ [2].

Бу эштә периоды $2\pi$ булган функциягә $I_{\pm}^{\alpha}(T_n)\,(t_k) = I_{\pm}^{\alpha}(\varphi)\,(t_k)$ шарты үтәлерлек итеп (монда $t_k\ -(-\pi;\pi)$ дә бер-берсеннән тигез ераклыкта урнашкан нокталар) тригонометрик полином тиңдәш итеп куючы операторның рәвеше билгеләнә. Табылган формулалар Wolfram Mathematica системасы ярдәмендә тикшерелә.

## 2. Гомумиләштерелгән *An* полиномиаль операторын төзү

$H_n^T = \left\{ \frac{a_0}{2} + \sum_{k=-n}^{n} a_k \cos k\,t + b_k \sin k\,t \right\} = \left\{ \sum_{k=-n}^{n} c_k e^{iks} \right\}$ – дип дәрәҗәсе $n$ нан югары булмаган барлык тригонометрик полиномнар күплеген билгелик [1].

$A_n$ дип исә $\forall \varphi(t) \in C_{2\pi}$ гә $T_n(t) \in H_n^T$ полиномын тиңдәш итеп куючы сызыкча операторны билгелик һәм түбәндәге шартлар үтәлсен:

$$I_{\pm}^{\alpha}(T_n)(t_k) = I_{\pm}^{\alpha}(\varphi)(t_k),\ k = \overline{-n,n}, \qquad (1)$$

$t_k$ – бер-берсеннән бертигез ераклыкта урнашкан нокталар: $t_k = \frac{2k\pi}{2n+1},\ k = \overline{-n,n}.$

$\varphi(t) \in C(0,2\pi)$ булган һәм $c_0 = 0$ шарты үтәлүче функцияләр классын карыйк.

$A_n$ ны җентекләбрәк тикшерик.

$I_{\pm}^{\alpha}(\varphi;t) = \sum_{|k|=1}^{\infty} \frac{c_k e^{ikt}}{(\pm i\,k)^{\alpha}}$ – вакланма тәртиптәге Вейль интегралы табу операторы формуласы [2].

$A_n(\varphi;t) = \varphi_n(t) = \sum_{|k|=1}^{n} c_k(\varphi_n) e^{ikt}$ булсын, биредә $c_k(\varphi_n)$ – $\varphi_n(t)$ функциясенең комплекслы Фурье коэффициентлары. Димәк:

$$\sum_{|k|=1}^{n} \frac{c_k(\varphi_n) e^{ikt}}{(\pm i\,k)^{\alpha}} = I_{n\pm}^{\alpha}(\varphi)(t_j),\ t_j = \frac{2j\pi}{2n+1},\ j = \overline{-n,n}.$$

«Сулъяклы» вакланма тәртиптәге интегралны карыйк.

$I_{+}^{\alpha}(\varphi;t) = I^{\alpha}(\varphi;t)$ ($\Psi_{-}^{\alpha}(t) = \Psi_{+}^{\alpha}(t)$) икәнен билгеләп үтик).

Түбәндәге теорема үтәлә:

**1 нче теорема**

*$A_n(\varphi;t)$ полиномиаль операторын түбәндәге рәвештә күрсәтеп була:*

$$A_n(\varphi;t) = \frac{d^{\alpha}}{dt}(L_n(z;t)\ , \qquad (2)$$

*монда $L_n(z;t)$ – $z(t) = I^{\alpha}(\varphi;t)$, $\varphi(t) \in C(0,2\pi)$ функциясе өчен $t_{-n},...,t_n$ нокталары буенча Лагранж интерполяцион полиномы.*

**Исбатлау.**

$A_n$ коэффициентлары (2) бирелешендә күрсәтелсен.

Полиномиаль оператор (1) шартын канәгатьләндерә, димәк,

$$I^{\alpha}\left(\frac{d^{\alpha}}{d\,t}\left[L_n\left(I^{\alpha}(\varphi;t)\right)\right]\right)(t_k)=I^{\alpha}(\varphi;t_k),\ t_k=\frac{2k\pi}{2n+1},\ k=\overline{-n,n}.$$

$A_n(\varphi;t)$ ның рәвешен җентекләбрәк тикшерик.

$c_0=0$ булганда $T_n(\varphi;t)=\sum_{|k|=1}^{n}c_k e^{ikt}$, бу очракта $I^{\alpha}\left(T_n\right)=\sum_{|l|=1}^{n}\frac{c_l e^{ilt}}{(i\,l)^{\alpha}}$.

$L_n(z;t)=L_n\left\lfloor I_+^{\alpha}(\varphi;t)\right\rfloor=I^{\alpha}\left(T_n;t\right)$ икәне күренә.

Димәк $L_n(z;t)=\sum_{|k|=1}^{n}\frac{c_k e^{ikt}}{(i\,k)^{\alpha}}$,

Билгеләмә буенча, $\frac{d^{\alpha}x}{d\,t}(t)=D^{\alpha}(x;t)=\sum_{|k|=1}^{\infty}(i\,k)^{\alpha}c_k(x)e^{ikt}$.

Димәк, $D^{\alpha}\left(L_n(z;t)\right)=\sum_{|k|=1}^{n}\frac{(i\,k)^{\alpha}c_k e^{ikt}}{(i\,k)^{\alpha}}=T_n(\varphi;t)$.

Теорема исбатланды.

$A_n$ полиномиаль операторының рәвешен табыйк.

$$z(t_j)=T_n(z;t_j)=\sum_{|k|=1}^{n}\frac{c_k(\varphi)e^{ikt_j}}{(i\,k)^{\alpha}},\ j=\overline{-n,n}.$$

$T_n(z;t)$ – дәрәҗәсе $n$ булган күпбуын.

$$T_n(z;t)=L_n(z;t),\qquad (3)$$

монда $L_n(z;t)-$ $z(t)$ функциясе өчен $t_j=\frac{2j\pi}{2n+1}$ $j=\overline{-n,n}$ нокталары буенча $n$-нчы дәрәҗәдәге Лагранж интерполяцион полиномы. Һәм $c_0$ буыны юк (нульгә тигез).

Лагранж полиномын комплекслы формада языйк

$$L_n(z;t)=\sum_{k=-n}^{n}e^{ikt}\frac{1}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}z(t_j)e^{-ikt_j},$$

(3) тән

$$\sum_{|k|=1}^{n}\frac{c_k(\varphi)e^{ikt_j}}{(i\,k)^{\alpha}}=\sum_{k=-n}^{n}e^{ikt}\frac{1}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}z(t_j)e^{-ikt_j}$$

икәне табыла.

Коэффициентларның кыйммәтләрен табабыз

$$c_k=\frac{(k\,)^{\alpha}}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}z(t_j)e^{-ikt_j},\ k=\overline{-n,n}.$$

Аларны $T_n(\varphi;t)$ полиномына куябыз

$$T_n(\varphi;t)=\sum_{|k|=1}^{n}c_k e^{ikt}=\sum_{|k|=1}^{n}e^{ikt}\frac{(i\,k)^{\alpha}}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}z(t_j)e^{-ikt_j}=\frac{1}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}I^{\alpha}(\varphi;t_j)\sum_{|k|=1}^{n}(i\,k)^{\alpha}e^{ik(t-t_j)}$$

икәнлеге чыга.

Ягъни, $A_n(\varphi;t)=\dfrac{1}{2n+1}\sum\limits_{j=-n}^{n}I^{\alpha}(\varphi;t_j)\sum\limits_{|k|=1}^{n}(i\,k)^{\alpha}e^{ik(t-t_j)}$ . (4)

Түбәндәге теорема исбатланды:

**2 нче теорема.**

*$\forall\varphi(t)\in C_{2\pi}$ функциясенә $T_n(t)\in H_n^T$ полиномын тиңдәш итеп куючы һәм (1) шартларын канәгатьләндерүче сызыкча опретор түбәндәге рәвештә күрсәтелә ала*

$$A_n(\varphi;t)=\frac{1}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}I^{\alpha}(\varphi;t_j)\sum_{|k|=1}^{n}(i\,k)^{\alpha}e^{ik(t-t_j)}\,.$$

(4) тигезлегендә $(i\,k)^{\alpha}=|k|^{\alpha}e^{\frac{\alpha\pi i}{2}\operatorname{sgn}k}$ икәнен истә тотсак, $A_n(\varphi;t)$ полиномын түбәндәге рәвештә күрсәтеп була

$$A_n(\varphi;t)=\frac{1}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}I^{\alpha}(\varphi;t_j)\sum_{|k|=1}^{n}|k|^{\alpha}e^{i\left[k(t-t_j)+\frac{\pi}{2}\alpha\operatorname{sgn}k\right]}\,.$$

Без түбәндәге формуланы таптык:

$$A_n(\varphi;t)=\sum_{|k|=1}^{n}(i\,k)^{\alpha}c_k^{(n)}\left(I^{\alpha}(\varphi;t)\right)e^{ikt}\,.$$

$I^{\alpha}(\varphi;t)=z(t)$ булганга,

$$c_m(z)=\frac{c_m\left(D^{\alpha}(z)\right)}{(i\,m)^{\alpha}}=\frac{c_m(\varphi)}{(i\,m)^{\alpha}},\ z(const)=0,\ m\neq 0\,.$$

$$c_k^{(n)}(z)=\frac{1}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}e^{-ikt_j}\sum_{|m|=1}^{\infty}c_m(z)e^{-imt_j}=\sum_{|\mu|=1}^{\infty}c_{k+\mu(2n+1)}(z)=\sum_{|\mu|=1}^{\infty}\frac{c_{k+\mu(2n+1)}(\varphi)}{\left(i\left[k+\mu(2n+1)\right]\right)^{\alpha}}$$

$c_k^{(n)}(z)$ ны $A_n(\varphi;t)$ формуласына куйыйк:

$$A_n(\varphi;t)=\sum_{|k|=1}^{n}(i\,k)^{\alpha}\sum_{|\mu|=1}^{\infty}\frac{c_{k+\mu(2n+1)}(\varphi)}{\left(i\left[k+\mu(2n+1)\right]\right)^{\alpha}}e^{ikt}=$$

$$\sum_{|k|=1}^{n}e^{ikt}(i\,k)^{\alpha}\sum_{|\mu|=1}^{\infty}\left[\frac{k}{k+\mu(2n+1)}\right]^{\alpha}c_{k+\mu(2n+1)}(\varphi)$$

икәнен табабыз.

Комплекслы саннарның тригонометрик формада күрсәтелүен искә алып, (4) нең башка рәвешен күрсәтик.

$$A_n(\varphi;t)=\frac{1}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}I^{\alpha}(\varphi;t_j)\sum_{|k|=1}^{n}(i\,k)^{\alpha}e^{ik(t-t_j)}$$

$$(i\,k)^{\alpha}=|k|^{\alpha}e^{\frac{\alpha\pi i}{2}\operatorname{sgn}k},\ e^{\frac{\alpha\pi i}{2}\operatorname{sgn}k}=\cos(\frac{\alpha\,\pi}{2}\operatorname{sgn}k)+i\sin(\frac{\alpha\,\pi}{2}\operatorname{sgn}k).$$

Икенче сумманы аерым карыйк:

$$\sum_{|k|=1}^{n}(i\,k)^{\alpha}e^{ik(t-t_j)}=\sum_{|k|=1}^{n}|k|^{\alpha}e^{\frac{\alpha\pi i}{2}\operatorname{sgn}k}e^{i\,k(t-t_j)}=$$

$$\sum_{|k|=1}^{n}|k|^{\alpha}\left(\cos\frac{\alpha\,\pi}{2}+i\sin(\frac{\alpha\,\pi}{2}\operatorname{sgn}k)\right)\left(\cos k(t-t_j)+i\sin k(t-t_j)\right)=$$

$$=\sum_{|k|=1}^{n}|k|^{\alpha}\left(\cos\frac{\alpha\,\pi}{2}\cos k(t-t_j)+i\cos\frac{\alpha\,\pi}{2}\sin k(t-t_j)+\right.$$

$$\left.+i\sin\frac{\alpha\,\pi}{2}\operatorname{sgn}k\cos k(t-t_j)-\sin\frac{\alpha\,\pi}{2}\operatorname{sgn}k\sin k(t-t_j)\right)$$

$$=\sum_{|k|=1}^{n}|k|^{\alpha}\left(\cos\frac{\alpha\,\pi}{2}\cos k(t-t_j)-\sin\frac{\alpha\,\pi}{2}\operatorname{sgn}k\sin k(t-t_j)+\right.$$

$$\left.+i\left(\cos\frac{\alpha\,\pi}{2}\sin k(t-t_j)+\sin\frac{\alpha\,\pi}{2}\operatorname{sgn}k\cos k(t-t_j)\right)\right)=$$

$$=\sum_{k=-n}^{-1}|k|^{\alpha}\left(\cos\frac{\alpha\,\pi}{2}\cos k(t-t_j)+\sin\frac{\alpha\,\pi}{2}\sin k(t-t_j)+i\left(\cos\frac{\alpha\,\pi}{2}\sin k(t-t_j)-\sin\frac{\alpha\,\pi}{2}\cos k(t-t_j)\right)\right)+$$

$$+\sum_{k=1}^{n}k^{\alpha}\left(\cos\frac{\alpha\,\pi}{2}\cos k(t-t_j)-\sin\frac{\alpha\,\pi}{2}\sin k(t-t_j)+i\left(\cos\frac{\alpha\,\pi}{2}\sin k(t-t_j)+\sin\frac{\alpha\,\pi}{2}\cos k(t-t_j)\right)\right)=$$

$$=\sum_{k=1}^{n}k^{\alpha}\left(\left(\cos\frac{\alpha\,\pi}{2}\cos k(t-t_j)-\sin\frac{\alpha\,\pi}{2}\sin k(t-t_j)+i\left(-\cos\frac{\alpha\,\pi}{2}\sin k(t-t_j)-\sin\frac{\alpha\,\pi}{2}\cos k(t-t_j)\right)\right)+\right.$$

$$\left.+\left(\cos\frac{\alpha\,\pi}{2}\cos k(t-t_j)-\sin\frac{\alpha\,\pi}{2}\sin k(t-t_j)+i\left(\cos\frac{\alpha\,\pi}{2}\sin k(t-t_j)+\sin\frac{\alpha\,\pi}{2}\cos k(t-t_j)\right)\right)\right)=$$

$$=\sum_{k=1}^{n}k^{\alpha}\left(2\cos\frac{\alpha\,\pi}{2}\cos k(t-t_j)-2\sin\frac{\alpha\,\pi}{2}\sin k(t-t_j)\right)=$$

$$=2\sum_{k=1}^{n}k^{\alpha}\cos\left(\frac{\alpha\,\pi}{2}+k(t-t_j)\right).$$

$A_n(\varphi;t)$ полиномының башка күрсәтелешен таптык:

$$A_n(\varphi;t)=\frac{1}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}I^{\alpha}(\varphi;t_j)\sum_{|k|=1}^{n}(i\,k)^{\alpha}e^{ik(t-t_j)}=$$

$$=\frac{2}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}I^{\alpha}(\varphi;t_j)\sum_{k=1}^{n}k^{\alpha}\cos\left(\frac{\alpha\,\pi}{2}+k(t-t_j)\right).\qquad(4')$$

## 3. *An* операторы белән Фурье операторы арасында бәйлелек һәм якынайту хатасын бәяләү

Гомумиләштерелгән $A_n$ интерполяцион операторы белән $S_n$ Фурье операторы арасындагы бәйлелекне карыйк.

$$S_n(\varphi;t)=\sum_{k=-n}^{n}c_k(\varphi)e^{ikt}=\frac{1}{\pi}\int_0^{\pi}D_n(t-x)\varphi(x)d\,x,$$

монда $D_n(t)=\dfrac{\sin(2n+1)\frac{t}{2}}{\sin\frac{t}{2}}$ – Дирихле төше.

$$c_k(\varphi)=\frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}\varphi(x)e^{-ikt}d\,t.$$

Түбәндәге теорема үтәлә:

**3 нче теорема.**

*Ирекле $\varphi(t)\in C_{2\pi}$ функциясе өчен түбәндәге формула дөрес*

$$A_n(\varphi;t)-S_n(\varphi;t)=\sum_{|k|=1}^{n}e^{ikt}\sum_{|\mu|=1}^{\infty}\left[\frac{k}{k+\mu(2n+1)}\right]^{\alpha}c_{k+\mu(2n+1)}(\varphi), \qquad (5)$$

*һәм бу рәт уртача кыйммәте буенча җыелучан.*

**Исбатлау.**

$\alpha$ тәртип чыгарылмасы булган ирекле $\varphi(t)\in C_{2\pi}$ функциясе өчен түбәндәге тигезлек үтәлә:

$$\frac{d^{\alpha}}{d\,t}S_n(\varphi(x);t)=S_n\left\{\frac{d^{\alpha}}{d\,t}\varphi(x);t\right\}.$$

$$S_n\varphi-A_n\varphi=\frac{d^{\alpha}}{d\,t}\left[S_n(z_0;t)-L_n(z_0;t)\right].$$

Һәм биредә $\varphi_0(t)=\varphi(t)-c_0(\varphi)$,

$z_0(t)=I^{\alpha}(\varphi_0;t)$, $\varphi\in C_{2\pi}$.

$$S_n(z_0;t)-L_n(z_0;t)=\sum_{k=-n}^{n}\left(c_k(z_0)-c_k^{(n)}(z_0)\right)e^{ikt}.$$

$$S_n(\varphi_0;t)-A_n(\varphi_0;t)=\sum_{k=-n}^{n}(k)^{\alpha}\left(c_k(z_0)-c_k^{(n)}(z_0)\right)\cdots e^{ikt}.$$

$$\varphi_0(t)=\frac{d^{\alpha}}{d\,t}z_0(t).$$

$$c_k(z_0)-c_k^{(n)}(z_0)=c_k(z_0)-\sum_{\mu=-\infty}^{\infty}\tilde{n}_{k+\mu(2n+1)}(z_0)=-\sum_{|\mu|=1}^{\infty}\tilde{n}_{k+\mu(2n+1)}(z_0)=-\sum_{|\mu|=1}^{\infty}\frac{\tilde{n}_{k+\mu(2n+1)}(\varphi)}{\left(i[k+\mu(2n+1)]\right)^{\alpha}}$$

$$A_n(\varphi;t)-S_n(\varphi;t)=\sum_{|k|=1}^{n}(k\ )^{\alpha}\sum_{|\mu|=1}^{\infty}\frac{\tilde{n}_{k+\mu(2n+1)}(\varphi)}{\left(i[k+\mu(2n+1)]\right)^{\alpha}}e^{ikt}=$$

$$=\sum_{|k|=1}^{n}\sum_{|\mu|=1}^{\infty}\left[\frac{k}{[k+\mu(2n+1)]}\right]^{\alpha}e^{ikt}\tilde{n}_{k+\mu(2n+1)}(\varphi)$$ Бу рәт уртача кыйммәте буенча җыелучан. Теорема исбатланды.

**4 нче теорема.**

$\forall\varphi(t)\in C_{2\pi}$, $\frac{1}{2}<\alpha<1$ булганда $A_n(\varphi;t)$ җыела һәм:

$E_n^T(\varphi)_C\le\left\|\varphi-A_n\varphi\right\|_C\le\sqrt{1+\sigma_n^2}\,E_n^T(\varphi)_C$, биредә

$$\sigma_n^2=\max\sum_{\mu=1}^{\infty}\left|\frac{k}{k+\mu(2n+1)}\right|^{2\alpha}.$$

**Исбатлау.**

(5) шарты үтәлгәнгә һәм

$$A_n(\varphi;t)=\sum_{|k|=1}^{n}e^{ikt}(i\,k)^{\alpha}\sum_{|\mu|=1}^{\infty}\left[\frac{k}{k+\mu(2n+1)}\right]^{\alpha}c_{k+\mu(2n+1)}(\varphi)$$ булганга

$\forall\varphi(t)\in C_{2\pi}$ һәм

$$\varphi-A_n\varphi=(\varphi-S_n\varphi)+(S_n\varphi-A_n\varphi)=\sum_{|k|=n+1}^{\infty}c_k(\varphi)e^{ikt}-\sum_{|k|=1}^{n}\sum_{|\mu|=1}^{\infty}\left[\frac{k}{k+\mu(2n+1)}\right]^{\alpha}\tilde{n}_{k+\mu(2n+1)}(\varphi)$$

$S_n\varphi-A_n\varphi\in H_n^T$, $\varphi-S_n\varphi\notin H_n^T$ булганга, аларның скаляр тапкырчыгышы 0 гә тигез:

$$\left(\varphi-S_n\varphi,S_n\varphi-A_n\varphi\right)=0,\ \varphi\in C_{2\pi}.$$

Димәк,

$$\left\|\varphi-A_n\varphi\right\|_C^2=\left\|\varphi-S_n\varphi\right\|_C^2+\left\|S_n\varphi-A_n\varphi\right\|_C^2=$$

$$=\sum_{|k|=n+1}^{\infty}\left|c_k(\varphi)\right|^2+\sum_{|k|=1}^{n}\left|\sum_{|\mu|=1}^{\infty}\left[\frac{k}{k+\mu(2n+1)}\right]^{\alpha}\tilde{n}_{k+\mu(2n+1)}(\varphi)\right|^2\le$$

$$\le\sum_{|k|=n+1}^{\infty}\left|c_k(\varphi)\right|^2+\sum_{|k|=1}^{n}\left\{\sum_{|\mu|=1}^{\infty}\left|\frac{k}{k+\mu(2n+1)}\right|^{2\alpha}\sum_{|\mu|=1}^{\infty}\left|\tilde{n}_{k+\mu(2n+1)}(\varphi)\right|^2\right\}\le$$

$$\leq \sum_{|k|=n+1}^{\infty} \left| c_k(\varphi) \right|^2 + \sigma_n^2 \sum_{|k|=1}^{n} \sum_{|\mu|=1}^{\infty} \left| \tilde{n}_{k+\mu(2n+1)}(\varphi) \right|^2 \leq$$

$$(1+\sigma_n^2) \sum_{|k|=n+1}^{\infty} \left| \tilde{n}_k(\varphi) \right|^2 = (1+\sigma_n^2) \left\{ E_n^T(\varphi)_C \right\}^2, \varphi \in C_{2\pi},$$

$\sigma_n^2$ аша күрсәтелгән сумманы билгеләдек:

$$\sigma_n^2 = \max \sum_{\mu=1}^{\infty} \left| \frac{k}{k+\mu(2n+1)} \right|^{2\alpha}.$$

## 4. Wolfram Mathematica системасын куллану

Бу бүлектә Wolfram Mathematica системасында үткәрелгән исәпләүләр нәтиҗәсе китерелә. Чыгарылган формулаларны тикшерү өчен беренче очракта $\varphi(t) = \sin 3{,}6t$ функциясе алынды. $A_n(\varphi;t)$ полиномының кыйммәтләре (4′) формуласы буенча $\alpha = 0{,}6$ булганда $n = 8$ һәм $n = 50$ өчен табылды. 1 нче һәм 2 нче рәсемнәрдә графиклар күрсәтелгән.




**1 нче рәсем.** $n = 8$ булганда $\varphi(t) = \sin 3{,}6t$ функциясен $A_n(\varphi;t)$ полиномы белән якынайту




**2 нче рәсем**. $n$ = 20 булганда $\varphi(t) = \sin 3{,}6t$ функциясен $A_n(\varphi;t)$ полиномы белән якынайту

3 нче, 4 нче, 5 нче рәсемнәрдә $n = 50$ булганда һәм $\alpha$ төрле кыйммәтләр алганда $\varphi(t) = \sin 3{,}6t + \sin 2t$ функциясен $A_n(\varphi; t)$ полиномы белән якынайту күрсәтелгән.




**3 нче рәсем**. $n = 50$, $\alpha = 0{,}6$ өчен $\varphi(t) = \sin 3{,}6t + \sin 2t$ функциясен $A_n(\varphi; t)$ полиномы белән якынайту




**4 нче рәсем**. $n = 50$, $\alpha = 0{,}8$ өчен $\varphi(t) = \sin 3{,}6t + \sin 2t$ функциясен $A_n(\varphi; t)$ полиномы белән якынайту




**5 нче рәсем**. $n = 50$, $\alpha = 0{,}9$ өчен $\varphi(t) = \sin 3{,}6t + \sin 2t$ функциясен $A_n(\varphi;t)$ полиномы белән якынайту

$\varphi(t) = \sin 3{,}6t + \sin 2t$ функциясе өчен $\alpha$ төрле кыйммәтләр алганда, $n = 50$ булганда $|\varphi(t) - A_n(\varphi;t)|$ аңлатмасының максималь кыйммәтләре исәпләнде. Ике очрак каралды – беренче очракта интервал тулаем, икенче очракта интервалның урта өлеше алынды. Нәтиҗәләр 1 нче таблицада күрсәтелгән.

1нче таблица

$\varphi(t) = \sin 3{,}6t + \sin 2t$, $n = 50$ өчен $|\varphi(t) - A_n(\varphi;t)|$ ның максималь кыйммәтләре

| $\alpha$ | 0.6 | 0.7 | 0.8 | 0.9 | 0.95 | 0.99 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| $\max\|\varphi(t_i) - A_n(\varphi;t_i)\|$, $i = \overline{-n,n}$ | 1.53177 | 1.32091 | 1.07917 | 0.87513 | 0.64192 | 0.37329 |
| $\max\|\varphi(t_i) - A_n(\varphi;t_i)\|$ $i = \overline{-\frac{n}{2},\frac{n}{2}}$ | 0.05513 | 0.0533 | 0.04498 | 0.02799 | 0.01543 | 0.00326 |

6 нчы, 7 нче, 8 нче рәсемнәр $\alpha$ ның төрле кыймммәтләре өчен $|\varphi(t) - A_n(\varphi;t)|$ ның кыйммәтләрен күрсәтә.




**6 нчы рәсем**. $\alpha = 0{,}6$, $n = 50$ булганда $\left|\varphi(t) - A_n(\varphi;t)\right|$ның кыйммәтләре




**7 нче рәсем**. $\alpha = 0{,}8$, $n = 50$ булганда $\left|\varphi(t) - A_n(\varphi;t)\right|$ ның кыйммәтләре




**8 нче рәсем.** $\alpha = 0{,}9$, $n = 50$ булганда $\left|\varphi(t) - A_n(\varphi;t)\right|$ ның кыйммәтләре

## 5. Йомгаклау

Шулай итеп, периоды $2\pi$, урта кыйммәте 0 булган функциягә тригонометрик полином тиңдәш итеп куя торган интерполяцион операторны күрсәтә торган формулалар чыгарылды. Функцияне полином белән якынайту Wolfram Mathematica системасы ярдәмендә

тикшерелде. Системада эш бу төр мәсьәләләргә хас күренешне – $n$ саны үскәндә якынаюның төгәллеге артуын күрсәтте. $0,5 < \alpha < 1$ кыйммәтләре каралды. Шулай ук бирелгән функция кыйммәтләре һәм полином кыйммәтләре аермасы модуленең максималь кыйммәтләре күрсәтелде. Бу саннар буенча модуль кыйммәтләре белән $\alpha$ кыйммәтләре арасындагы бәйлелекне өйрәнеп була.

**Әдәбият**

*Горская Т.Ю., Галимянов А.Ф.* Обобщенный метод Бубнова-Галеркина для уравнений с дробноинтегральным оператором. [Текст] // Известия Казанского государственного архитектурно-строительного университета. 2014. № 4. С. 398–402.

Зигмунд А. Тригонометрические ряды. Том 1 [Текст] М.: Мир, 1965. С. 11–14.

*Корчагина А.Н.* Использование производных дробного порядка для решения задач механики сплошных сред [Текст] // Известия Алтайского государственного университета. 2014, № 1-1 (81). С. 65–67.

*Самко С.Г., Килбас А.А., Маричев О.И.* Интегралы и производные дробного порядка и некоторые их приложения [Текст]. Минск: Наука и техника, 1987. С. 263–267.

*Tenreiro Machado J.A., Alexandra M.S. F. Galhano, Juan J. Trujillo.* On development of fractional calculus during the last fifty years. Scientometrics, January 2014, Volume 98, Issue 1, pp 577–582.

***Галимҗанов Әнис Фуат улы,***
*математика фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университетының функцияләр теориясе кафедрасы доценты*
*e-mail: anis_59@mail.ru*
***Миңнегалиева Чулпан Бакый кызы,***
*педагогика фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университетының мәгълүмати системалар кафедрасы доценты*

УДК 821.512.145

*Д.Ф. Заһидуллина*

# ӘДӘБИЯТ ГАЛИМЕ МАНСУР ХӘСӘНОВ:
## Г. Ибраһимовның иҗат мирасын комплекслы өйрәнү

В статье рассматривается литературоведческая деятельность М.Х. Хасанова. Особое внимание уделено раскрытию научного таланта Мансура Хасановича как основного специалиста по творчеству Галимджана Ибрагимова.

**Ключевые слова:** Мансур Хасанович Хасанов, Галимджан Ибрагимов, татарская литература первой половины XX века.

Татарстан Фәннәр академиясенең беренче президенты, академик, күренекле җәмәгать эшлеклесе Мансур Хәсәнович Хәсәновны без, иң элек, татар әдәбияты тарихчысы, XX йөзнең беренче чиреге татар мәдәни, иҗтимагый, сәяси фикер тарихын җентекләп өйрәнгән галим, татар мәдәниятендәге төрле сәбәпләр белән оныттыруга дучар ителгән күп кенә сәхифәләрне халыкка кайтарган эзләнүче буларак беләбез. Менә илле елдан артык ул әдәбият белеме фәнендә төп «Ибраһимовчы» булып кала. Г. Ибраһимовның мирасын кайтару белән башланган фәнни эшчәнлек аны татар әдәбиятының бер гасырлык тарихына алып керә.

Галимнең әлеге фәнни теманы сайлавы ил тормышына 1960 елларда «Хрущев җепшеклеге» алып килгән үзгәрешләр белән бәйле. Алар татар мәдәниятенә дә зур йогынты ясый. Г. Ибраһимов, М. Җәлил, Х. Туфан кебек зур әдипләрнең исеме аклана һәм иҗатлары әдәби барышка кабат килеп кушыла. Моңа кадәр тыелып торган Дәрдемәнд, С. Сүнчәләй, Ш. Бабич, Н. Думави, Ф. Борнаш кебек әдипләр мирасы татар укучысына әйләнеп кайта. Шуларның сәнгати югарылыгын өлге итеп алырга мөмкинлекләр, әдәбиятта XX йөз башында калыплашкан традицияләрне дәвам итәргә шартлар туа.

Әдәбиятта һәм әдәбият белемендәге яңарыш бер дулкын булып күтәрелә. М. Җәлил (Р.Г. Бикмөхәммәтов, 1955; Н.Г. Юзиев, 1956), Ф. Кәрим (З.М. Мәҗитов, 1955), М. Гафури (Р.Ш. Максутова, 1955), Мирсәй Әмир (Ф.М. Хатыйпов, 1955), Ш.Камал (А.Г. Әминев, 1956) һ.б. әдипләр иҗаты буенча кандидатлык диссертацияләре яклана, XIX йөз, XX йөз башы әдәби хәрәкәтен колачлаган докторлык диссертацияләре әзерләнә (М.Х. Гайнуллин, Х.У. Госманов, И.З. Нуруллин, Г.М. Халитов) [Каримуллин А.Г., Каримуллин Ш.А., 156 с.]. Г. Ибраһимов мирасын 20 еллык өзеклектән соң халыкка кайтара башлау да шушы процессларның бер чагылышы булып тора.

Г. Ибраһимовны аклау хакындагы карар чыгуга (1955 елның 24 сентябре) [Галимджан

Ибрагимов..., с.76] аның иҗат мирасын кайтару комиссиясе оеша, өч томлык сайланма әсәрләрен басмага әзерләү эше башлана. Бу китаплар 1956 елны басылып та чыгалар. Шуның артыннан ук М.Х. Хәсәновның язучы тормышы-иҗатына багышланган, томнарга анализ ясаган мәкаләләре дөнья күрә. 1961 елда исә яшь галим Галимҗан Ибраһимовның Октябрьгә кадәрге иҗаты буенча кандидатлык диссертациясе яклый [Хәсәнов, 1961, 343 б.]. 1964 елда язучының күпсанлы әсәрләрен һәм тәнкыйди, фәнни хезмәтләрен системага салып язылган саллы монографиясе укучыга тәкъдим ителә [Хәсәнов, 1964, 331 б.].

Галимҗан Ибраһимов тормышы һәм иҗаты, күпкырлы эшчәнлеге аның гомерлек темасына әверелә [Хасанов, 1966, 26 с.; Хасанов, 1969, 432 с.; Хасанов, 1977, 432 с.]. 1971 елда Г. Ибраһимов шәхесенең Октябрь инкыйлабыннан соңгы чорына багышланган докторлык диссертациясен уңышлы яклый [Хасанов, 1971, 595 с.]. 1987 елны китап рус телендә «Язучы, галим һәм революционер» дигән исем белән Мәскәүдә дөнья күрә [Хасанов, 1987, 318 с.]. Язучының сигез томлыгын (1974–1987) әзерләүне башлап йөрүчеләрнең берсе дә, әлеге томнарның аерым китапларына кереш сүз язучы да М.Х. Хәсәнов була. 1956 елдан башлап гомеренең соңына кадәр галим даими рәвештә Г. Ибраһимовның иҗат мирасына, шул мирасның күләгәдәрәк кала килгән якларына багышланган мәкаләләр язудан туктамый.

Әлбәттә, фәнни эшчәнлектә бер теманы ярты гасыр дәвам итеп бару өчен әлеге теманың колачлы булуы кирәк. Чыннан да, Г. Ибраһимов татар мәдәниятендә Г. Тукай, Г. Исхакый белән янәшә куела торган гаять бай иҗат мирасы калдырган. Аның иҗтимагый-сәяси, фәнни-публицистик эшчәнлеге, фәлсәфи, нәзари карашлары да аерым тикшеренүләргә лаек. Бу очракта, галимнең – үз өйрәнү объектын табуы, ә Ибраһимов мирасының шундый тикшеренүчегә тапшырылуы олы нәтиҗәләргә китерә.

М.Х. Хәсәновның Г. Ибраһимов мирасын барлау юнәлешендәге эшчәнлеген бәяләү өчен, әлбәттә, сүзне әлеге историографиядә аның урынын билгеләүдән башларга кирәк. Чөнки Г. Ибраһимов – татар әдәбият белеме, әдәби тәнкыйть күз уңында торган шәхес. Иң беренче әсәрләре басылып чыгуга ук татар вакытлы матбугаты битләрендә аларга мөнәсәбәт белдерелә башлый [Тутый...; Кәримов...; Яңа әсәр... 3 июнь; Яңа әсәр... 17 июнь].

Ә инде язучының «Яшь йөрәкләр» кебек зур әсәрләре матбугат битләрендә зур-зур сөйләшүләргә азык була [Авыргазый...; Хөсни...; Җәләй...; Сәйфи...; Газиз...]. Әгәр XX йөз башында Г. Ибраһимов историографиясенә күз салсак, аның шактый киңкырлы булуы күзгә ташланыр. Язучы иҗатының романтик табигате, аның геройлар тудыру осталыгы, матур тел-стиле хуплау таба. Бигрәк тә «Яшь йөрәкләр», романтик хикәяләре, нәзари хезмәтләре җентекле анализлана. Әдәби иҗаты хакында

әтрафлы язмалар авторлары буларак Г. Гобәйдуллинны, Җ. Вәлидине, Н. Гасрыйны аерып күрсәтергә мөмкин. Нәзари хезмәтләре хакында Г. Сәгъди, Г. Рәхим, Ш. Әхмәдиев, Н. Думави, С. Сүнчәләй, Хөсни Кәрим һ.б. катнашында зур-зур бәхәсләр булып уза. XX йөз башы әдәбият белеме, әдәби тәнкыйть Г. Ибраһимовны зур язучы, фикер иясе буларак бәяли.

1917 елдан соң Ибраһимов сәяси көрәш вакыйгаларында кайнап яши. 1920–1930 елларда ул татар язучыларының чын лидеры, әйдаманына, яңа татар әдәбиятының үсеш юлын билгеләүче теоретикка әверелә.1920–1938 еллар аралыгында басылып чыккан әдәби әсәрләре татар әдәбиятының метод сайлау бәхәсләре үзәгенә куела. Ә инде 1938–1956 еллар аралыгында Г. Ибраһимовның мирасы гына түгел, исеме дә татар мәдәниятеннән алып ташлана.

Шулай итеп, әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеме фәненең игътибар үзәгендә торсалар да, Г. Ибраһимовның әсәрләре XX йөз башында әдәби барыштагы тулы бер мәктәп барлыкка китергән иҗат буларак бәяләнергә өлгерми. 1917 елдан соң мондый омтылышлар ясала: аерым алганда, Г. Сәгъди хезмәтләрендәге [Сәгъди, 1926, 300 б.; Сәгъди, 1930, 200 б.] монографик бүлекләр, күпсанлы мәкаләләре [Сәгъди, Мәгариф, 1927, № 12, б. 94–98; Сәгъди, Кызыл Татарстан, 1927, 2 февраль; Сәгъди, Мәгариф, 1928, № 2, б. 24–33], Г. Нигъмәтинең һәр әсәрен күзәтеп-анализлап барган әтрафлы язмалары [Нигъмәти, 1929, б. 80–99; Нигъмәти, Яңалиф, 1932, № 6/7, б. 104–113; № 8. б. 77–88], Ф. Сәйфи-Казанлының иҗтимагый фикергә караган хезмәтләренә бәяләмәләре шундыйлардан. Ләкин бу чорның идеологик каршылыклар, эзләнүләр чоры булуы әдип иҗатын бөтенлекле анализларга комачаулый.

Менә шушы нигездә М.Х. Хәсәнов язучының иҗтимагый-сәяси һәм фәнни-публицистик иҗатын тулысынча, комплекслы анализларга алына. Тарихилык принцибына таяну Ибраһимовның тормышын һәм мирасын хронологик яктан төзек барыш итеп күзалларга мөмкинлек бирә. Шушы шәхси тормышын галим милли яңарыш тарихы, иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-мәдәни барыш белән янәшә куя. Нәтиҗәдә бер шәхеснең мирасы халык тарихы сәхифәләренә урнаша. Мондый юл иҗтимагый-сәяси документларны, архив материалларын, әдәби әсәрләрне, фәнни-фәлсәфи, нәзари карашларны бергә тупларга мөмкинлек бирә. Әйтергә кирәк, бер шәхеснең тормыш юлын һәм иҗатын комплекслы өйрәнү татар әдәбият белемендә беренче тапкыр шундый киң колач һәм масштабларда башкарыла.

М.Х. Хәсәнов тарафыннан Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнүнең нигезе билгеләнә, моңа кадәр бу иҗатка мөнәсәбәтле күрсәтелгән шактый хаталар төзәтелә. Аерым алганда, язучы әдәби иҗатының романтик иҗат тибы булуы өзеп әйтелә, «Сөю-сәгадәт», «Диңгездә», «Йөз ел элек» кебек хикәяләре, «Яшь йөрәкләр» ро-

маны романтик әсәрләр буларак анализлана. Бер үк вакытта роман материалында язучы иҗатында башланган үзгәрешләр билгеләнә, 1920–30 еллар әдәби тәнкыйтендә әсәрне реалистик иҗат тибына «тартып кертү» омтылышы белән ясалган кайбер ялгышлар, әйтик, Г. Нигъмәтинең әсәр идеясен Сабир образы белән бәйләве [Хәсәнов... 1964. б. 40] төзәтелә. Позициянең аныклыгы Ибраһимовның 1917 елга кадәрге әсәрләренә генә түгел, 1920 еллардан соң иҗат ителгән «Кызыл чәчәкләр», «Алмачуар», «Казакъ кызы» кебек әсәрләргә юл табарга мөмкинлек бирә.

М.Х. Хәсәнов Г. Ибраһимов тормышы, эшчәнлеге белән бәйле бик күп мәсьәләләрне ачыклый һәм шәрехли. Әдипнең Тукай белән мөнәсәбәтләре, бәхәсле «Татар шагыйрьләре»нең язылу сәбәпләре шундыйлардан. Бер үк вакытта, аның концепциясендә чор идеологиясенә ияргән урыннар да юк түгел. Аеруча бу «Яңа кешеләр», «Адәмнәр», «Безнең көннәр», «Татар хатыны ниләр күрми» кебек әсәрләрне бәяләгәндә сизелә.

Г. Ибраһимовның эшчәнлеген тикшерү галимгә Академүзәк тарихын, аның татар мәдәниятен-фәнен үстерүдә тоткан ролен аңларга ярдәм итә. М.Х. Хәсәновның үзгәртеп кору ачкан мөмкинлектән файдаланып, 1991 елда Татарстан Фәннәр академиясен оештыруга алынуы, аның беренче президенты булып, 15 ел җитәкчелек итүе, Татар энциклопедиясе институтын оештыруы һәм башка күп кенә игелекле адымнары, күрәсең, күпмедер күләмдә яшь вакытта сайлаган фәнни темасына, Ибраһимовның «Татар академиясе»н оештыру тарихын өйрәнүенә барып тоташа торгандыр.

Г. Ибраһимов иҗат мирасы галимне XX йөз башы яңарышына катнашы булган бик күп шәхесләр, аларның фәнни, әдәби, публицистик, фикри мирасына алып килә. Галимнең Г. Камал, К. Тинчурин, Ф. Әмирхан һ.б. зыялыларның иҗатын халыкка кайтаруда өлеше зур. Г. Исхакый мирасын барлап язылган беренче кандидатлык диссертацияләренең җитәкчесе М.Х. Хәсәнов булу да аның бу чор буенча әзерлеге, мәгълүматлылыгы хакында сөйләп тора. Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнүдән галим XX йөз татар мәдәниятенең төп белгечләреннән берсенә әверелә.

Шулай итеп, М.Х. Хәсәновның фәнни эшчәнлеге мисалында без аерым шәхеснең тормыш һәм эшчәнлек биографиясенең галимне татар әдәбияты тарихына, милли иҗтимагый-сәяси фикер тарихына, тирән социомәдәни гомумиләштерүләргә алып килгәнлекне күрәбез. Фактологик һәм аналитик материалларга таянып тергезелгән бу фон галимгә, инде докторлык диссертациясен яклаганнан соң, Г. Ибраһимов шәхесен һәм иҗатын яңа биеклектән бәяләргә ярдәм итә. Мондый тикшеренүләр идеологик яки тарихи үзгәрешләргә бәйле түгел, алар бер заманда да актуальлеген җуймый. Мансур Хәсәновның татар әдәбият белемендәге олы урыны шуның белән билгеләнә дә.

**Әдәбият**

*Авыргазый.* Яңа әсәрләр. «Яшь йөрәкләр» // Йолдыз. 1913. 24 гыйнвар.

*Газиз Г.* Яшь әдәбиятыбызда – «Яшь йөрәкләр» // Аң. 1913. № 11. Б. 189–194 б.

Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых / авт.-сост. М.-Х. Ибрагимов. Казань: Татар. кн.и зд-во, 2012. 336 с.

*Җәләй.* Әдәби мөсахәбәләр. «Яшь йөрәкләр» // Вакыт. 1913. 23 февраль.

*Каримуллин А.Г., Каримуллин Ш.А.* Указатель авторефератов и диссертаций по татарской филологии по состоянию на 1998 год. Казань: Фикер, 2000. 156 с.

*Кәримов Ф.* «Яңа әсәр» мөнәсәбәте илә // Вакыт. 1911. 6 декабрь; Яңа әсәрне тәнкыйть. «Карак мулла» // Сибирия. 1912. 3 июнь.

Кызыл Татарстан. 1927. 2 февраль; *Сәгъди Г.* Галимҗан Ибраһимов иҗатында типлар эволюциясе // Мәгариф. 1928. № 2. Б. 24–33.

*Нигъмәти Г.* Галимҗан Ибраһимовның яңа әсәре // Революция елларында әдәбиятыбыз. М., 1929. Б. 80–99.

*Нигъмәти Г.* Г. Ибраһимов һәм аның иҗат юлы турында // Яңалиф. 1932. № 6/7. Б. 104–113; № 8. Б. 77–88 һ.б.

*Сәгъди Г.* Татар әдәбияты тарихы. Казан: Татар. дәүләт нәшр. басмасы, 1926. 300 б.

*Сәгъди Г.* Карт марксист, бөек әдип Галимҗан Ибраһимов һәм аңа юбилей хәзерлеге // Мәгариф. 1927. № 12. Б. 94–98.

*Сәгъди Г.* Татар пролетариат матур әдәбиятына 20 ел // Кызыл Татарстан. 1927. 2 февраль.

*Сәгъди Г.* Галимҗан Ибраһимов иҗатында типлар эволюциясе // Мәгариф. 1928. № 2. Б. 24–33.

*Сәгъди Г.* Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты («Татар әдәбияты тарихы»ның икенче бүлеге урынында). Казан: Татиздат, 1930. 200 б.

*Сәйфи Ф.* «Яшь йөрәкләр». (Тәнкыйть) // Хокук вә хәят. 1913. № 3. Б. 49–50.

*Тутый.* Яңа әсәрләр. «Татар хатыны ниләр күрми» // Йолдыз. 1910. 18 ноябрь;

*Хасанов М.* Галимджан Ибрагимов: крат. очерк жизни и творчестве. Казань: Татар. кн. изд-во, 1966. 26 с.

*Хасанов М.Х.* Галимджан Ибрагимов. Казань: Татар. кн. изд-во, 1969. 432 с.

*Хасанов М.Х.* Эволюция творчества Галимджана Ибрагимова в послеоктябрьский период: дис. ... д-ра филол..наук / ИВ АН СССР. М, 1971. 595 с.

*Хасанов М.* Галимжан Ибрагимов: монография. Казань: Таткнигоиздат, 1977. 432 с.

*Хасанов М.Х.* Писатель, ученый, революционер: страницы жизни и творчества Г. Ибрагимова. М.: Наука, 1987. 318 с.

*Хәсәнов М.Х.* Галимҗан Ибраһимов иҗаты: (Октябрьгә кадәрге чор): филол.фән. канд. ... дис. Казан, 1961. 343 б.

*Хәсәнов М.* Галимҗан Ибраһимов: тормыш һәм иҗат юлы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. 331 б.

*Хөсни.* «Яшь йөрәкләр» // Идел. 1913. 21 февраль.

Яңа әсәрне тәнкыйть. «Сөю-сәгадәт» // Сибирия. 1912. 17 июнь һ.б.

***Заһидуллина Дания Фатыйх кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Татарстан Фәннәр академиясенең баш гыйльми сәркатибе*
*zagik63@mail.ru*

*И.Р.Таһиров*

# МАНСУР ХӘСӘНОВ – КҮРЕНЕКЛЕ ГАЛИМ, КЫЮ ҺӘМ ТӘВӘККӘЛ ДӘҮЛӘТ ЭШЛЕКЛЕСЕ

Халкыбызның мәшһүр улы Мансур Хәсән улы Хәсәновның баскычтан баскычка күтәрелеп, берсе артыннан икенче үрләр яулый баруы минем һәм күп замандашларымның күз алдында булды дисәм, һич кенә дә хата булмастыр дип уйлыйм.

Аның белән танышуым 1958 елның сентяберенә туры килә. Бу минем Казан университетының тарих-филология факультетында укый башлаган вакытым. Факультетның деканы Шакир Мифтах улы Еналеев, ә аның урынбасары әле күптән түгел генә филология фәннәре кандидаты исеменә ия булган яшь галим Мансур Хәсәнов. Факультет тарих, рус филологиясе, татар филологиясе һәм рус-татар бүлекләреннән тора. Һәрбер курста 100 кеше укый, ә барлыгы – 500 студент. Декан күбрәк гомумҗитәкчелек һәм педагогик коллективны туплау эшләре белән мәшгуль. Ә барлык оештыру эшләрен Хәсәнов алып бара. Бу, әлбәттә, Шакир Мифтахович студент эшләре белән шөгыльләнми иде дигән сүз түгел. Ул кешеләргә, шул исәптән укучыларга карата да игътибарлы кеше иде. Ләкин аның шактый вакыты факультет составында булмаган КПСС кафедрасында үтә. Ул партия тарихы укытучысы буларак, башка факультетларда да эшли. Шунлыктан һич кенә дә җиңел булмаган оештыру эшләре Мансур Хәсәнов җилкәсендә иде. Ул һәрбер студентны танып белә, һәрберсенең ихтыяҗлары белән ныклап кызыксына. Группа эшләрен җайга салу, старосталар билгеләү, аларга төп юнәлеш биреп, вазифаларын аңлату, студентларны тулай торакка урнаштырып, аларның көндәлек яшәешләре белән кызыксынып тору – аның төп эшләренең берсе булды. Көзләрен студентларны бәрәңге алу кебек эшләрдә катнашу өчен колхозларга җибәрәләр иде. Бу эшләрне дә, төрле рәвештәге бәйрәмнәрне оештыруның башында да ул торды.

Факультетыбыз составы буенча катлаулы булса да, ул барлык күрсәткечләр буенча беренче урында барды. Безнең ике телдә чыга торган «Әдәби сүз» һәм «Ленинское знамя» стена газетабыз район буенча үткәрелә торган конкурста гел беренчелекне ала килде. Шушы газетада катнашу күпләрне язучылык юлына алып чыкты. Равил Фәйзуллин, Мөдәррис Әгъләм, Шамил Маннапов кебек күренекле әдипләр нәкъ менә шушы эштә катнашып чыныктылар. Үзешчән сәнгатьне оештыруда да безнең факультетка районда һәм шәһәрдә тиңнәр юк иде. Мансур Хәсәновның боларны оештыруда да өлеше зур булды. Кыскасы, аның көнне төнгә ялгап, армый-талмый хезмәт иткән еллары иде.

Мин баштарак тарих-филология факультетының беренче курсында укучы комсомолларның җитәкчесе, ә аннан соң комсомолның факультет бюросы секретаре итеп сайландым. Без аның белән шушы вакытлардан бирле бергә булдык. Ул эшләгән һәрбер эшенең төбенә төшә торган иде. Күп эшләрне ул минем белән дә киңәшләшеп башкарды. Студентларга карата гаять игътибарлы булды. Аны без барыбыз да ярата һәм ихтирам итә идек.

Аны югарыда бик тиз күреп алдылар. Һәм ул тиздән КПСС Өлкә комитетының лекторы итеп билгеләнде. Аның кебек ике телдә дә камил рәвештә лекцияләр укый алучылар бик сирәк иде ул елларда. Мансур Хәсәнович танылган лекторга әверелде. Лекторлык эшләрен оештыруга ул безне дә тарта иде. Без дә кайчагында аның белән, ә кайвакыт аннан башка да районнарда лекцияләр укый идек. Бу сәнгатьне үзләштерүебездә дә аның роле зур булды.

Тиз арада аны КПСС Өлкә комитетының фән һәм мәгариф эшләре бүлеге җитәкчесе итеп күтәрделәр. Бу вазифаны да ул чын күңелдән бирелеп башкарды. Аның кадрлар сайлый, аларны тиешле рәвештә эшкә тарта белүе безнең күз алдыбызда булды. Шушы вазифаларын башкарган вакытта да ул факультетны, университетны онытмады. Эшләребез белән һәрвакыт кызыксынып, безнең белән очрашкалап торды.

Мин бу очракта аның Казан культура институтын оештырудагы ролен ассызыклап үтәсем килә. Шушы уку йорты үзенең эшен, баштарак Ленинград культура институтының филиалы рәвешендә башлап җибәрде. Аңа бина, студентлар өчен торак булдырудан башлап, кадрлар туплауга кадәр эшләрнең барысы да, энәсенннән җебенә кадәр, аның җитәкчелегендә башкарылды. Мансур Хәсән улы шушы уку йортының директоры итеп инде шактый оештыру тәҗрибәсенә ия булган Солтанбеков Булат Фәйзерахман улын күзаллады. Ләкин Солтанбековның авырып китүе, Хәсәновның игътибарын Рәхилә Абдулла кызы Шәмсетдиновага юнәтергә мәҗбүр итте. Дөресен әйтергә кирәк, Рәхилә ханым аның ышанычын аклады. Үзен зур оештыру сәләтенә ия икәнлеген таныта алды.

Мансур Хәсәнов мине дә шушы уку йортына иҗтимагый фәннәр кафедрасы мөдире итеп чакырды. Ул минем фатирсыз икәнлегемне яхшы белә иде һәм бу эшкә күчсәм, проблеманы бик тиз хәл итеп булачагын да әйтте. Ләкин ул минем университеттан китәргә теләмәвемне дә яхшы белә иде. Шунлыктан, яхшылап уйларга тәкъдим итте. Мин хатыным Люция белән киңәшләшкәннән соң Хәсәновка, институтка бармаячагымны әйттем. Ул миңа һич кенә дә үпкәләмәде, ризасызлык белдермәде. Шулай да һәрвакыт, кайда гына эшләмәсен, мине күз алдында тотты.

Министрлар Советы председателенең беренче урынбасары булып эшли башлагач та, аның ишеге һәммәбезгә дә ачык булды. Без аның янына төрле рәвештәге киңәшләр, сорау-үтенечләр белән

керә идек. Аның яныннан кайчан да булса ризасызлык белән чыгып китүемне хәтерләмим.

80 нче һәм 90 нчы елларда мәгълүмат чараларының сыйфат үзгәреше, үтемлелеге үзеннән үзе генә барлыкка килмәде. Моның өчен республика җитәкчелегенә дә, шул исәптән Хәсәновка да күп тырышлык куярга туры килде. Аның тырышлыгы нәтиҗәсендә, «Вечерняя Казань» һәм «Шәһри Казан» газеталары барлыкка килде. Аларның һәм башка мәгълүмат чараларының эшен демократик һәм артканнан-арта барган хәбәрдарлык шартларына туры китерү журналистлар алдына яңа бурычлар куйды. Шуларны истә тотып, университетта баштарак журналистика бүлеге, ә аннан соң махсус факультет ачылды. Мансур Хәсәнович аларны кадрлар белән тәэмин итүгә дә зур өлеш кертте. Аның тәкъдиме белән факультетның деканы итеп талантлы журналист Флорид Әгъзамов билгеләнде, һәм бу һич кенә дә хата булмады. Шушы факультет кыска гына вакыт эчендә дистәләгән талантлы журналист кадрлар әзерли алды.

Мансур Хәсән улының үзенә дә шушы елларны зур сынаулар аша, утлы-сулы юллар аша үтәргә туры килде. Илдәге үзгәртеп кору заманы башлану республикадагы барлык гуманитар цикл өчен җаваплы кешегә янәдән-янә һич кенә дә җиңел булмаган вазифалар өсти торды.

Мәгълүмат чаралары һәм алар өчен иң җаваплы кеше булган Мансур Хәсәнов өчен иң зур сынау ГКЧП һәм республикабызның статусын күтәрү өчен референдум үткәргән көннәр булды. ГКЧП фетнәсе җәмгыятьнең бөтенлегенә, милләтара мөнәсәбәтләр өчен зур куркыныч тудырды – әллә СССР җитәкчелегенең иң җаваплы булган кешеләреннән торган фетнәчеләрне якларга, аларның әмерләренә буйсынып республикада гадәттән тыш чаралар игълан итәргә, әллә инде аларга каршы күтәрелгән Россия җитәкчелеге ягында булырга. Ике як та буйсынмаучыларга җитди чаралар белән яный.

Идел буе хәрби округы командиры генерал Альберт Макашев Казан гарнизоны начальнигына берсеннән-берсе куркыныч әмерләр җибәреп тора. Ул Казанда 150 кешедән торган спецназ командасы булдырырга боерык бирә. Шуның өстенә, Куйбышевтан янә 150 кешелек шундый ук команда җибәрәчәген хәбәр итә. Алар махсус әмер алу белән үк, танк һәм БТРлар ярдәмендә, барлык хөкүмәт учреждениеләрен, аэропорт, вокзалларны кулга төшерергә тиеш була. Гаскәргә бронетехника озатуында көненә берничә мәртәбә урамнарны әйләнә торырга әзер булу бурычы куела. Макашев тарафыннан шуңа охшаш башка чаралар күрү дә каралган була. Ләкин республика җитәкчелеге иминлекне, милләтара тынычлыкны саклауны төп бурыч итеп билгеләде, кемнәрнеңдер республикадагы тату тормышны бозуга юнәтелгән карарларына буйсынмады. Республика матбугат чаралары, Хәсәновның тырышлыгы аркасында, халкыбызга объектив мәгълүматлар биреп, экстремистик тайпылышларга каршы

тора алдылар. ГКЧП җиңелгәч, Татарстан җитәкчелегенә карата да җинаять эшләре ачарга тырыштылар. Хәсәновны да кайберәүләр матбугат чараларына цензура кертүдә гаепләп чыктылар. Ләкин безнекеләр сынмадылар да, егылмадылар да.

Референдум көннәре дә шулай ук шомлы булды. Республикабызга, аның җитәкчелегенә бертуктаусыз куркыныч яный торды. Россиянең Конституцион суды референдумны үткәртмәү турында карар чыгарды. Россия Югары Советы машиналары аңа каршы листовкалар таратып йөрде. Россия парламентында бу мәсьәлә махсус рәвештә тикшерелеп, бу хакта Татарстан Югары Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшинны тыңлау оештырылды. Конституция суды рәисе Валерий Зорькин чыгышында «әгәр дә референдумда куелган сорауга уңай җавап бирелсә, бу Татарстанның бәйсезлеген игълан итү өчен тулы нигез булачак. Һәрбер юрист моны шулай дип санаячак һәм хаклы да булачак, дип депутатларны һәм, гомумән, киң җәмәгатьчелекне куркытырга тырышты. Прокуратура сайлау участокларын ачуны тыеп әмер бирде. Россия президенты Борис Ельцин телевидение аркылы чыгыш ясап, рус гражданнарына, әгәр дә сез куелган сорауга уңай җавап бирсәгез, иртәгесен икенче сортлы гражданнар булачаксыз, диде.

Бу көннәрне Татарстан чикләрендә танклар гөрелдәп торды, республикага гаскәр кертү куркынычы туды. Россия Югары Советы рәисе Руслан Хасбулатов Мари республикасының Волжск шәһәренә килеп, референдум нәтиҗәләрен көтеп торды. Ул, әгәр дә референдум куелган сорауга тискәре җавап бирсә, Татарстан президенты Минтимер Шәймиевне Мәскәүгә алып китәргә тиеш булган.

Ләкин Татарстан сынатмады. Аның җитәкчеләре халкыбызга көч-куәт, дәрт-дәрман биреп тордылар. Мансур Хәсәнов җитәкчелегендәге массакүләм мәгълүмат чаралары сәгатьтәй төгәл эшләделәр. Ул бу көннәрдә күпчелек галим-голәмәләрне, укытучыларны халык белән эш алып баруга юнәтә алды.

Референдумның нәтиҗәсе һәркемгә мәгълүм. Тавыш бирүдә катнашучыларның 61,4 проценты куелган сорауга «әйе» дип җавап бирделәр. Бу көннәрдә эшләнгән эшләр, күрелгән чаралар турында күпләп сөйләп булыр иде. Ләкин мин, бу очракта, Мансур Хәсәновның шул көннәрдә эшчәнлегенең әһәмияте искиткеч зур икәнлеген генә ассызыклыйсым килде.

Гомумән, бу кеше турында, аның гыйльми уңышлары хакында күп язып булыр иде. Ул эше никадәр тыгыз һәм авыр булуына карамастан, беркайчан да фәннән читләшмәде. Татар әдәбияты тарихын иңләп-буйлап чыга алды. Гаепсездән репрессия корбаны булган классик язучыбыз Галимҗан Ибраһимовның иҗатын ныклап өйрәнде. Берничә китап һәм мәкаләләр язып, аның иҗатын халкыбызга кайтарып бирүгә зур өлеш кертте.

Галимнең иң зур эшләренең берсе – республиканың Фәннәр академиясен барлыкка китерү

булды. Бу аның күптәнге хыялы иде. Ул һәрвакыт Россиянең төрки дөньясында беренче урында торган татарларның үз Фәннәр академиясе булмавына уфтана иде. Һәм совет властенең беренче елларында ук, Галимҗан Ибраһимов тарафыннан төзелгән Академик Үзәк башлаган эшне ахырына кадәр җиткерү кирәклеген әйтә килде, акрынлап моның өчен тиешле чараларны күрә торды. Моны ул җайлап, Мәскәүдәге Россия Фәннәр академиясе белән килештереп, аның җитәкчеләре белән аңлашып эшләде.

Республиканың үзендәге фәнни институтларны, оешмаларны, югары уку йортларын, аларда эшләгән галимнәрне шушы эшкә ныклап тарта алды. Хәсәнов Академиянең төп нигезе рәвешендә Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтын билгеләде. Аның нигезендә ике махсус институт барлыкка килде һәм тагын берничә яңа фәнни институт оештырылды.

Бу очракта Энциклопедия институты турында махсус әйтеп үтмәсәм, дөрес булмастыр, чөнки аны оештыру да аның күптәнге хыялы иде. Билгеле ки, СССР заманында Фәннәр академиясенә, Энциклопедия институтларына фәкать союздаш республикалар гына ия булырга хаклы иде. Шунлыктан ул аны республикабызның сәяси статусын күтәрүгә таба әһәмиятле адымнарның берсе итеп санады. Бу эш тә аңардан зур кыюлык һәм тәвәкәллек таләп итте, аны оештыру эшләрен ул турыдан-туры үзе башкарды. Аңа кадрлар туплау, бинасын булдыру, эшләү юнәлешләрен җайлап җибәрү аның тырышлыгы аркасында булдырылды. Бу галимнең үзенә дә мәңгелек һәйкәл булып тора.

Шушы зур галим һәм дәүләт эшлеклесенең тормыш һәм хезмәт юлына багышланган фәнни конференциядә мин Энциклопедия институтына Мансур Хәсән улы Хәсәнов исемен бирү тәкъдиме белән чыктым. Ул конференциядә катнашучылар тарафыннан хупланды. Хөкүмәтебезнең шушы хуплауга кушылып, тиешле карар чыгаруына һичнинди шигем юк.

Бүген ул безнең арабызда булмаса да, аның милләтебез, республикабыз өчен кылган гамәлләре мәңгелек. Алар беркайчан да онытылмас, халкыбызның киләчәк буыннары да аңа рәхмәтле булып яшәрләр.

***Таһиров Индус Ризак улы,***
*тарих фәннәре докторы, профессор,*
*Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы*

*А.Ш. Зыятдинов*

## УЛ ЭШ КЕШЕСЕ ИДЕ

Мансур ага Хәсәнов белән мин озак еллар берьяклы гына таныш идем, ягъни, аны күреп таныйм, чыгышларын тыңлыйм, язганнарын укыйм һәм күңелемдә үзенә карата хөрмәт йөртәм, бу шәхес белән кызыксыну да арта бара. Ә ул мине белми. Очрашып танышу озак еллар насыйп булмады. Күрәсең, монда безнең туып-үскән яклар арасы ерак булу да – ул Кама аръягыннан, ә мин Казан артыннан – һәм яшь аермабызның зур булуы да үз ролен уйнагандыр. Аннан, Мансур абый гуманитар өлкә белгече, ә минем өлкә – техника, ул обком, кабмин вәкиле, ә мин – завод кешесе. Тормышымдагы рухи җитәкчем, гомерем буе җылы мөнәсәбәтләр саклап яшәгән кешем – бертуганым Бакый абый булды. Ул Мансур Хәсәновның яшьтәше иде һәм аның турында беренче мәгълүматларны да мин абыемнан алдым.

Бакый Зыятдинов районыбызның хөрмәтле педагогы, физик-математик, мәктәп директоры. Безнең як районнарының лекторы буларак Казанда партия өлкә комитеты яки Министрлар кабинеты оештырган төрле укуларда, семинарларда да булгалый. Шулар турында сөйләгәндә аның: «Хәсәнов та чыгыш ясады», – дип, аның чыгышларының бик төгәл, үтемле булуын ассызыклап әйтүе дә истә калган. Абыем тагын Хәсәновның репрессия еллары корбаннары буларак исемнәре халкыбыз хәтереннән җуела язган шәхесләребез мирасын ачыклап, үз чыгышларында аларның рухи дөньябызны баетуга керткән өлешләрен бәяли баруына хәйран кала иде.

Түбән Камада яши башлагач, язмыш мине университетта укыганда Мансур Хәсәновичның лекцияләрен тыңлаган, рухы белән чын педагог, шәһәребездәге педагогия көллияте директоры Рифкать Муллин белән очраштырды. Аның туган авылы Иштирәк Мансур Хәсәновның туган авылы Бигеш белән янәшә урнашкан. Мин Муллинның да Мансур ага турында җылы истәлекләрен еш ишеттем. Ул: «Мансур Хәсәнов Зәй төбәгенең Казандагы иң абруйлы кешесе», – дип әйтә иде.

Ә инде Мансур Хәсәнов шәхесенә карата иң әтрафлы бәяләмәләрне мин хөрмәтле аксакалыбыз – бөек рассамыбыз, сынлы сәнгатьтәге даһиебыз Бакый ага Урманче авызыннан ишеттем һәм аңлап куандым да: «Менә нинди эшлекле кешеләр бар икән безнең җитәкчелектә!» Һәм, табигый инде, күңелемдә бу бик тә үзенчәлекле шәхес белән танышу, аралашу теләге дә туды. Чөнки бу уйлар бөек Тукаебыз абруе, аның халкыбыз язмышында тоткан урынын лаеклы бәяләү һәм шул фикерне заман таләпләренә ярашлы итеп башкарып чыгу белән бәйләнгән иде.

Әйе, без бүген инде бөек шагыйребез хөрмәтенә корылган мәһабәт «Тукай-Кырлай»

комплексына һәм Казаныбызның Иске татар бистәсендә, затлы бинада урнашкан бай эчтәлекле Г. Тукай музеена ия халык. Димәк, без сөекле шагыйребезнең халкыбыз язмышында тоткан урынын да тиешле дәрәҗәдә бәяли беләбез һәм яшь буынны да шул рухта тәрбияләргә тырышабыз. Киләчәгебез өметле.

Ә бу комплексны салу һәм музейларны оештыру фикерен үз күңелендә йөрткән һәм җәмәгатьчелеккә җиткергән кеше – ул мөхтәрәм аксакалыбыз, Габдулла Тукайның замандашы, аннан 11 яшькә генә кече булган, үзен күреп белгән, иҗатына мөкиббән Бакый Идрис улы Урманче. Юк, идея авторы гына түгел, ә Кырлайдагы шундый зәвыклы музей бинасының һәм бай эчтәлекле комплексның архитекторы да. Шунысын да белеп торыйк: «Шамил йорты»н Тукай музеена бирдерү идеясе дә – Б. Урманченыкы.

Бу урында М. Хәсәновның «Сайланма хезмәтләр» исемле җыентыгындагы Б. Урманчега багышланган мәкаләсеннән өземтә китерү урынлы булыр. «Бакый Урманче гомере буена таланты белән дә, җаны белән дә, иҗатында да гел бөек Тукаебызга тартылды, идеяләре белән рухланды.

Аның Г.Тукайга бөек мәхәббәтен, шагыйрьнең тормышын һәм иҗатын камил белүен мин 70–80 елларда Арча районы Тукай-Кырлайда шагыйрьнең музей комплексын төзегәндә аеруча нык тойдым... Ул Г. Тукай музей-йортының архитекторы булды. Тукай-Кырлай комплексын төзүдә Татарстан хөкүмәтенә зур ярдәм күрсәтте» (321 бит).

Шушы урында Бакый Урманченың, бу игелекле хезмәтләренә кадәр нинди фаҗигале тормыш юлы узганлыгын искә алмасак, бу затлы шәхескә карата беркатлылык, җиңел караш булыр иде. 1927 елда, халкыбыз мең ел файдаланган алфавитыбызны алыштыруга риза булмыйча, 82 зыялыбыз имза куеп Сталинга җибәргән хатта аның да кулы була. Ул шулар арасыннан Соловки лагерларын да үтеп исән калган өч бөртек кешенең берсе. Юк, алай гына да түгел, аннан соң «минус 38» исемендәге күрсәтмә нигезендә СССРның 38 шәһәрендә яшәүдән мәхрүм ителеп, Казаныбызга 62 яшен узгач кына кайта алганы, сынмаганы, рухын саклаганы... Ягъни Сталин вафатыннан соң, сәяси туңнар бераз җеби башлап, кирәге чыккач кына кайта алганы.

Рухи дөньябыз өчен шундый көчле, әзерлекле шәхесне саклаганы өчен язмышка без рәхмәтле булыйк.

Үзем өчен иң куанычлысы: Бакый ага Урманче белән безнең элемтәләр ныгый барды, гаилә дуслары булдык. Очрашулар ешайды, аларның һәрберсе безне аңарчы билгеле булмаган шәхесләр, мәгълүматлар белән таныштыра иде. Шушы рухи яктан бик бай, тарихи шәхес белән Түбән Кама халкын да таныштыру ниятеннән, шәһәребездә мөхтәрәм аксакалыбызның 90 еллыгына багышланган «Җидегән чишмә» кичәсе дә уздырдык. Онытылмаслык кичә булды ул. Бакый ага үзе дә ул кичәне: «Сез миннән хан ясадыгыз», – дип, шаяртып искә ала иде. Без Бакый

ага Урманче белән Тукай-Кырлайга да сәяхәт кылдык. Әлбәттә, максатым – бу тарихи шәхеснең үзеннән комплекс турында мәгълүмат алу, чөнки безнең буын яшьтән үк Пушкин, Лермонтов, Толстой... музей-йортлары, усадьба-утарлары турында мәгълүматлы иде. Без аны шулай булырга тиеш кебегрәк кабул итәргә күнеккән, чөнки алар югары катлам, «ничек инде усадьба-утарсыз булсын...» Ә менә үз гомерендә йорты түгел, фатиры да булмаган Тукаебызны да шундый затлы «комплекслы» итү – нинди матур, көчле идея бит ул. Мине шул идеянең барлыкка килү һәм тормышка ашыру тарихы кызыксындыра иде.

Бакый ага, гади генә: «Иң мөһиме кемнең нинди йортта үсүе түгел бит, ә тудырган иҗаты, үзләреннән соң калдырган хезмәтләренең кыйммәтендә, аларның бүгенге тормышыбыз өчен дә актуаль булуында. Ә безнең Тукаебызның иҗаты иң зур хөрмәткә лаек. Шушы хакыйкатьне Татарстан җитәкчелегеннән иң беренче булып Мансур Хәсәнов аңлады. Без башка җитәкчеләрдә дә теләктәшлек таптык. Иң мөһиме – обкомның беренче секретаре Фикрәт Табиевтан хуплау алдык», – дип төшендерде.

Димәк, Бакый ага Урманче бу комплексның идея җитәкчесе – төп архитектор. Ә Мансур Хәсәнов – башкарып чыгуны оештыручы, төп җитәкче. Бу – 1978 елда төзелә башлап, 1979 елның 25 апрелендә ачылган комплекс, мөгаен, аларның икесе өчен дә хезмәт елларыннан халкыбызга калдырылган иң күркәм, истәлекле бүләк буларак та каралырга лаеклыдыр.

Әлеге комплекс турында сүз чыкканда Бакый аганың йөзе балкып китә иде. Ә урман хуҗалыгы хезмәткәрләренең ничек булышуларын, Арча районы җитәкчеләренең бу эшкә нинди җаваплылык белән карауларын һәм Казан арты – Арча районы балта осталарының ничек тырышып, булсынга эшләүләрен зур канәгатьлек хисе белән искә алулары әле дә хәтеремдә.

Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның 100 еллык юбилее халкыбыз һәм күпсанлы, мәртәбәле кунаклар өчен чын мәгънәсендә куанычлы, зур масштаблы бәйрәм булды. Аның да төп бизәге – Кырлайда махсус төзелгән өр-яңа музей-комплекс иде. Ул шагыйрьгә халкыбыз рәхмәте буларак кабул ителде. Ә инде бу гүзәл корылманы барлыкка китерү өчен зур күңел байлыкларын, тырышлыкларын куйган ике шәхес: Бакый Урманче һәм Мансур Хәсәнов бу тантананың иң абруйлы кунаклары буларак хөрмәтләнде. Мин бу сүзләрне аларның куанычтан балкыган йөзләрен күргән, шул тарихи тантананың шаһите буларак язам. Бу – булдыра алу шатлыгы иде.

Алгарак китеп булса да билгеләп узу кирәктер, бу ике шәхеснең үзара ихтирамлы мөнәсәбәтләре гомерлек булды. Еллар узып, инде Бакый Урманченың вафатыннан соң, аның бай мирасын саклау һәм республикабызның рухи тормышын баетуга куйган игелекле хезмәтләренә рәхмәтле булу йөзеннән бөек рәссамыбыз, даһи сынчыбызның музеен ачу,

шәһәребездә һәйкәлен кую буенча күркәм эшләре дә башкарылды. Әлбәттә, бу игелекле гамәлләр дә хөрмәтле Мансур Хәсәнов игътибарыннан, эшлекле теләктәшлегеннән башка эшләнмәде. Бу матур эшләрне оештыручыларга һәм башкарып чыгучыларга Бакый аганың җәмәгате Флора ханым, улы Айдар, туганнары һәм дуслары бик рәхмәтле булдылар.

Мансур Хәсәнов шәхес буларак күңелемдә гел үсә барды һәм аның белән аерым бер очрашу теләге дә көчәйде. Ә тормышыбызда зур үзгәрешләр чоры башланды, моңарчы күз алдына да китерә алмаган яңалык – «сүз иреге» – барлыкка килде. Халкыбызда милли рух баш калкытты, ул матбугатка үтте. Казанда да татар иҗтимагый үзәге оештыру буенча җыелып сөйләшүләр башланды. Ул хәрәкәт гел көчәйде һәм аның утырышлары Татар дәүләт академия театры бинасында, тулы залда уздырыла башлады. Күп таләпләр арасында иң мөһиме – республикага союздашлык статусы алу иде. Шул җыелышларда хөкүмәтебез вәкиле булып гел Мансур Хәсәнов катнаша һәм президиум өстәленең бер башында бик җитди кыяфәттә гел язып утыра һәм ахырында сүз алып бөтен куелган сорауларга җавап бирә, үз сүзен әйтә. Бик компетентлы булуы күпләрне сокландыра иде. Күңелемдә ул иң тәвәккәл хөкүмәт вәкиле булып калды. Мин боларны Татарстанда рәсми рәвештә беренче булып оешкан Түбән Кама Татар иҗтимагый үзәгенең рәисе һәм 1990–1995 елларда Татарстан Югары Советы халык депутаты буларак язам.

Менә шундый тынгысыз чорга туры килде Мансур ага Хәсәновның 60 еллык юбилее да. Шулай да мин якташлары исеменнән, Казанга килеп, кабинетында аны котлый алдым. Әңгәмә дә оешты. Б.Урманче белән Тукай-Кырлайга, Кышкарга, Мәчкәрәгә сәяхәт кылуыбыз, Карадуганда, абыем Бакый йортында кунак булуыбызны сөйләдем. Тукай-Кырлай комплексы өчен рәхмәтемне әйттем. Ә Б. Урманченың Түбән Камада «Җидегән чишмә» кичәсендә булуыннан инде ул хәбәрдар иде. Күрәсең, аңа бу турыда Аксакалыбыз үзе сөйләгәндер. Югыйсә, Мансур абый аптырабрак: «Азатҗан» син буласыңмыни инде ул?» – димәс иде. Чөнки мине бер Урманче гына шулай атады. Әңгәмәбезнең нәкъ шушы урынында миңа да Мансур Хәсән углын «Җидегән чишмә» кичәсенә чакырырга форсат туды һәм мин аңа «юбилеен туган авылы Бигештә дә, Түбән Камада да уздыру» – тәкъдиме ясадым. Мансур ага: «Сезнең ул чаралар рухи дөньябызда матур гына яңгыраш тапты, рәхмәт үзегезгә. Бәлки минекен дә булдыра алыр идегез, тик үтә дә тотрыксыз чор бит, кичереп торыйк» – диде. Кызганыч, тормыш гел катлаулана барды һәм без ул матур хыялны, Мансур Хәсәновны туган ягында да зурлау хыялын тормышка ашыра алмый калдык.

Ә шулай да безнең өчен шунысы куанычлы – илебездә башланган «үзгәртеп кору» сәясәте республикабыз үсешендә

дә яңа мөмкинлекләр тудырды. Шулар арасында Татарстан Фәннәр академиясен оештыру, мөгаен, аерым игътибарга лаеклыларның берседер. Киң эрудиция һәм зур оештыру сәләте таләп иткән бу эш Мансур Хәсәновка тапшырылды. Әлбәттә, бу очракта аның танылган галим, Казан университеты профессоры булуы да, башта өлкә комитетында, аннан соң Министрлар Кабинетында озак еллар Министрлар Кабинеты рәисенең урынбасары, беренче урынбасары буларак гел фән, мәгариф, мәдәният юнәлешләре эшчәнлеге өчен җаваплы хезмәттә булуы да исәпкә алынгандыр. Белгеч буларак та, оештыручы буларак та аның абруе төрле даирәләрдә һәрчак югары булды.

Республикабыз алдында торган үтә дә мөһим, катлаулы бу мәсьәләне дә Мансур Хәсәнов, үзенә хас җитдилек һәм җаваплылык белән лаеклы итеп башкарып чыкты. Сайлаулар үткәрелде һәм академик М. Хәсәнов, Татарстан Фәннәр академиясенең беренче президенты буларак, аның уңышлы эшләп китүен тәэмин итте. Рәхмәт үзенә.

Тормышымда булып узган, хезмәтем белән бәйле, үзем өчен байтак ук мөһим булып исемдә калган бер вакыйганы искә алмасам, бу истәлекләр язмасы тулы ук булмас иде. Юк, үземә карата түгел, бигрәк тә, Мансур аганың бик җаваплы шәхес булуына карата. Көннәрдән бер көнне Министрлар Кабинетында республикабызда урнашкан эре завод, берләшмәләрдәге фәнни берәмлекләрнең эш нәтиҗәләрен барлау чарасы булып узды. Минем хезмәт биографиямдә беренче тапкыр булды бу, җитмәсә, бу чарага безнең генераль директор үзе дә барды. Күрәсең, күрсәтмә шулай булгандыр, чөнки утырышлар залында үземә таныш башка генераль директорлар да байтак иде. Шулай ук ул залда Мансур Хәсәнов барлыгын да шәйләдем. Ә утырышны премьер-министр үзе, Рөстәм Миңнеханов алып барды. Башлап казанлылар «хисап тотты». Башлаучыларга кыенрак, бигрәк тә республикакүләм мондый киңәшмәләрдә катнашканың булмаса. Монда да башлаучыларга: «Безне технология түгел, ә ирешелгән нәтиҗәнең кыйммәте кызыксындыра», – кебегрәк кисәтүләр ишетелде. Шуның өчен мин үз чыгышымны кыскарттым: кайсы завод, ничә патент алынган, ничәсе гамәлгә кертелгән һәм ничә миллион экономия алынганны сөйли башладым, әйбәт кенә китте. Зал җанланды, җиденче завод яңалыкларын әйтеп узгач, Рөстәм Нургалиевич: «Наверное, достаточно, Азат абый, кайда эш барганын без аңладык, все бы так работали, мы давно были бы в передовиках, молодцы», – диде. Көтелмәгән мондый борылыштан аптырап калдым, чөнки мин тәнкыйть көткән идем. Генераль директорыбызның кәефе дә әйбәт. Тәнәфестә мине М. Хәсәнов янына чакырдылар. Ул чыгышымның отышлы булуын әйтте һәм озакка сузмыйча үзенә рәсми басылган фәнни хезмәтләремнең исемлеген китерергә кушты. Шулай эшләдем дә. Мансур Хәсәнович фәнни

хезмәтләрем белән җентекләп танышып чыкты. Аннан патентларымның күплеген, безнең фәнни үзәкнең шундый зур берләшмә уңышларында әһәмиятле роль уйнаганын һәм шул хакыйкатьне хөкүмәт җитәкчесенең дә югары бәһаләвен ассызыклап үтте. Аннан: «Мин бит сине, Азатҗан, иҗтимагый өлкә хезмәткәре итеп кенә күрә идем», – дип куйды. Академиягә сайлауларда катнашырга өндәде. Шунда ук академиянең баш гыйльми секретаре Илдус Бариевич Хәйбуллинны чакырды һәм бергә эшләргә кушты. Бу үтә ихлас күңелле, җаваплы кеше миңа бик булышты. 2001 елгы сайлауларда катнашып, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы булдым.

Мансур Хәсән углы Хәсәнов эш кешесе иде. Ул бөтен барлыгын: акылын, сәләтен, энергиясен тормышыбызны матуррак, камилрәк итүгә багышлады. Бу фикер аның 75 яшьлек юбилеенда, Татарстан Фәннәр академиясенең актлар залында, Казан федераль университетында һәм бигрәк тә озак еллар партия, хөкүмәт эшләрендә бергә эшләгән, аралашкан, үзара дустанә мөнәсәбәттә булган хезмәттәшләренең ихлас чыгышларында бик еш яңгырады. Юбилярга үзләренең җылы хисләрен, рәхмәтләрен белдерергә омтылучылар бихисап булды ул көнне. Тантанада төрле елларда М. Хәсәнов белән республикабызның беренче җитәкчеләре буларак эшләгән мөхтәрәм Ф. Табиев, Г. Усманов, М. Шәймиев иптәшләр дә катнашты. Һәр өчесе үзләрен бик гади, кечелекле тотып, юбилярга карата иң җылы хөрмәтләү сүзләрен җиткерделәр. Бу Мансур аганың республикабызны, иң әүвәл аның фәнен, мәгарифен, мәдәниятен үстерүгә куйган биниһая хезмәтен тану иде. Бу аның хезмәттә үткән тормыш юлын бәһаләүнең, мөгаен, кульминация ноктасы булгандыр. Тышкы хисләргә саран, үтә дә тыйнак булуына карамастан, юбилярның йөзендә әлеге бәһадән канәгатьлек шәйләнә иде. Академия бинасында узган юбилей мохите үзе үк сирәк очрый торган дустанә халәт иде... Бүген күңелгә ирексездән шундый уй килә: ә академия бинасының икенче катында, гөлләр арасында, зәвыклы постаментта Мансур Хәсәновның җыйнак кына бюсты торса һәм башкалабызның бер урамына аның исеме бирелсә, бик урынлы булыр иде. Рәхмәтле була белик!

***Зыятдинов Азат Шәймулла улы,***
*техник фәннәр докторы, профессор,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы*

***Ф.Г. Фәйзуллина***

# МАНСУР ХӘСӘНОВ. «САЙЛАНМА ХЕЗМӘТЛӘР»: яңа китапка күзәтү

Татар милләте узган катлаулы тарихи юлда милләтнең күренекле шәхесләре якты маяклар булып янып калалар. Һәр чорның нәтиҗәлелеген аның могътәбәр затлары билгели. Күпкырлы талант иясе Мансур Хәсән улы Хәсәнов, һичшиксез, әнә шундый шәхесләрнең берсе.

Әдәбият галиме, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе дию генә Мансур Хәсәнов эшчәнлегенең юнәлешләрен иңләми. Ул Татарстан хөкүмәтендә эшләгән елларда халык өчен истә калырлык вакыйгалар шактый була. Татар халык шагыйре Габдулла Тукайның 90 еллыгы хөрмәтенә Арча районының Тукай-Кырлай авылында мемориаль комплекс төзелү, Казан дәүләт мәдәният институты (хәзер мәдәният һәм сәнгать академиясе), Чаллыда педагогия институты, Волгоград физкультура институтының Казан филиалы ачылу, күп кенә тарихи шәхесләргә һәйкәлләр салыну (М. Вахитов, И. Шишкин һ.б.) – болар барысы да аның исеме белән бәйле. Хөкүмәттә үтә җаваплы вазифаны башкарса да, Мансур Хәсәнов фән өлкәсендәге актив эшчәнлеген туктатмый.

Мөхтәрәм галимнең юбилей көннәрендә дөнья күргән «Сайланма хезмәтләр» китабы моны тагын бер кат раслаучы дәлил булып тора. Биредә күренекле галим һәм язучы, ТР фәннәр академиясенең беренче президенты, ТРның атказанган фән эшлеклесе, профессор Мансур Хәсәновның төрле елларда фәнни җыентыкларда, газета-журнал битләрендә дөнья күргән фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләре туплап бирелгән. Хезмәтне кулга алу белән, беренче чиратта, аның төзүчесе Гөлназ Хөснетдинованың зур эш башкаруы күзгә ташлана. Төзүче тарафыннан галимнең, 1958–2005 еллар арасында язылып, төрле җирләрдә чәчелеп, таралып яткан мәкаләләре берәмтекләп җыелган.

Мансур Хәсәнов әдәбият белемендә иң абруйлы, иң зур белгечләрнең берсе. Аның фәнни эшчәнлеге төрле юнәлешләрдән гыйбарәт. Иң әүвәл ул – татар әдәбияты тарихын өйрәнүгә зур көч куйган галим. М. Хәсәнов 1937–1956 елларда исеме дә, әдәби мирасы да тыелган Г. Ибраһимовның исемен халыкка кайтару һәм аның иҗатына, фәнни хезмәтләренә, сәяси эшчәнлегенә объектив бәя булдыру юнәлешендә эзлекле тикшеренүләр алып бара. М. Хәсәновның Г. Ибраһимовка багышланган монографияләре, күп санлы мәкаләләре бар. «Сайланма хезмәтләр» җыентыгында төп игътибар әлеге темага бирелгән булуы да очраклы түгел. Аның беренче җитди гыйльми хезмәте 1964 елда басылган «Галимҗан Ибраһимов: тормыш һәм иҗат юлы». Әлеге шәхеснең мирасы укучыга кайтарыла башлаган чорда М. Хәсәнов олы язучының тормышын, беренче

чор иҗатын җентекләп тикшерә. Татар әдәбияты классигы, галим һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның әдәби мирасын фәнни өйрәнеп, анализлап, татар әдәбияты тарихында лаеклы урынын билгеләүгә зур тырышлык куя. Җыентыкка кергән «Г. Ибраһимовның билгесез ике әсәре турында» исемле мәкалә М. Хәсәновның әдип иҗатын җентекле өйрәнүе турында сөйли. Биредә мәкалә авторы әдипнең төрле псевдонимнар белән дөнья күргән әсәрләре турында сүз алып бара.

М. Хәсәновның Гыйльми үзәк эшчәнлеген яктырткан «Гыйльми үзәк һәм Галимҗан Ибраһимов» мәкаләсе дә игътибарга лаек. Әлеге язмада, Г. Ибраһимов тырышлыгына бәйле рәвештә, Гыйльми үзәкнең халык мәгарифен, мәдәниятне һәм матур әдәбиятны үстерү юнәлешендә гаять зур эшләр башкаруы ассызыклана.

М. Хәсәнов шулай ук татар халкының бөек шагыйре Г. Тукай иҗатын өйрәнүгә һәм пропагандалауга зур өлеш керткән галим. Үзенең «Тукай хакында сүз» мәкаләсендә ул Тукай иҗатына бәйле кайбер мәсьәләләргә туктала, шагыйрь мирасындагы һәм аның гражданлык йөзендәге сыйфатлар – гуманизм һәм хөрлек хисе, фәлсәфи оптимизм һәм халыкка тирән мәхәббәт, Ватанны сөю һәм интернационализм хисенең соклandыргыч булуына басым ясый.

М. Хәсәнов әдәбият тарихын өйрәнүне татар иҗтимагый һәм фәлсәфи фикер тарихын өйрәнү белән бергә бәйләп алып бара. Моңа мисал итеп XIX гасырның икенче яртысында һәм XX гасырның башларында иҗат иткән, яңарыш чорының нигез ташларын тәшкил итүче Шиһабетдин Мәрҗани, Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Риза Фәхретдин, Муса Бигиевләргә багышланган мәкаләләрне күрсәтергә кирәк.

Әдәбият галимен милли сәнгатьнең һәр тармагы кызыксындыра. Җыентыкта урын алган Галиәсгар Камал, Салих Сәйдәшев, Рәшит Ваһапов, Нәҗип Җиһановлар турындагы мәкаләләр шуны раслый.

Чын татар зыялысы буларак, М. Хәсәнов татар милләтенең үткәне белән кызыксына, бүгенгесе һәм киләчәге өчен борчыла. «Татарстан мөстәкыйльлек юлында: үткәннәрдән киләчәккә таба бару» (2000) мәкаләсендә ул бөтен кешене борчыган сорау куя: XXI гасырда Россия нинди булыр? Татарстан республикасы суверенитеты белән нәрсә булыр? Шунда ук җавап та бирә: Россия – күп нәрсәдә алдан фараз кылырлык ил түгел. Ләкин, минем карашымча, ул күп милләтле, күп динле һәм төрле мәдәниятле ил булыр. М. Хәсәнов Татарстанның суверен дәүләт буларак үсешен, дөнья күләмендә танылуын аның мәркәзе Казан шәһәренең хәзерге хәле, бай тарихы һәм киләчәге белән бәйли («Милли яңарышның көнүзәк мәсьәләләре», 2003) һәм шуңа кагылышлы ике проблеманы күрсәтә: беренчесе – башкаланың борынгы татар шәһәре буларак, милли рухын тергезү, икенчесе – Казанның бай тарихын җентекләп тикшерү, аның дөнья шәһәрләре

арасындагы кабатланмас урынын, Евразия цивилизациясенә керткән зур өлешен ачып бирү.

2000 елда ук М. Хәсәновның эшчәнлеген төрле яклап яктырткан «Татарның яңарышы: заман һәм шәхесләр» исемле истәлекләр һәм котлаулар җыентыгы дөнья күргән иде. Моңа кадәр әле, аның хезмәтләре, мәкаләләре җыйналып, аерым китап булып басылганы булмады. «Сайланма хезмәтләр» җыентыгы галим, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе Мансур Хәсән улының фәнни язмаларын туплаган беренче саллы китап. Бу юнәлештә уңышлы башланган эшнең киләчәктә дәвамы булыр дип ышанып калабыз.

Фоат Галимуллинның этрафлы итеп язылган кереш мәкаләсе Мансур Хәсән улының эшчәнлеген тулысы белән күзалларга ярдәм итә. Монда ул галим буларак та, дәүләт эшлеклесе буларак та, гомумән, олуг зат буларак күрсәтелә. Язмамны, Ф.Галимуллинның фикерен дәвам итеп, әлеге китап Мансур агага бер рухи һәйкәл булыр дип тәмамлыйсым килә.

***Фәйзуллина Фәния Галимулла кызы,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145-2

***Ф.Г. Галимуллин***

## ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТ ИҖАТЫНДА ТАТАР ХАЛКЫ ЯЗМЫШЫ

В статье поднимается вопрос отражения прошлого татарского народа в произведениях Т. Гиззата, описания сложных этапов в истории наших предков. Особое внимание уделено изучению двух драм автора «Наемщик» и «Фәрхиназ», посвященных теме «освобождения» крестьян в ходе реформ 1860 года.

**Ключевые слова:** Т. Гиззат, драма, крестьянская реформа 1860-х годов, судьба татарского народа, конфликт, характер.

Таҗи Гыйззәтнең, драматург буларак, татар әдәбиятына алып килгән яңалыклары турында сөйлибез икән, алар, әлбәттә, бар һәм сәхнә әдәбиятыбызны үстерүгә зур этәргеч бирделәр. Бу очракта без аларның берсенә – татар халкының үткәне, аның төрле чорлардагы язмышы әсәрләренең үзәгенә куеп яктыртуына гына игътибар итик. Драматург, чыннан да, халкыбызның катлаулы тарихи барышын шактый дәвамлы чорда, ягъни йөз елга якын вакыт эчендә булганнарын эзлекле сурәтләп барды. Ул моны 1860 нчы елларның шаулы вакыйгаларын бәян итүдән башлады, ягъни «Наемщик» (1925–1937) һәм «Фәрхиназ» («Ялкын») (1939) әсәрләрен иҗат итте. «Талир тәңкә» (1922) һәм «Чаткылар» (1934) әсәрләрендә татар авылының 1905–1907 еллардагы халык күтәрелешеннән соңгы хәлен тасвирласа, «Ташкыннар» (1937–1941) әсәрендә исә 1914–1917 еллардагы хәлләрне күз алдына китереп бастырды, «Бишбүләк»тә гражданнар сугышы чорының хәл-әхвәлләренә игътибар юнәлтте. Инкыйлабтан соңгы авыл тормышы «Ударник Мохтар»(1932), «Фамилиясез тимерче» (1933), «Мактаулы заман» (1935) әсәрләрендә, Бөек ватан сугышы чоры «Төнге сигнал» (1941), «Изге әманәт» (1945), «Чын мәхәббәт» (1946) әсәрләрендә гәүдәләнде. Гомере булса, бу юнәлештәге иҗаты алга таба да дәвам иткән булыр иде. Ул тарихи үткәнебезне шулай эзлекле сурәтләп барган язучыларыбыздан булды. Без бу очракта драматургның искә алынган әсәрләренең барысы турында да түгел, бәлки аның 1860 елларда крестьяннарга «ирек бирү» мәсьәләсенә багышланган ике әсәре «Наемщик» һәм «Фәрхиназ» («Ялкын») драмалары турында гына сүз алып барырбыз.

Патша Россиясе хөкүмәтенең бу акты турында сүз барганда, ул чордагы патша Александр Икенчене «азат итүче» дип бәяләләр. Моннан аның игелекле, миһербанлы шәхес булган икән, дигән тәэсир калырга мөмкин. Бу турыда артык сүз куертмыйча, шулай да бу патшаның монысы илдәге шул еллар вәзгыятен һәм аның, әгәр алга таба шулай барса,

нинди нәтиҗәләргә китерәсен төшенгән кеше булганлыгын әйтмичә ярамый. «Наемщик»та морзабикә Шәрифәнең «крестьяннарны азат итү безнең кебек дворяннарны бөтенләйгә юк итү дигән сүз бит ул» дигән сүзләренә каршы С.-Петербургта тау-инженерлык институтында укучы Зәкәрия биргән җаваптан бу ачык аңлашыла. Киресенчә, – ди ул, – алар (крестьяннар. – *Ф.Г.*) бу азатлыклары өчен безгә тагын да күбрәк файда китерәчәкләр. Без ул чагында натураль хуҗалыктан Европадагыча сәүдә, акча хуҗалыгына күчәрбез. Сез үзегез уйлап карагыз, алар хәзер безгә каршы үчегүнең чигенә килеп җиттеләр. Безгә Россиядә югарыгы сыйныф дворянство интересларын һәм чикләнмәгән монархияне саклап калу өчен крестьяннарны азат итүдән башка бернинди дә чара юк. Моны мин түгел, тормыш логикасы куша. Бу – Александр Николаевич хәзрәтләренең үз фикере. Әгәр дә без аларны азат итмәсәк, аларның үз-үзләрен азат итү куркынычы бар», – ди ул борчылып. Димәк, бу тормыш барышы көн тәртибенә куйган мәсьәлә иде. Т. Гыйззәт моны шулай күрсәтә дә. Чөнки инде крестьяннар патша күңеленә миһербанлык килүен көтеп утырмыйлар. Илнең төрле урыннарында азатлыкка омтылыш нияттән гамәли адымнарга күчә башлаган иде.

«Фәрхиназ» («Ялкын») драмасында Т. Гыйззәт XIX гасырның алтмышынчы елларындагы крестьяннар хәрәкәтендә татарларның катнашуын шактый киң планда тасвирлауны максат итә. Шуңа күрә әсәр дилогия рәвешендә булыр дип фараз кылына, ягъни «Фәрхиназ» әле алда булачак көрәшләрне колачлырак итеп күрсәтү өчен пролог бурычын гына башкара. Икенче кисәк инде «Ялкын» дип аталырга тиеш булгандыр дип уйларга нигез бар. Бу үзе үк драматургның халкыбыз кичергән тарихи вәзгыятьне сәхнә чаралары ярдәмендә укучыларга һәм тамашачыларга җиткерү максатының эзлекле булганлыгын күрсәтә.

Т. Гыйззәтнең сиксән ел элек булган тарихи вакыйгаларны җентекләп өйрәнгәнлеге сизелеп тора. Чыннан да, 1861 елның 19 февралендә игълан ителгән «Положение» нигезендә, крестьяннар рәсми рәвештә ирекле дип белдерелсәләр дә, аларның элеккеге хуҗаларыннан матди бәйлелеге үз көчендә калды, алай гына да түгел, ул көчәйде. Икътисадый бәйлелек кешене башка яклардан да ирексез итә.

Ул вакыттагы крестьяннар өч төрле иде: алпавыт крестьяннары, удел – император фамилиясендәге имениеләр крестьяннары, дәүләт крестьяннары. Т. Гыйззәт туып үскән төбәк (хәзерге Әгерҗе яклары) күбрәк шуларның беренчесенә карый иде, ягъни алпавыт крестьяннары. Шаршады, Тирсә һәм якынтирәдәге авылларның алпавыт Тәфкилевләргә караганлыгы билгеле. Реформаның гаделсезлегенә мөнәсәбәтле әлеге күтәрелештән, әлбәттә, бу һәм башка төбәк крестьяннары да читтә калмады, алар да гомуми агымга кушылды. Лаеш өязендәге Княжа, Кармачи, Юныс, Карташиха, Чемодурова,

Зөя өязендәге Тәмте, Кенәз Гагарин имениеләре булган 5 авыл, Спас өязендәге Йорткүл, Полянка, Изгар, Мораса, Чистай өязенең Дмитриевка, Андреевка авылларында бу хәрәкәт аеруча көчле булды. Әлеге өязләрдә алпавыт һәм крепостной крестьяннар аеруча күп иде (78,5 һәм 74%). Спас өязе Бездна авылындагы кузгалыш ил тарихына аеруча зур вакыйга булып кереп калды. Алпавыт Мусин-Пушкин имениесе крестьяны Антон Петровның (дөресендә – Сидоров) әлеге «Положение»нең асылын аңлатуы халыкның ачуын тагын да кабарта. Меңләгән крестьяннар үзләренә хак сүзне җиткергән А. Петровны берничә көннәр буе хакимият көчләренә бирми. Генерал-майор Апраксин 12 рота солдат белән килеп тә уңышка ирешә алмый. Шулай да, баш күтәрү бастырылып, 350 гә якын крестьян һәм шул исәптән А. Петров юк ителсә дә, халык бу күтәрелештән үзенең көчен күреп кала.

Т. Гыйззәт әлеге күтәрелешнең татарлар арасында да булганлыгын күрсәтүне максат итә. Моның өчен алпавыт крестьяннары авылын ала. Котлыкай мирза Алкин авыл крестьяннарының такыр басуын ревизия вакытында үз җире итеп рәсмиләштергән. Әмма моннан авыл кешеләре зыян күрмәгән, чөнки ул аларны бу җирдән файдалануны тыймаган. Ләкин өлкән Алкин үлгәч, варис булып калган малае бу хәлгә чик куярга, документ буенча үзләренә караган җирне үзе теләгәнчә файдаланырга карар биргән. Өяз суды да, шул рәсми кәгазьгә таянып, аны әлеге бәхәсле җирнең хуҗасы буларак таныган. Фәезхан кебек байлар куштаны өяз судында файда булмаса, губерна судына бирәбез, мин яхшы адвокат таптым, авыл халкы чыгымнар өчен акча бирсен, дип, бу хәлне үз файдасына бора. Әлбәттә, М. Галәүнең «Мөһаҗирләр» романындагы Әкрәм карый кебек, әлеге «адвокат» Фәезхан суд оешмаларындагы җыештыручылар һәм ишек төбе саклаучылар белән генә сөйләшә ала, ягъни аның бу алдап йөрүләреннән халыкка зыян гына. М. Галәүдән аермалы буларак, Т. Гыйззәт драмада, халык мәнфәгатьләрен ихлас яклау максатында, чын көрәшкә кушылып китүчеләрнең килеп чыгуын күрсәтүне дә бурыч итеп алган. Без бу әсәрнең финалында халык тарафыннан хупланган мондый ялкынлы күңелле кешеләр җитәкчелегендә алда зур көрәшләр булачагын сизеп калабыз. Әсәр менә шушы кайнар ноктага җиткәндә өзелеп кала – Каһәрман, Тимерша кебекләрнең сурәтләнгән мохиттә шушы зур миссияне үз җилкәләренә ала башлауга үсүләрен күрсәтү белән финалга килә.

Автор әсәрнең исемен «Фәрхиназ» дип кушса да, драманың «Ялкын» дип аталырга мөмкин булуы да искәртелә. Чыннан да, халык күңелендә рәсми хакимиятләргә мөнәсәбәттә ачу, нәфрәт күмере көйрәсә дә, билгеле бер киеренке сызыкка җиткәнче, ул әле ялкын теленә әверелми. Моның өчен хәл-әхвәлнең соң дәрәҗәгә җитеп тыгызлануы кирәк. Монда, социаль сәбәпләрдән тыш, Фәрхиназга бәйле рәвештә,

әхлакый-интим катламдагы каршылыкларның да әһәмияте зур. Дөресендә, алар да бу контекстта шул ук социаль-икътисадый мөнәсәбәтләр белән шартлана, ягъни Фәрхиназ сызыгы көйрәп торган киеренкелекнең ялкын китереп чыгаруын тәэмин итүче көч булып әверелә. Автор әсәрнең икенче кисәген дә язган булса, аның исемен, ихтимал, «Каһәрман» дип атаган булыр иде.

Каһәрман – гарәпләрдә һәм фарсыларда батыр, герой мәгънәсендәге сүз. М. Гафури әйткәнчә, «Чын каһәрман мондый чакта курыкмас вә артка атламас». Т. Гыйззәт сурәтләгән Каһәрман да нәкъ шундый кеше. Авылда им-томлык итүче ярлы хатын Маһитапның кече улы. Ул бәхет эзләп чыгып киткән. Әстерханда балык тотуда эшләгән, Малороссиядә шахталарда күмер чапкан, Одесса портында йөк төяүче-бушатучы булып та йөргән. Ике ел, йөкче-матрос буларак, сәүдә пароходында дөнья гизеп кинәнгән. Хәтта Көньяк Америкага барып җиткән. Андагы Сан-Сальвадор шәһәрендә негрларны кимсетүгә каршы чыгышларда катнашып, чит илләргә чыгу хокукыннан мәхрүм ителгән. Шулай йөри торгач, ниһаять, алты елдан соң гына авылына кайтып килә алган. Күрәсең, кайда гына эшләсә дә, матди яктан әллә ни уңышка ирешә алмаган. Кайтмый йөрүнең дә сәбәбе әнисенә әйткәннәрдән шулайрак аңлашыла: «Буш кул белән күренергә гарьләндем», – ди ул. Димәк, хезмәт хакыннан туганнарына бүләккүчтәнәч алырга да мөмкинлеге булмаган. Монысы барлык түбән катламнар өчен уртак хәл. Инде авылдагы, бу очракта татар авылындагы хәлләргә килсәк, монда исә хакимият тарафыннан күрсәтелгән тенденциоз сәясәт аеруча ачык чагыла. Реформаны Россия тарихында авыл халкы өчен ясалган гаять мөһим вакыйга дип карау гадәткә кергән. Моның бер дә әһәмияте булмаган дигән караштан без дә ерак торабыз. Бу Россия халыкларын коллыктан азат итүнең бер баскычы иде. Әйе, 1861 елга кадәр кешелек җәмгыяте үсешенең хурлыклы формасы булган коллыкның бу тереннән баш тартуыбызга әле нибары 154 ел. Бу патша Россиясендәге социаль хәлнең үзенә бер үзенчәлеген күрсәтә. Мондый хәлнең бездә шулай соңгы гасырларга кадәр сузылуы әледән-әле каршылык хәрәкәтен тудырып килде. Димәк, Россиядә 1917 елдагы хәлләрнең асыл сәбәбе – тарих төпкелендә шактый электән хәрәкәткә килү вакытын көтеп яткан көчләрнең туплануында икән. Т. Гыйззәт әлеге әсәрдә менә шуны күрсәтә. Антон Петров (Сидоров) өлешенә тигән миссияне башкаручылар Россиядәге башка халыкларда да булды. Аларга бу бурычны шул көннәрнең вәзгыяте үзе йөкләде. Куркытылган, өркетелгән, кысрыкланган татарлар арасында да ирек өчен кузгалышларда байрак ролен үтәгән шәхесләрнең булганлыгын инкарь итү мөмкин түгел. Югыйсә, алда искә алынган өязләрдәге халык күтәрелеше үзләреннән-үзләре генә барлыкка килә алмас иде. Әмма тарих бу каһарманнарны теркәп калдырмаган. Әйе, гомумән алганда,

халкыбыз бу хәрәкәттән бөтенләй үк читтә калмады. Ф. Бурнашның «Хөсәен мирза» драмасында да милләттәшләребезнең Муса, Бикмурзалар тәэсирендә күтәрелеп алулары тасвирланган иде. Ләкин бер авыл кысаларында гына баш күтәрүнең уңышка китерә алмаячагы бәхәссез. Мусалар тиңдәшсез көрәшнең корбаннары гына булалар. Т. Гыйззәт исә әлеге миссияне үз кулына алучы сыйфатында Каһәрман образын сурәтли. Дөнья күргән, русча укырга өйрәнгән бу егет әлеге «Положение»не туган телдә аңлатучы буларак кына чыгыш ясамый, ул үз өстенә вакыт тарафыннан йөкләнгән бурычның олылыгын аңлап эш итүче буларак гәүдәләнә. Шунысы мөһим, Муса да, Каһәрман да ялгыз түгел. Аларның Бикмурза, Тимерша кебек аңлы егетләргә таяну мөмкинлекләре бар. Тимерша белән Каһәрман диалогында без моны аеруча ачык күрәбез. Шактый еллар читтә булган Каһәрманны авыл хәлләре белән таныштырганда, Тимерша болай ди: «Крестьяннарны азат итәбез дигән булып, алпавыт хөкемен генә көчәйттеләр. Элек ирегең юк иде, азмы-күпме җирең бар иде. Хәзер ирегең бар, җирең юк».

Т. Гыйззәт «Фәрхиназ»(«Ялкын») әсәрендә менә шуларны сәнгать алымнары ярдәмендә сурәтләүгә алына һәм уңышлы гына хәл итә. Сүз дә юк, сәнгать әсәре сәяси көрәш күренешләрен сурәтләүне үзмаксат итеп куюны өнәми. Шуңа күрә автор Каһәрман образының көрәшкә җитәкчелекне үз кулына алырлык дәрәҗәдәге үсеш кичерүенә аның шәхси каршылыклар алдында калуын да табигый рәвештә китереп бәйли. Байлыгына таянып, авылда үзен бөтен нәрсәгә хуҗа итеп тоючы Мөстәкыйм тарафыннан, биш пот он бәрабәренә, өченче хатынлыкка сатып алынган Фәрхиназны коткару да җәмгыятьтәге шушы вәзгыятьтән башка һич тә мөмкин булмас иде. Димәк, драматург аерым кешеләрнең шәхси мәсьәләләрен хәл итүнең алшартлары сыйфатында илдәге, төбәктәге гомуми хәл-әхвәлләрне дә карый. Бу инде, әлбәттә, әсәрнең укучы һәм тамашачы тарафыннан кабул ителүен, анда үткәрелгән карашларның үтемлелеген көчәйтә. Каһәрман белән Фәрхиназның бергә булуы сәяси төсмер ала икән, бу һич тә «кызыллык» буларак кабул ителми. Дөрес, әсәрнең нигезендә социалистик реализм методы таләпләре ятуын инкарь итеп булмый. 1939 нчы ел шартларында башкача мөмкин дә түгел иде. Әмма драманың тулаем әһәмияте шунда – автор халкыбызның билгеле бер чордагы хәлен бернинди измсыз, ягъни дөреслеккә тугры калып сурәтли, әсәр кабат андый хәлләргә төшү хәтәреннән сакланырга кирәклегенә өндәү буларак кабул ителә. Чөнки андый күренеш бүгенге көндә дә юк түгел. Т. Гыйззәт иҗатының хәзерге чорыбыз өчен әһәмиятен менә шунда да күрергә мөмкин.

***Галимуллин Фоат Галимулла улы,***
*филология фәннәре докторы,*
*Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры*

УДК 821.512.145-2

***Ф.Х.Миңнуллина***

# Т. ГЫЙЗЗӘТ ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ ШӘХЕС ФАҖИГАСЕ

Статья посвящена изучению концепции трагического как формы образного мышления и ее отражения в драматургии Т. Гиззата. В ней показана трагедия человека, на долю которого выпали суровые жизненные испытания.

**Ключевые слова:** трагическое, трагедия, личность, пьеса, конфликт, драма

1917 елгы инкыйлабтан соң әдәбият үсешендә яңа чор башланып китеп, әлеге дәвердә иҗат иткән язучыларыбызның эшчәнлеге дә моның белән турыдан-туры бәйләнешле. Хәзерге карашлар югарылыгыннан бәя биргәндә, уңышларын да, кимчелекләрен дә күрсәтергә мөмкин. «...бу дәвер драматургларның бәхете шунда иде: алар профессиональ театр белән кулга-кул тотышып эшләде. Жанрларның тел-сурәтләү чаралары төрләнде, сәхнә телен халыкка якынайтуда яңа үрләр яуланды. «Татар совет театры» дигән кызыклы да, бай да, катлаулы да һәм кимчелекле дә күренеш барлыкка килүгә ярдәмләште... Идеология ягыннан хаталар һәм югалтулар күп булуга карамастан, совет әдәбияты сәнгатьлелек ягыннан, сәхнә кануннарын үзләштерү һәм искә алу җәһәтеннән игътибарга лаек» [Әхмәдуллин, 2002. б. 60], – дип бәяли бу чорны әдәбият галиме А. Әхмәдуллин. Иҗаты шундый катлаулы елларга туры килгән күренекле драматург Таҗи Гыйззәт тә татар драматургиясен үстерүгә үзенең талантын, тырышлыгын багышлаган каләм иясе. Драматург иҗатында якты киләчәккә өметләндергән көч, халык рухының үлемсезлеге алгы планга чыга. Аның әсәрләрендә шәхес һәм ил фаҗигасе җәмгыятьтәге тәртипләр аша ачыла. Ул үзенең әсәрләрендә революциягә кадәрге авыл халкы тормышының авырлыгын, фаҗигасен, азатлык, яңа тормыш өчен көрәшкә күтәрелүен яза. Катлаулы тарихи процессларның асылына үтеп керә, заманның иң мөһим мәсьәләләрен күтәреп чыга.

XX гасырда бер-бер-сен алыштырып кына торган инкыйлаблар, атага улын каршы куйган гражданнар сугышы, коллективлаштыру, Бөек Ватан сугышы кебек тарих тудырган фаҗигаләр Таҗи Гыйззәт әсәрләрендә, гомум халык язмышына мөнәсәбәтле киң планда гәүдәләнеш тапса да, аерым шәхес фаҗигасе буларак та ачыла. Чөнки шәхес – халыкның бер вәкиле, ил тарихын үз иңнәрендә күтәрүче. Гомумән, драматургның иҗат мирасын халкыбыз тарихында булып узган әһәмиятле вакыйгаларны гәүдәләндерүче елъязма буларак кабул итеп була. Шушы нигездә

Т. Гыйззәт драматургиясендә тарих-заман-шәхес проблемасын сыйнфыйлык, социалистик реализм терминнары, карашлары белән генә бәяләп бетерү мөмкин түгел. Аның иҗатында якты киләчәккә өметләндергән көч, халык рухының үлемсезлеге, халкыбызның гореф-гадәтләрен тулы чагылдыру үзәктә тора. «Кызыл карчыга», «Наемщик», «Ташкыннар», «Чаткылар», «Мактаулы заман», «Алсу таң» пьесаларында заман сулышы, әхлакый кыйммәтләр үзгәреше, татар кешесенең киң борылышлар чорындагы гыйбрәтле дә, шул ук вакытта фаҗигале дә язмышы чагылыш таба. Мәсәлән, 1923 елда сәхнәләштерелгән «Талир тәңкә» әсәрендә, заман рухына хас булганча, сыйнфый каршылыклар тасвирлана. Гади халык алпавыт утарларын талый, урманнарны кисә. Вакыйгалар бирелешендә Сабир бай, Столыпин реформасы ачкан мөмкинлекләрдән файдаланып, община җиренең иң яхшы өлешен үзенә ала. Рамай, Гаяз кебек геройлар үзләрендә җиңүгә ирешерлек көч булмавына карамастан, кыю рәвештә һәртөрле изүгә каршы көрәшкә чыгалар. Нәтиҗәдә, Гаяз кулга алына, Рамай Сабир бай тарафыннан үтерелә. Биредә фаҗигалелек геройның яшәп килгән тәртипләр белән килешә алмавыннан туа. Әлбәттә, протест пассив характерда. Социаль киртәләрнең билгеле бер моментта көчлерәк булуы геройның фаҗигасен тудыра. Шулай да биредә ирекка сусаган шәхеснең реаль тормыш белән ризасызлыгы ассызыклана. «Талир тәңкә»не яңартып язган «Чаткылар» драмасының финалында инде бунт күтәргән авыл халкының Сабир байны ялкын эченә атуы, халыкның оешкан төстә хәрәкәт итә башлавы күренә.

Т. Гыйззәтнең «Кызыл карчыга» әсәрендә шулай ук гомумкешелек кыйммәтләре, заман фаҗигасе бирелә. Бәян Гыйззәт билгеләгәнчә, пьесада яхшы тормышлы шәһәр кешесенең улы (Карчыга) үз теләге белән Кызыл Армия сафларына языла. Шул вакыт совет хөкүмәтенә каршы баш күтәрүләр оештырыла. Фетнә үзәге булып, Кызыл карчыганың туган йорты алына. Бәрелештә атасы ялгышлык белән улын атып үтерә [Гыйззәт, 1965, б. 36]. Бу вакыйга ата белән ул арасындагы туганлык мөнәсәбәтләренең өзелә баруы буларак кабул ителә. Шул рәвешле, зур ялгышлык аркасында герой язмышы фаҗига белән тәмамлана. Герой фаҗигасен тудыручы төп сәбәп – социаль җирлек, ил күләмендә барган трагик вакыйгалар белән бәйле.

Т. Гыйззәтнең «Наемщик» драмасында исә 1861 елгы халык бунты сурәтләнә. Автор Батырҗан, Гөлйөзем, Гәрәй, Булат образлары аша гади халыкның ирек, азатлык хакындагы уй-теләкләрен ачык чагылдыра. Әдип Шәрифә бикәнең халыкны ач-ялангач тотуына, Зөбәрҗәт исемле яшь кызны, сөйгәненнән аерып, әхлаксыз, явыз Иманкол муллага бирүенә, кызның суга ташланып, вакытсыз гомере өзелүенә, авыр тормышта көн итүләренә игътибарын юнәл-

тә. Герой үлеме заман тудырган шартлар нәтиҗәсе буларак бирелә. Драматургның «Җиде кыз» бәетенә нигезләнеп иҗат ителгән «Кыю кызлар» (1939) комедиясендәге төп конфликт исә, иске карашлы мәдрәсә ишаннары, азгын байлар, аларның булдыксыз ул-кызлары белән чая шәкертләр арасындагы каршылыкка корылган. Ир-малайларча киенгән Бибкәйнур, Миләүшә кебек ятим кызларның мәдрәсәгә килүе әлеге каршылыкка көч бирә, заманның көлке, шул ук вакытта аянычлы якларын ача. Әлеге күренешләргә бәйле рәвештә, комедиядә 1897 елгы ачлык вакыйгалары да телгә алына. Шундый фаҗигале шартларны автор әти-әниләре үлгән ятим кыз балаларны сату белән шөгыльләнгән Хаҗия образы, авыл карчыгы Сафура аша күрсәтә. Алга таба да язучы халык ризасызлыгын чагылдырган тарихи вакыйгаларны сурәтләвен дәвам итә. Халыкның әкренләп көрәш юлына килүе драматургның «Ташкыннар» драмасында да ачык гәүдәләнеш таба. Биктимер карт тормышның күләгәле, читен якларын күрмәскә тырышып йөрсә дә, геройның революцион көрәшкә якынлашуы тасвирлана. Империалистик сугышта һәлак булган улы Мирхәйдәрнең язмышы, кызы Гөлчирәнең бай малае Мирзахан тарафыннан мәсхәрәләнүе, улы Мирвәлинең патшага каршы көрәштә катнашуда гаепләнеп кулга алынуы аны шуңа этәрә. Биредә Т. Гыйззәт ике гаилә арасындагы конфликтка нигезләнеп, ил күләмендә барган социаль каршылыкларның бөтен катлаулылыгын аерым шәхес язмышы аркылы күрсәтә алган.

Драматургның «Җиңү бәйрәме» (1933), «Бөек борылыш», «Мактаулы заман», «Акбаш вакыйгасы» (1932), «Көрәш» (1935) пьесаларында колхозлашу еллары тудырган катлаулы, каршылыклы процесслар ачыла. Биредә фаҗига төшенчәсе яңа бер төсмер белән аерылып тора. Бу – күңел фаҗигасе, кеше күңелендәге каршылык, икеләнү, үз мәнфәгатьләреңә каршы килү, заман таләбенә ирексез буйсынудан туган фажига. Билгеле, бу бик тирәндә, психологик яссылыкта ята. Әмма язучы аны нечкә тоемлау аша җиткерә алган. Мондый рухта иҗат ителгән әсәрләрдә конфликт шулай бирелә ки, төп геройлар үз мәнфәгатьләрен халык файдасына корбан итә. Драматургның «Җиңү бәйрәме» пьесасындагы Хәйри белән Фәйрүзә, «Алсу таңда»гы Мортаза белән Халидәләр – шуның ачык мисалы.

Бу дәвердә язылган әсәрләрдә эчке дошманны эзләү мотивы аеруча ачык чагыла. Мәсәлән, «Акбаш вакыйгасы» Котбетдин исемле картның тискәрелегеннән көлеп язылган булса да, асылда ул совет елларындагы аяныч вакыйгалар, халык драмасы турында. Автор малын үзенеке итеп санаган кешенең яңа хөкүмәткә ят итеп каравын күрсәтә, кешенең иҗтимагый фаҗигагә юлыгып, тарихи агышны үзгәртә алмыйча җан газаплары кичерүен

ассызыклый. Әсәрнең нигезендә тарихи каршылыклар арасында калган ялгыз кеше язмышы ята. Автор тарафыннан комик персонаж буларак тәкъдим ителгән Котбетдин, асылда, драматик халәттәге, колхозлаштыру еллары фаҗигасен гәүдәләндергән шәхес буларак бәяләнә ала.

Йомгак итеп шуны әйтергә кирәк, Т. Гыйззәтнең «Чаткылар» (1934), «Ташкыннар» (1937), «Башмагым» (1941) кебек сәхнә әсәрләрен, татар халкының гасырларга сузылган азатлык көрәшен чагылдыру сәбәпле, читкә кагу мөмкин түгел. «Таймасовлар», «Изге аманәт», «Кыю кызлар» (1939), «Төнге сигнал» шул еллардагы фаҗигаләрне, гаделсезлекләрне тиешенчә ачып бетермәсә дә, аларда шәхси батырлык, патриотизм көче, гыйбрәтле язмышлар сурәтләнә. Драматург вакыйгаларны, геройларны үсештә бирергә омтыла, чорның фәлсәфи рухын чагылдыра. Ирекле тормыш өчен көрәш, шәхес һәм халык арасындагы мөнәсәбәтләр, җәмгыятьтә хатын-кызның роле, бердәмлек һәм таркаулык, кешенең рухи дөньясы, халыклар язмышы проблемасы пьесаларның үзәгенә куела.Т. Гыйззәт ил, халык язмышындагы вакыйгаларның һәркайсына игътибарын юнәлтә, ул заман белән бергә атлый. Яңа чор тудырган яңа шәхесләр аның әсәрләрендә үзәккә куелган. Кешелек тарихы тудырган вакыйгалар шәхес язмышына турыдантуры бәйле. Шәхес җәмгыятьтән бәйсез була алмаган кебек, тарихны да шәхесләр тудыра. Шул бәйләнеш Т. Гыйззәт әсәрләрендә бөтен тулылыгында гәүдәләнеш таба, шәхеснең эчке һәм тышкы каршылыклары аша бәян ителә. Милли характерны ачуда Т. Гыйззәт халыкның психологиясенә, аның гореф-гадәтләренә, традицияләренә, иҗтимагый идеалларына һәм башка милли үзенчәлекләренә мөрәҗәгать итә.

Т. Гыйззәтнең сыйнфый җәмгыятьне чагылдырган пьесаларында геройлар шул стройга каршы чыксалар, совет дәвере әсәрләрендә исә үзләре яшәгән стройны ныгыту, илне дошманнан саклау өчен көрәшәләр. Аларда яңа заман сулышы, әле генә мәйданга чыккан заман геройлары (яңа кешеләр) бар, мәдәни, әхлакый кыйммәтләр үзгәреше ярылып ята. Бер үк вакытта аларда гади халыкның зирәк акылы, кан коюны кабул итмәве дә сизелеп тора. Әхлак, намус-вөҗдан каршында җаваплылык, яшәү максаты, кеше күңелендә һәм чынбарлыкта барган мәңгелек көрәш гыйбрәтле язмышлар, тирән конфликтлы, драматик вакыйгалар аша яктыртыла. Сәясәт һәм гаилә каршылыгын, сәяси вакыйгаларның кеше күңелен тупасландыруын, вәхшиләндерүен, кеше язмышын җимерүен күрергә була. Бу очракта шәхес язмышы халык язмышы, гаилә, ил, Ватан язмышы белән тыгыз бәйләнештә яктыртыла. Шул рәвештә драматург үз заманы һәм кешеләре турындагы концепцияне үткәрә. Алар – үз-

гәреш заманы кешеләре. Заман үзе дә зур үзгәрешләр, тетрәнүләр, фаҗигаләр белән тулы. Шулай ук драматург туган илне, җирне ярату, халкыбызның гореф-гадәтләренә хөрмәт, хезмәтне олылау аша милли мохит тудыра. Тормыш дөреслеген әсәрләрдә чагылдыру һәм тарихи чынбарлыкка тугрылыклы булу – Т. Гыйззәт иҗатының төп билгеләренең берсе.

**Әдәбият**

*Әхмәдуллин А.* Таҗи Гыйззәт иҗатының татар драматургиясе тарихында тоткан урыны / Офыклар киңәйгәндә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 160 б.

*Бәян Гыйззәт.* Драматург Таҗи Гыйззәт. Казан: Таткнигоиздат, 1965. 96 б.

***Миңнуллина Фатыйма Хәлиулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*
*minnullina77@mail.ru*

УДК 821.512.145-2

*М.Г. Арсланов*

# ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТНЕҢ ИҖАТ ЭВОЛЮЦИЯСЕ

В статье анализируется эволюция творчества одного из самых ярких, самобытных татарских драматургов – Тази Гиззата, в течение 1930–1950-х гг. обеспечивавшего актуальным репертуаром национальное театральное искусство. Прослеживается история постановок его выдающихся произведений, таких как «Искра», «Потоки», «Бишбуляк», «Словная эпоха», «Священное поручение», «Настоящая любовь», в Театре имени Г. Камала.

**Ключевые слова:** Тази Гиззат, татарская драматургия, театр имени Г. Камала, Ш. Сарымсаков, К. Тинчурин, Х. Уразиков.

Мәдәният, сәнгать өлкәсендә халык тудырган бөек шәхесләрнең мирасын барлау, саклау, киләсе буыннарга мөмкин кадәр тулырак, бөтенрәк итеп тапшыра белү милләтнең үсеш дәрәҗәсен, зурлыгын билгеләүче төп сыйфатларның берсе. Татар әдәбияты классигы Таҗи Гыйззәтнең иҗат мирасын барлау, яңа тормыш шартларыннан чыгып яңача бәя бирү дә әнә шул юнәлештәге эшнең мөһим бер тармагы, халкыбызның мәдәни югарылыгын раслаучы гамәл. Таҗи Гыйззәт – пьесаларында татар халкының 100 елга якын тарихын, гореф-гадәтләрен, яшәү рәвешен, фикерләү үзенчәлекләрен, милли характерларны чагылдырган зур драматург. Әйтик, «Наемщик»та вакыйгалар 1861 елгы реформалар алдыннан барса, авторның соңгы әсәрләре ул үзе яшәгән илленче ел урталары турында сөйли. Шушы тулы бер гасырлык вакыт аралыгында Таҗи Гыйззәт халык тормышының ташкынлы елларын да, шомлы көннәр, даулы көннәр, данлы көннәрен дә, алай гына да түгел, якты киләчәк, алдагы бай, матур тормыш турында халык күңелендә сакланган мәңге сүнмәс өмет чаткыларын да, гади хезмәт кешесенең хыял-омтылышларын да табигый җирлектә, гаҗәеп тормышчан итеп сурәтли алган. Ул милләтебезне рухи яктан тәрбияләрлек мәктәп булырдай театр тудырган шәхес. Таҗи Гыйззәт театры бу төр сәнгатьнең бөтен тармакларына – режиссура сәнгатенә, актерлык осталыгына, хәтта сәхнә бизәү сәнгатенә (сценография) дә үсеш өчен материал биргән һәм бүгенге көндә дә бирә килгән күп сулы дәрьядай киң һәм тирән мирас ул.

Таҗи Гыйззәт иҗаты һәм татар театр сәнгате арасындагы мөнәсәбәтләрне шартлы рәвештә өч чорга бүлеп карарга мөмкин. Беренче чор: 1920–1934 еллар. Бу – Самара студиясендә укыганнан башлап, Татар дәүләт академия театрында «Чаткылар» әсәрен сәхнәгә куйдыруга кадәрге вакыт аралыгы – Таҗи Гыйззәт өчен уку-өйрәнү, үз иҗат юнәлешен, сәнгатьтәге урынын ачыклау еллары булып тора.

Икенче чор: 1934–1955 еллар. Бу чорда Таҗи Гыйззәт – иҗатта зур биеклекләр яулаган,

халык арасында киң танылган күренекле драматург. Шушы ук еллар аның иң актив эшләгән еллары да. Бүгенге көндә аның иҗат мирасының иң асыл энҗеләре саналган барлык әсәрләре дә диярлек әнә шул вакытта язылган.

Өченче чор Таҗи Гыйззәт вафатыннан алып, бүгенге көнгә кадәр вакыт аралыгын үз эченә ала. Биредә инде Таҗи Гыйззәт мирасының авторның үзеннән башка яшәү рәвеше тәгаенләнә. Билгеле булганча, һәр яңа чор драматургик материалга яңа таләпләр куя. Заман куйган таләпләргә тулысынча җавап биргәндә генә классик пьеса яңадан сәхнәгә күтәрелә ала. Хәзер инде спектакльдә вакыт, заман таләпләрен тормышка ашыручы буларак, театрның, режиссура сәнгатенең өлеше бермә-бер үсә. Сәхнәләштерүче режиссер сурәтләгән вакыйгаларны замана белән бәйләүче җепләр тапканда гына әсәр яңа чорда тулы канлы тормыш белән яшәргә мөмкин. Таҗи Гыйззәтнең иҗат мирасы әлеге теоретик уйлануларның дөреслеген тагын бер кат раслый. Бу чорда әсәр белән заман диалогында театр коллективының мөмкинлекләре, максаты хәлиткеч рольне уйный.

Инде яңадан Таҗи Гыйззәт иҗатының тәүге чорына, өйрәнчеклек чорына әйләнеп кайтыйк. Мәгълүм булганча, аның профессиональ сәнгатьтәге чишмә башы Самара студиясеннән, 1920 елның июнь аенда башланып китә. Бу чорда Октябрь инкыйлабына үсеп, профессиональ яктан тәмам өлгереп, ныгып килеп кергән татар театры эзләнү, географик яктан киңәю чоры кичерә. Шәһәрләрдә бик күп профессиональ һәм ярым профессиональ театрлар төзелә. Авыл, кантоннарда бихисап драма түгәрәкләре эшләп килә. Һәркайда театр эшен тиешле югарылыкта алып барырлык профессиональ әзерлеге булган кадрлар җитешми. Югары органнар тарафыннан Самара студиясе тормыш куйган әнә шул таләпне канәгатьләндерү өчен оештырыла да.

1920 ел татар режиссура сәнгатендә дә җитди үзгәрешләр елы. Бу елны «татар театрының атасы» Г. Кариев үзенең иҗат һәм тормыш юлын тәмамлый. Аның эш принципларын, режиссурада тормыш дөреслеге мәктәбе традицияләрен кабул итеп алган Кәрим Тинчурин бөтенләй яңа тип театр төзүне максат итеп куя. Аны шартлы рәвештә «тигезләр театры», «коллектив театр» яки «геройсыз, лидерсыз театр» дип атап булыр иде. Бу коллективта бөтен кеше дә бертигез хезмәт хакы ала. Актерлар, режиссерлар барысы да бертигез. Рольнең кечкенәсе, зурысы юк. Берәү бүген төп рольдә уйнаса, иртәгә шул ук актер халык сәхнәләрендә катнаша. Театрның һәр иҗади, административ яки техник проблемасы күмәкләшеп хәл ителә һ.б. Күренгәнчә, К. Тинчурин төзергә уйлаган театрның эш, яшәү принциплары шактый үзенчәлекле. Моны тормышка ашыру өчен иң элек бер иҗади манерада иҗат итә торган фикердәшләр тәрбияләү зарури. Әлеге зарурияттне тирәннән аңлаган режиссер, җиң сызганып, педагогика белән шөгыльләнә башлый. Самара студиясендә ул

рус телендә алып барыла торган «артистлык, режиссерлык эше һәм иҗаты» предметын татарчага тәрҗемә итә, практик дәресләр алып бара, театр тарихы буенча лекцияләр укый. Соңрак яңа театр принципларын К. Тинчурин студияне тәмамлаучылардан төзелгән 51 кешелек «Г. Кариевка хатирә» труппасында тормышка ашыра башлый.

Тик 1921 елда илдә башланган ачлык, Оренбург өлкәсендәге холера эпидемиясе труппаның эшен дәвам итәргә ирек бирми. Шул ук елның көзендә «Г. Кариевка хатирә» исемен алган коллектив, ныгып та өлгермичә, таралырга мәҗбүр була.

Таҗи Гыйззәт иҗатын, әнә шул Самара студиясендә белем алып, К. Тинчурин төзегән «Г. Кариевка хатирә» труппасында актер сыйфатында башлап җибәрә. Аның иҗади шәхес буларак формалашуында, әлбәттә, остазы К. Тинчуринның роле гаять зур. Ул булачак драматургны җитәкләп диярлек очсыз-кырыйсыз сәнгать дөньясына алып керә, иң авыр булган тәүге адымнарны ясарга ярдәм итә, яхшыны ямannан аера белергә өйрәтә, зәвык тәрбияли. «Тинчурин студиядә иң авторитетлы, иң зур кеше итеп санала иде, – дип яза Т. Гыйззәт 1936 елда К. Тинчуринга багышланган мәкаләсендә. – Өч айдан соң практик эшкә керешеп репетицияләр башлану белән, ул үзен укучыларга тагын да якынайта. Чөнки театр эшендә тәҗрибәсез, белемсез яшь көчләрдән артистлар хәзерләү бурычы бөтен килеше белән Тинчурин җилкәсендә иде. Шушы бурычны ул, бик күп авырлыкларга карамыйча, намуслы рәвештә үтәде. Алты ай эчендә тотнаклы яхшы артистлар хәзерләп чыгарды».

К. Тинчуринның иҗади йогынтысы Т. Гыйззәт 1922–1923 ел сезонында Кызыл Октябрь исемендәге театрда актер булып эшләгәндә дә, 1928 елдан Казанга кайтып, драматургия өлкәсендә актив эшли башлагач та, 1937 елга кадәр, ягъни К. Тинчурин репресссиягә эләккәнче дәвам итә.

Т. Гыйззәт иҗатының беренче чорында зур йогынтыга ия булган икенче бер зур шәхес – актер, режиссер Зәйни Солтанов. Ул Самара студиясендә дикция, декламация, бүгенге көн термины белән әйтсәк, сәхнә теле дәресләрен алып бара. Драматургия өлкәсендә «Бәхетсез гаилә» – дип аталган иң беренче тәҗрибәсен Т. Гыйззәт беренче булып аңа күрсәтә. Әле шактый чи булган бу пьесаны ошатмаса да, З. Солтанов яшь авторның күңелен сындырмаска тырыша, саклык белән генә үзенең теләкләрен әйтә, киңәшләрен бирә. Шәкерт белән остаз арасындагы мөнәсәбәтләр, киңәштабыш итү ТДАТ сәхнәсендә озак еллар бергә эшләү дәверендә дәвам иткән зур иҗади дуслыкка әверелә.

1928 елны яңадан Казанга кайткач, Т. Гыйззәт инде Ульяновск, Алабуга, Бондюг, Чаллы шәһәрләрендә уйналып, халыкта шактый кызыксыну уяткан «Наемщик» әсәрен Татар дәүләт академия театрына тәкъдим итә. Аны куярга алынган режиссер Сульва-Вәлиев белән әсәрне

тагын бер кат эшләп чыгарга туры килә. Куелган вариантта пьесаның социаль эчтәлеге тирәнәя, Шәрифә бикә, Әскар, Бикчәнтәй, Гөлйөзем, Зөбәрҗәт образлары кертелә, музыкаль номерлар өстәлә һәм мулла белән наемщик мөнәсәбәтләренә корылган җиңел комедия акрынлап тулы канлы музыкаль драмага әверелә. С. Сәйдәшев аңа өр-яңа музыка яза, ә ул вакытта «сул» театр йогынтысында эшләгән режиссер-новатор С. Вәлиев-Сульва спектакль өчен кабатланмас сурәтләү чаралары эзли. Күп очракта мавыгып читкәрәк китә торган киң фантазияле режисссер бу очракта эзләнүләрен тиешле кысага куя ала һәм, нәтиҗәдә, халык яратып карый торган, киң социаль яңгырашлы, тормышчан сәхнә әсәре туа.

Таҗи Гыйззәт белән С. Вәлиевның иҗат дуслыгы җимеше буларак, 30 нчы еллар ахырында Татар дәүләт академия сәхнәсендә «Бишбүләк», «Кыю кызлар» кебек уңышлы әсәрләр куела. С. Вәлиев-Сульва «Бишбүләк» пьесасын илленче еллар башында Республика күчмә театрына баш режиссер булып күчкәч тә сәхнәләштерә.

Күргәнебезчә, Т. Гыйззәт иҗатының тәүге чорында К. Тинчурин, З. Солтанов, С. Вәлиев кебек режиссерлар белән элемтәгә керә һәм алар драматургның иҗаты формалашуга шактый көчле тәэсир ясыйлар.

Т. Гыйззәт драматургиясен олы юлга чыгарырга булышучы тагын бер режиссер – 1934 елны Мәскәүдән ГИТИСны тәмамлап кайткан Гомәр Исмәгыйлов. Режиссурада МХАТ мәктәбен турыдан туры Станиславский шәкерте И.А. Судаковтан кабул иткән режиссер, Казанга кайту белән, Татар дәүләт академия театрында Станиславский системасын өйрәнү буенча дәресләр оештырып җибәрә һәм үз эшен шул нигездә алып бара башлый. Т. Гыйззәт драматургиясе белән ул Мәскәүгә киткәнче үк таныш була. 1930 елда куелган «Ил үскәндә» спектакле әле күптән түгел генә Казан театр техникумын тәмамлап чыккан Г. Исмәгыйловның иң тәүге эшләреннән санала. Ул вакытта гел яшьләрдән генә торган спектакль тамашачылар һәм театр тәнкыйте тарафыннан уңай бәяләнә. Г. Кутуй аның яшь көчләр катнашында куелуы һәм режиссерның үзе генә куйган беренче эше булуы белән әһәмиятле икәнен язып чыга.

«Чаткылар» (1935) һәм «Ташкыннар» (1937) спектакльләре Г. Исмәгыйловның татар театры сәхнәсендә куйган иң уңышлы эшләреннән санала. Революциягә кадәрге авыл крестьяннарының авыр тормышын, проблемаларын, Октябрь инкыйлабына килүен сурәтләгән бу пьесалар режиссер тарафыннан тормыш дөреслеге кануннарында сәхнәләштерелә. Әмма, алда аталган кайбер әсәрләрдән аермалы буларак, соңгы ике эш психологик драма кысаларына сыймыйча, халык тормышын төрле яклап чагылдыра торган киң иҗтимагый панорамага әйләнә. Авыл халкын төрле катлау тормышы яссылыгында ачу өчен Г. Исмәгыйлов, төп сәнгатьчә алым итеп, иҗтимагый каршы куюны

сайлый. Шуңа күрә дә автор, режиссер теләге белән спектакльләрдә ярлы, урта хәлле крестьян, бай сәүдәгәрләр яшәеше, тормыш фәлсәфәсе, фикерләү рәвеше, гадәтләре, көнкүреш детальләре аша төгәл, җентекләп анализлана. Социаль контрастны кискенләштерү тамашаларның һәр компонентында – образларның характерларында, сәхнә бизәлешендә, костюмнарда, хәтта музыкада чагылыш таба.

Беренче шау-шулы зур уңыш Т. Гыйззәткә Х. Уразиков куйган «Мактаулы заман» спектакленнән соң килә. Әсәр иң элек язучылар союзында укылып, уңай бәя ала. Тик ТДАТның сәнгать советы шактый икеләнеп кенә аны репертуарга кертә. Куяр вакыт җиткәч, штаттагы өч режиссер да (Г. Исмәгыйлов, Г. Ильясов, Г. Хавис) төрле сәбәпләр табып, пьесаны куюдан баш тарталар. Әсәрне сәхнәгә ул вакытта артист буларак шактый танылган, тик профессиональ режиссурада үзен әлегә күрсәтмәгән Х. Уразиков куярга алына. Ул пьесага артык зур теоретик анализ ясап тормыйча, артистлар белән күбрәк практик планда эш алып бара, образларның характерларын ачуга, сүзне тамашачыга җиткерүгә җитди игътибар бирә. Нәтиҗә пьесаны кабул итмәгәннәрне гаҗәпләндерерлек дәрәҗәдә була. Спектакль тамаша залында утыручыларның көчле алкышлары астында бара һәм чын-чынлап апофеоз белән тәмамлана. Спектакль республика күләмендәге зур мәдәни вакыйгага әйләнә. Аны карарга төрле районнардан аерым эшелоннар белән авыл хуҗалыгы эшчәннәре килә. «Мактаулы заман» барган көннәрдә театр гөрләп тора.

Татар режиссура сәнгатендә Ш. Сарымсаков Т. Гыйззәт пьесаларын иң күп сәхнәләштергән осталарның берсе. 1937 елда Г. Исмәгыйлов, «Ташкыннар»ның премьерасына кадәр, Казаннан китәргә мәҗбүр була. Генераль репетициягә хәтле җиткерелгән эшне Ш. Сарымсаков, Х. Уразиков һәм Х. Сәлимҗанов сәхнәгә чыгара.

1941 елда Мәскәүдә булачак Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына әзерлек көннәрендә Ш. Сарымсаков «Ташкыннар» драмасын яңадан куя. Яңа куелышта спектакльгә шактый гына үзгәрешләр кертелә: беренче пәрдәнең вакыйгалар урыны күчерелә, артык озын тоелган күренешләр кыскартыла. «Иске редакциядә спектакль йөздән артык уйналган иде, – ди Ш. Сарымсаков “Красная Татария” газетасы корреспонденты белән сөйләшкәндә. – Шуңа карамастан артистлар үзләренең уеннарына тәнкыйть белән карый алдылар һәм табышларның иң кыйммәтлесен генә декадада күрсәтү өчен сайладылар».

Шулай ук 1957 елда Мәскәүдә узган Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына да Ш. Сарымсаков Т. Гыйззәтнең «Даулы көннәрен» сәхнәләштерә. Өч кисәккә бүленгән «Ташкыннар» драмасының бу беренче кисәге була. Гадәттә, әсәрнең яңа вариантлы өстендә эшләгәндә, режиссер белән драматург кулга кул тотынышып эшлиләр. Ш. Сарымсаков үзенең теләкләрен,

фикерләрен авторга җиткерә һәм соңгысы, үз чиратында, озакка сузмыйча, драматик формада әйтелгәннәрне тормышка ашыра килә. Мондый үзара хезмәттәшлек Т. Гыйззәтнең «Таймасовлар» (1941), «Ялкын» (1943), «Изге амәнәт» (1946) кебек әсәрләрен сәхнәгә чыгарганда да дәвам итә.

«Чаткылар» драмасын исә Ш. Сарымсаков, Т. Гыйззәтнең вафатыннан соң, 1963 елда куя. 1956 елда сәхнәләштерелгән «Даулы көннәр» һәм 1960 елларның беренче яртысында тудырылган «Чаткылар» спектакле Т. Гыйззәт драматургиясенең татар режиссура сәнгате белән мөнәсәбәтләрендә өченче чорны ача. Безнең көннәргә кадәр дәвам иткән әлеге периодта Т. Гыйззәт пьесаларының тексты канунлаша, классика сыйфатларын кабул итә. Билгеле, драматургның иҗади мирасында һәрбер әсәр дә бердәй кыйммәтле түгел. Бик табигый булган әлеге үзенчәлекне искә алып, замана режиссерлары бу мирастан үзләренә кирәк булган материалны эзлиләр. Тапкан очракта бүгенге көн белән ныклы бәйләнеше булган яңа сәхнә сәнгате дөньяга килә.

Татарстан театрлары репертуарына күз салсак, Т. Гыйззәт вафатыннан соңгы чорда «Ташкыннар», «Чаткылар» һәм «Бишбүләк» драмаларының, «Кыю кызлар», «Наемщик», «Башмагым» кебек музыкалы әсәрләр күбрәк сәхнәләштерелүен күрербез. Күрәмсең, драматург иҗатының иң югары нокталарыннан саналган әлеге пьесалар бүгенге көндә дә үзләренең кыйммәтләрен саклап калалар. Соңгы чорда ТДАТта М. Сәлимҗанов, Әлмәт театрында Г. Юсупов кебек режиссура сәнгатебезнең осталары куйган спектакльләр театр тамашачыларын эстетик яктан тәрбияләүдә үзләреннән зур өлеш керттеләр.

Т. Гыйззәт драматургиясе – театр сәнгате алдына шактый авыр бурычлар куя торган киң агышлы, күп характерларны эченә алган, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне тирәннән ача торган, бай, катлаулы, иҗади мирас. Аның пьесаларын сәхнәгә чыгаручы режиссердан иҗади өлгергәнлек, тарихны, әдәбиятны, сәнгатьне халыкның этник үзенчәлекләрен, мәдәни аерымлыкларны – җыеп әйткәндә, татар милләтен эчтән белүе таләп ителә. Шуңа күрә дә аларны куярга теләсә кем алына алмый. Әйтелгәннәрдән чыгып, түбәндәге нәтиҗәне ясарга мөмкин. Т. Гыйззәт драматургиясе – татар театр сәнгатен төрле яклап баеткан, озак еллар дәвамында үсәр өчен җирлек булган, бүгенге көндә классика категориясенә күчеп, әле хәзер дә үзенең әһәмиятен саклаган, кыйммәтен җуймас хәзинә. Җәүһәрләр тутыкмый, талантлы драматургның үлемсез әсәрләре яңадан сәхнәләргә күтәрелер көннәр алда әле.

***Арсланов Мөхәммәтгали Гыйльмегали улы,***
*сәнгать фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге мөдире*

УДК 792:821.512.145-2

*Л.Г. Шакирҗан*

# Г. КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ РЕПЕРТУАРЫНДА ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТ ИҖАТЫ

Статья посвящена биографии, творчеству, а также этапным постановкам в Татарском государственном академическом театре им. Г. Камала произведений выдающегося деятеля татарского театра, драматурга, актера Таззи Гиззата. Анализируются наиболее успешные актерские работы Т. Гиззата, прослеживаются его творческие связи с видными деятелями национального постановочного искусства.

**Ключевые слова:** Таззи Гиззат, татарская драматургия, Татарский государственный академический театр им. Г. Камала, актерское искусство.

...Ялланып эшләүче, ашлык сугучы, урак уручы, сука сукалаучы, урман кисүче, завод эшчесе, суфлер, артист, драматург...

Бу – татар драматургиясен үстерүгә үз иҗаты белән җитди өлеш керткән олуг драматург, Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Таҗи Гыйззәт узган хезмәт юлы. Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш, Таҗи Гыйззәт, Нәкый Исәнбәт – «Татар сәхнәсен пьесалары белән тәэмин итеп торган төп фигуралар» дип тарихка кергәннәр. Бүген дә аларның исемнәре театрлар репертуарын бизи. Таҗи Гыйззәтнең җор телле комедияләре яшьләргә элекке тормышны бик җанлы итеп күз алдына китерергә, психологик драмалары исә тарихи вакыйгаларны тирәнрәк аңларга ярдәм итә.

Татарстаның Әгерҗе районындагы Барҗы Омга авылында алты балалы ярлы гаиләдә беренче бала булып туа ул. Әтисе Кәлимулла агай бик иртә вафат була. «Мәдрәсәдә җиде-сигез ел укып, соңгы елларда түбәнге сыйныф балаларына сабак бирүче мөгаллим ярдәмчесе булуга ирештем. Безнең мәдрәсәдә укытучы мөгаллимнәр барысы да рус культурасын танучы Буби мәдрәсәсеннән чыккан, заманына күрә алдынгы, ачык фикерле кешеләр иде», дип укытучыларын җылы сүзләр белән искә ала.

Ул табигатьтән талант белән яратылган зат. Булачак сәнгатькәр малай чактан шигырьләр укырга һәм аларны күчереп алып яттан сөйләргә яраткан. Авылда бәетләр язып, шуны авыл кешеләрен елатырлык итеп көйләп сөйләгәнТаҗи, тора-бара егетләр-кызлар өчен мәктүп, ягъни мәхәббәт хатлары – мәгъшукнамәләр язып та таныла. Ул язган хатлар берсеннән-берсе матур, тәмле сүзләр белән, төсле карандашлар белән ясалган, мәчет, тәсбих,комган рәсемнәре белән дә бизәлә һәм ул язган хатларга ихтыяҗ зур була. (Соңрак «Кыю кызлар» комедиясендә ул мондый хат язышу-алышуларны персонажларында куллана: әлхаттанисфел мөләкат, син җаныйга сагынып яздым сәлам

хат...) Шигырь язу белән яшьлек елларында мавыкса да, хуплаучы булмаганга, әкренләп бу шөгыльне ташлый. Пьесалар язуга керешә.

Туганнарына ата урынына калган Таҗи, мәгълүм булганча, унбиш-уналты яшеннән алда язылган авыр хезмәт юлын башлый.

Т. Гыйззәтнең театр дөньясына килеп керү тарихы көтмәгәндә һәм кызык була. «Мин ничек артист һәм драматург булдым» исемле автобиографиясендәге үз сүзләре белән әйтсәк: «Ижауда эшләп йөргәндә 1917 елның җәендә миңа бер иптәшем килә дә: “Без сине суфлер итеп чакырабыз”, – ди. “Нәрсә соң ул суфлер?” – дим. “Без театр куябыз, менә син шунда, тамашачыларга күренми генә безгә, китаптан карап, сүз әйтеп торырсың”, – ди. Мин бик куркып кына репетициягә киттем. Репетициядә мине бер читкә утырттылар да, китаптан карап әйтеп торырга куштылар. Укыйм, миңа беркем дә бер сүз әйтми, искәртү дә ясамый. Шулай итеп, мин суфлер булып киттем. Берничә спектакль уйнадык. Шул елның көзендә Галиәсгарь абыйның “Бүләк өчен” дигән комедиясен куярга җыенабыз. Көтмәгәндә генә, яучы карчыкны уйнаучы кызыбыз Казанга мөгаллимәләр курсына китеп бара. Эзлибез, кеше таба алмыйбыз. Шуннан, “менә, Таҗи уйнасын”, диләр. Мин, күп икеләнеп тормыйча, тавышымны нечкәртеп, карчык булып кыланырга керештем. Спектакльне караган кешеләр мине бик яраттылар, “әйбәт чыгарасың”, диделәр. Шулай итеп, суфлерлыкны ташлап, артист булып киттем».

Таҗи Гыйззәт сәхнә эшенә җитди бирелеп китә. Үзешчәннәрне туплап, спектакльләр һәм концертлар оештыра. Аннан аны 1920 елның маенда Самара шәһәрендә ачылган татар драма студиясенә укырга җибәрәләр. Мин татар артистлары арасында совет шартларында беренче булып, азмы-күпме булса да, театр мәктәбендә тәрбия алу шәрәфенә ирешкән артистларның берсе... Бу студия миңа артистлык һөнәренә генә түгел, бәлки гомуми белемнән азмы-күпме авыз итәргә, культура казанышларын үзләштерергә, рус, Европа театры, сәнгать, әдәбият үрнәкләре белән танышырга ярдәм итте. Башкаладагы азык кытлыгы аркасында, Мәскәү, Петроград шәһәрләреннән сәнгать, әдәбият, театр белгечләре, танылган профессор, академиклар Самарага күчеп килә, алар безгә биргән дәресләрдән күп белем, тәҗрибә алдык», – дип яза драматург. Биредә ул Кәрим Тинчурин белән дә якыннан таныша: «Кәрим ага – минем артистлык ягыннан гына түгел, драматурглык ягыннан да остазым. Мин башка драматургларга да аңардан өйрәнергә, аның яхшы якларын кулланырга киңәш бирер идем. Ул – тел остасы, образлы җөмләләр мастеры һәм театрны бик нык белә торган язучы». (Бу урында мин драматургның сүзләрен аның үз иҗатына карата үзгәртеп: «Яшь каләм тибрәтүчеләр, сәхнә әсәрләре язарга теләүчеләр! Таҗи Гыйззәт әсәрләрен кат-кат укып, драматургия законнарына, сюжет

төзү серләренә, вакыйгаларның кискен һәм эзлекле үсешенә, характерлар тудыру осталыгына Таҗи Гыйззәттән өйрәнегез», – дияр идем).

Таҗи Гыйззәт студияне шул ук елның декабрендә яхшы билгесе белән тәмамлап, артист таныклыгы алып чыга һәм шул көннән бирле, сәхнәдән аерылмый. Оренбург, Казан, Сембер, Мәскәү театрларында профессиональ артист булып эшли. 1929 елдан Академия театрында төпләнә. Сәхнәдәге эшчәнлегенә ул үзе болайрак бәя бирә: «Ике җаваплы фронтны берьюлы алып бару аркасында артистлык хезмәтемә тиешенчә җәелергә мөмкинлек бирелми. Бигрәк тә соңгы елларда азрак катнашырга туры килә. Чөнки вакытымның күп өлешен язучылык эшем аладыр. Икенчедән, театр дирекциясе дә мөмкин кадәр миңа эш шартлары тудырырга, сәхнә эшендә азрак файдаланырга тырыша. Сәхнә сәнгатен яратып-сөеп эшләсәм дә, үземдә булган табигый сәләтемне тиешлечә җәелдерә алганым юк әле.»

Таҗи Гыйззәт башкарган һәм үзе дә уңышлы дип санаган рольләреннән түбәндәгеләрне күрсәтергә була: рус классикасыннан: «Враги»да – Синцов, «Тормыш төбендә» – Клещ, «Варварлар»да – Доктор, «Ревизор»да – Почтмейстер»; дөнья классикасыннан: «Разбойниклар»да – Роллер, «Отелло»да – Монтано; татар драматургиясеннән: «Томан артында» – Кузнецов, «Галиябану»да – Хәлил, «Бәхетсез егет»тә – Закир, «Таулар»да – Соколов, «Козгыннар оясында» – Мулла, «Шәмсекамәр»дә – Сәләхи, «Чаткылар»да – Орлов, «Бишбүләк»тә – Әхтәм, «Кыю кызлар»да – Шәйхезаман, «Ялкын»да – Мостафа, «Мактаулы заман»да – Ярулла бабай, «Ташкыннар»да – Әхтәри, «Наемщик»та – Булат, «Башмагым»да Кәрим бай һ.б.

Драматургның үз әсәрләре куелганда, авыручы артистларны алыштыру өчен, авторның үзенчә әйтсәк, аны «резервта» тоталар: «...чөнки мин, – ди ул, – автор буларак, үз әсәрләремдәге образларны яхшы хис итәм. Мин, гомумән, язган әсәрләремне күңелдән беләм. Шуның өчен дә миңа үз әсәрләремдә төрле рольләрдә чыгып уйнарга туры килә».

Шулай бервакыт Т. Гыйззәт тиз генә кемнедер алыштыра. Сәхнәгә ялгыш алданрак чыга, әмма инде кире кереп китү дә дөрес түгел. Сәхнәдәге артист аптырап калмый, ә бәлки аптыраганнан: «ник килдең» дип сорый. Таҗи Гыйззәт «Болай гына. Хәл белеп чыгыйм дигән идем» ди. Тегесе: хәлләр әйбәт, син генә ашыгыбрак килгәнсең, ди. Таҗи Гыйззәт «шулайрак икән шул, ярар, соңрак кагылырмын әле», – дип чыгып китә.

Татар, рус, чит ил авторларының әсәрләрендә дистәләгән рольләр уйнап, төрле образлар тудырса да, Таҗи Гыйззәт татар театрында һәм милли әдәбиятыбызда үзенең әдәби иҗаты белән тарихи хөрмәтле урынын алды.

«Бервакытны театрда бер иптәшемнең (*баш суфлер булып эшләүче хатыны Мәликә турында сүз бара. – Л.Ш.*) бенефис көне җитә башлады. Безнең

һаман әсәребез юк. Нишләргә? Шуннан, тукта, мин әйтәм, үзем язып карыйм әле дим. Хатыным моны бик хуп күрде. Шулай итеп, мин язарга утырдым. Көннәр утырдым, төннәр утырдым, ашамадым, эчмәдем, фәкать шул пьеса белән яшәдем. Күпме вакыт язганмын, хәзер хәтерләмим, ләкин озак газап чикмәдем, “Талир тәңкә” исемендә бер әсәр туды», дип искә ала автор.

Бу аның драматургиядәге беренче ныклы адымы була. Соңыннан ул аны «Чаткылар» исемендә кабат эшкәртеп яза. Гомумән, Т. Гыйззәт үз әсәрләренә бик тәнкыйть белән, таләпчән карый. Күп тапкырлар үзгәртә, күчереп яза. Унар вариант язган очраклар да була. Кайбер әсәрләре кырыена «Хәзерге көндә әһәмияте юк», дип объектив бәя дә бирә белә. Башка авторларның әсәрләрен укыганда, һәрвакыт Т. Гыйззәт фикеренә колак салалар. Ә ул бер генә сүз белән бәяләргә ярата. Я – «әйбәт, тормышчан», яки – «начар, тормышчан түгел», ди.

Таҗи Гыйззәтнең әдәби мирасы – татар драматургиясенең зур байлыгы. Аның тарафыннан язылган 37 сәхнә әсәренең 30 дан артыгы үз вакытында татар театрларының репертуарыннан төшми; профессиональ генә түгел, үзешчән театр коллективларының да яратып уйнаган һәм тамашачы мәхәббәтен казанган спектакльләре була.

Фаҗигале Бөек Ватан сугышы елларында «Башмагым» музыкаль комедиясенең премьерасы шаулап уза. Бу әсәрнең язылу вакыйгасы турында Т. Гыйззәт: «Шәһәрдә күңелсез. Кичләрен урамнарда ут юк. Композитор Җәүдәт Фәйзи миңа килде: “Таҗи абый, болай булмый бит. Халыкның күңелен күтәрәсе иде. Миндә Хәбибулла Ибраһимовның “Башмагым” дигән бер пьесасы бар, шуны либретто итеп эшкәртеп бирсәң, мин музыка язар идем”, – ди. Мин тиз арада эшләп бирдем». «Башмагым»ны халык бик яратып кабул итә, сугыш елларында да, аннан соң да илебезнең бик күп сәхнәләрендә зур уңыш белән барган һәм әле дә куелучы милли классик опереттабыз ул.

Татар дәүләт академия театрында 1930–1950 нче елларда Т. Гыйззәт әсәрләре буенча режиссерлар С. Вәлиев-Сульва, Г. Исмәгыйлев, Ш. Сарымсаков, Г. Юсуповлар тарафыннан куелган спектакльләр ел аралаш диярлек сәхнәгә чыга тора. Драматургның вафатыннан соң килгән буын М. Сәлимҗанов, Ф. Бикчәнтәев, И. Хәйруллин сәхнәләштергән әсәрләр дә уңыш казанып, озын гомерле булдылар.

1927 «Талир тәнкә» –
1931 «Наемщик» – реж. С. Вәлиев-Сульва, рәс. П. Сперанский
1934 «Чаткылар» – реж. Г. Исмәгыйлев, рәс. П. Сперанский
1936 «Чаткылар» – реж.Г. Исмәгыйлев, рәс. П. Сперанский
1937 «Ташкыннар» – реж. Г. Исмәгыйлев, рәс. М. Абдуллин
1938 «Бишбүләк» – реж. С. Вәлиев-Сульва, рәс. М. Абдуллин
1940 «Кыю кызлар» – реж. С. Вәлиев-Сульва, рәс. М. Сутюшев

1941 «Таймасовлар» – реж. Ш. Сарымсаков, рәс. М. Сутюшев
1941 «Наемщик» – реж. К.Тумашева, рәс. М. Абдуллин
1943 «Ялкын» – реж. Ш. Сарымсаков, рәс. П. Сперанский
1944 «Чаткылар» – реж. Ш. Сарымсаков, рәс. П. Сперанский
1946 «Изге әманәт» – реж. Ш. Сарымсаков, рәс. П. Сперанский
1949 «Бишбүләк» – реж. Г.Йосыпов, рәс. М. Сутюшев
1949 «Ташкыннар» – реж. Ш. Сарымсаков, рәс. П. Сперанский
1950 «Давыллы көннәр» – реж. Ш. Сарымсаков, рәс. П. Сперанский
1951 «Шомлы көннәр» – реж. Ш. Сарымсаков, рәс. П. Сперанский
1953 «Данлы көннәр » – реж. Г.Юсупов, рәс. А. Тумашев
1956 «Ташкыннар» – реж. Ш. Сарымсаков, рәс. А. Тумашев
1964 «Чаткылар» – реж. Ш. Сарымсаков, рәс. А. Тумашев
1968 «Кыю кызлар» – реж. М.Сәлимҗанов, рәс. М. Сутюшев
1974 «Ташкыннар» – реж. М.Сәлимҗанов, рәс. А. Тумашев
1990 «Акбаш вакыйгасы» – Ф. Бикчәнтәев, рәс. А. Замилова
2005 «Кыю кызлар» – реж. И. Хәйруллин, рәс. Б. Ибраһимов

Т. Гыйззәт, шулай ук, уннан артык рус әсәрләренең тәрҗемәчесе, сәхнәгә һәм театр эшлекләренә багышланган күп мәкаләләр авторы да.

1967 елда Мәскәү гастрольләрен театр «Чаткылар» спектакле белән ача.

Башкаланың театр белгечләре спектакльне һәм әсәрне «глубоко национальный» дип бәялиләр. Һәм бу – башка спектакльләрдәге кебек, милли җыр-бию исәбенә түгел, ә гади авыл кешеләренең психологиясен-кичерешләрен, килеш-килбәтен, сөйләмнәрен дөрес, тормышчан чагылдырганга, дигән фикер белдерәләр.

«Ташкыннар»ның беренче куелышында (1937 елның 5 ноябре, реж. Г. Исмәгыйлев) автор бик еш репетицияләргә килә, профессиональ киңәшләре белән ярдәм итә, композитор Җ. Фәйзи белән даими элемтәдә тора. Хәтта, киемнәр цехына кереп, образларның ничек киенүләрен дә контрольдә тота. 1957 елда Мәскәүдә үткән татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында «Ташкыннар» спектакле дә күрсәтелә (реж. Ш. Сарымсаков). СССР Мәдәният министрлыгы үткәргән фикер алышуларда бер-берсеннән бик аерылып торган Биктимер карт һәм Хуҗа Насретдин рольләрен искиткеч оста башкарган Хәлил Әбҗәлилов уенына, аның талантына югары бәя бирелә. Нәкъ менә Т. Гыйззәт драмасы, ул язган тормышчан һәм катлаулы Биктимер карт образы уңыш китерә артистка. *(Револьвер тотып уйлану мизгеле, нинди эчтәлекле пауза!)* Автор һәм башкаручы да гади җир кешесенең – крестьянның тирән психологик кичерешләрен, илдәге тарихи үзгәрешләр белән бәйле рәвештә, бик табигый үсештә бирә беләләр. Нәтиҗәдә, Х. Әбҗәлилов татар театры тарихында беренче буларак «СССР-ның халык артисты» дигән зур мактаулы исемгә ирешә – милли театрыбыз да зур дәрәҗә казана.

Нәгыймә Таҗдарова иҗатына багышланган монографиядә дә «Ташкыннар» әсәре, дөресрәге,

артистка иҗат иткән образ – Биктимернең хатыны Гөлниса карчык телгә алына: «...Нәгыймә Таҗдарованың юка, ябык гәүдәсе авыр хәсрәтләрдән менә хәзер сынар кебек тоела, гүя бөтен картлык сызланулары аның гәүдәсенә таралгандыр төсле сизелә. Анның бу хәлен әйткән сүзләреннән, зарлануларыннан түгел (киресенчә, ул һич зарланмый, сыкранмый), бәлки озын гомерен нужада үткәргән, хәзер исә шундый авыр хәсрәтләр кичергән чын карчык булуыннан күрәсең. Шул ук вакытта әнә шундый физик какшаган тәндә никадәр рухи көч, өмет, җан җылылыгы күреп, аңа чын-чыннан сокланасың, йөрәк авыртуы белән аны кызганасың».

Мондый иҗат уңышлары турында драматургның барлык әсәрләрендә диярлек уйнаган Галия Булатовага карата да әйтергә мөмкин. (Режиссер Ш. Сарымсаков куйган спектакльләрдәге төп рольләр: Маһи – «Чаткылар», Фәрхиназ – «Ялкын», Мөршидә – «Ташкыннар» һ.б).

«Ташкыннар» әсәре Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында 1974 елда тагын куела һәм шулай ук уңыш казана. Бу урында тарихи документтан, рәсми беркетмәдән кайбер чыгышларны искә аласы килә.

**Выписка** (сокращенная) **из протокола коллегии Министерства культуры Татарской АССР**
от 29 сентября 1977 года.

О выдвижении на соискание Государственной премии СССР спектакля Татарского государственного академического театра им. Г. Камала «Потоки» («Ташкыннар»).

<u>Председатель коллегии, Министр культуры ТАССР И.Н. Алеев:</u>

Есть предложение выдвинуть на соискание Госпремии СССР спектакль театра им. Г. Камала «Потоки» («Ташкыннар») по пьесе классика татарской советской драматургии Тази Гиззата, а именно: режиссера-постановщика т. Салимжанова М.Х., художника-постановщика т. Тумашева А.И. и исполнителя главной роли, народного артиста СССР т. Биктимирова Ш.Х.

<u>Народная артистка ТАССР, заслуженная артистка РСФСР Р.А. Зиганшина:</u>

Написанная в 30-е годы, эта пьеса и по сей день является добротным материалом для театров. Спектакль – очень слаженный, хороший как по режиссерской трактовке, так и по актерскому исполнению. Салимжанов как режиссер в этом спектакле раскрылся еще больше. Игра Биктимирова изумительна. Оформление спектакля на высоком профессиональном уровне. Я, думаю, что спектакль уже вошел в сокровищницу татарского советского театралъного искусства. Гастроли театра в Баку и Астрахани показали, что «Потоки» пользуются огромным успехом и за пределами Татарии.

<u>Директор Казанского театрального училища А.Л. Шапиро:</u>

Мы, знаем и прежние постановки этой пьесы. В отличие от них в постановке Салимжанова – спектакль современный, лаконичный, но яркий. Динамика событий захватывает. Я считаю, что этот спектакль коллективом театра очень достойно посвящен 60-летию Великого Октября. Особо хочется сказать о Шаукате Биктимирове, который блестяще исполнил свою роль, став подлинным центром, вокруг которого сплотился весь спектакль.

Заместитель министра культуры ТАССР Р.М. Харисов:

Да, «Потоки», несомненно, один из лучших произведений татарской советской драматургии и совершенно естественно, что и спектакль получился достойным этого произведения. По своей масштабности, по глубине трудно найти равные «Потокам» спектакли в татарском театральном искусстве. Этот спектакль, на мой взгляд, большой вклад вообще в театральное искусство нашей страны. Работа Салимжанова, Тумашева и Биктимирова поистине значительное творческое достижение. В течение двух часов мы видим как приверженец царской власти постепенно, логично, убедительно превращается в борца против царского самодержавия. В этой работемы видим как воедино слились великолепные возможности и талант режиссера, актера и художника.

М.Х. Делешова:

Тази Гиззат – масштабный драматург татарского народа. Солидный, яркий драматургический материал дал возможность и т. Салимжанову, и коллективу театра создать высокоидейный, высокохудожественный спектакль. Оформление создает тревожную обстановку, которая так нужна для восприятия всего спектакля.

Ләкин ни өчендер спектакльгә премия бирелми, бәлки Ш. Биктимировның шул елны «СССРның халык артисты» дигән исем алуы сәбәпледер.

1974 елда Казан театр училищесының диплом спектакле дә (М. Сәлимҗанов курсы) «Ташкыннар» иде. М. Сәлимҗанов бу әсәргә мөрәҗәгать итүенең сәбәбен сорагач: «Эта пьеса хорошо сцементирована драматургически и богата различными яркими характерами» дип җавап бирә. Әйе, бу камил драматургия әсәре яшьләрнең табигый талантларын һәм инде туплаган осталыкларын ачарга ярдәм итә. Ул чакта матбугат битләрендә шагыйрь Харрас Әюпов «Талантлы яшьләр ташкыны» килде дип язып чыкты. Җырлы Гайнавал ролен элек актриса Мәрьям Сульва бик тормышчан башкарган дип сөйлиләр иде. Гайнавалны уйнаган яшь артистка Зөлфирә Зарипова турында да табигыйлеге, ихласлыгы белән, җыры белән М. Сульваны хәтерләтте диюче өлкән артистлар булды.

Җырлы спектакльләр, композитор Салих Сәйдәшев белән бергә иҗат иткән «Бишбүләк», «Наемщик» һ.б. музыкаль драмалар милли опера театры барлыкка килүгә, аны үстерүгә җирлек, мәктәп булып торуы да бәхәссез.

«Кыю кызлар»да шәкертләр киеменә киенеп белем алырга омтылган кызлар Бибкәйнур, Гайшә, Миләүшәне (ягъни яшь кызлар һәм үсмер малайлар булып та) Наилә Гәрәева, Наилә Ибраһимова, Мәсгудә Хәйруллина, Фирдәвес Әхтәмова искиткеч талантлы уйнаганнар иде (1968 ел, М. Сәлимҗанов куелышы).

2005 елдагы куелышта Ләйсән Фәйзуллина, Миләүшә Шәйхетдинова, Гүзәл Шакированы телгә алу кирәк. Алар да зирәк, чая, чын «кыю кызлар» булды. 1968 елда үзенең мул талантын юморга төреп Гыйлемдарны уйнаган Наил Әюпов һаман күз алдында торса, үзенең комик сәләтен оста ачып, көлке алымнары белән 10 ел тамашачыны

кинәндергән Искәндәр Хәйруллин да тарихта калачак. Сәхнә йолдызлары Фатыйма Ильская, Гәүһәр Камалова уйнаган рольләрне – Тутакай, Хаҗияне Фирая Әкбәрова, Зөлфирә Зарипова да шундый ук колорит белән сәнгатьчә югарылыкта гәүдәләндерделәр. Спектакльне сәхнәләштергән Илдар Хәйруллин – 1968 елгы куелышта әле үзе дә катнашкан булгангадыр – әсәрне элекке аһәңнәрне, традицияләрне дәвам итеп, шул ук музыкаль бизәлеш белән тамашачы хозурына тапшырды. Спектакль быел репертуардан төште, гәрчә һәрчак тулы залда уңыш белән барды.

Әнә шулай 20 нче еллар ахырыннан башлап бүгенгә кадәр театрның төрле буын артистлары Т. Гыйззәт пьесаларындагы төрле характерларны уйнап, иҗат мөмкинлекләрен кулланалар, чарлыйлар. Театр белгече Баян Гыйззәт сүзләре белән әйтсәк, «Т. Гыйззәт әсәрләре – артистлар иҗатына азык, осталыкка сынау ул». Һәм ул шулай дәвам итәр. Таҗи аганың: «Чабаталы Биктимерем яшәсә, мин дә яшәрмен» дигән образлы җөмләсенә, «Мактаулы заман»нарыбызда «Ташкыннар» булып килеп кергән Т. Гыйззәт иҗаты «Изге амәнәт» булып һаман яшәр. Сәрвәр, Гайнавал, Гөлйөзем, Батырҗан арияләрендә яшәр, димәк, тамашачыбыз, халкыбыз күңелендә яшәр, дигән өметтә калабыз.

***Шакирҗанова Луара Галимҗан кызы,***
*Татарстанның халык артисты,*
*Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе,*
*Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры музее мөдире*

УДК 792:821.512.145-2

***И.З. Хәйруллин***

# ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТ ИҖАТЫ ҺӘМ ПЕРИФЕРИЯ ТЕАТРЛАРЫ

В статье говорится о проблемах постановок пьес Тази Гиззата, о том, почему в театрах республики они ставятся сравнительно редко. Может быть, дело в их качестве? А может в недостаточно внимательном отношении к ним режиссеров-постановщиков?

**Ключевые слова:** Таззи Гиззат, репертуар, периферийные театры, фестивальные спектакли.

Таҗи Гыйззәтнең бөтен иҗаты татар театры белән өзлексез бәйләнештә булганга күрә, театрларыбызның бүгенге хәлләренә дә күз саласы килә. Бигрәк тә республикада эшләүче периферия театрларының эшчәнлеге турында әйтәсе килгән фикерләр күп. Чөнки соңгы елларда мине бу өлкәдә борчый торган сораулар арткannan-арта бара.

Тарихка күз салсак, периферия театрларының дөньяга килү максаты – авыл халкына театр сәнгате аша язучыларыбызның әсәрләрен җиткерү. Дистә еллар буе ул шулай булды да. Яшь авторларның әсәрләре дә, танылган драматургларыбызның мәшһүр пьесалары да татар халкына, һәрбер авыл сәхнәсенә нәкъ шул периферия театрлары аша барып иреште.

Бүген исә бу күренеш аномалия сурәтендә чагыла. Әйтик, безнең периферия театрларының кайсылары, төрле фестивальләрдә катнашабыз дип, башка Европа милләтләре авторларының әсәрләрен татар телендә уйнап, бөтен катнашучыларга да бирелә торган дипломнар алып кайтып: «Без татар сәнгатен тагын бер баскычка күтәрдек!» – дип горурланып йөриләр.

Фестивальдә катнашу әйбәт әйбер. Ләкин ул фестивальдә үзебезнең татар авторларының әсәрләрен күрсәтсәләр, үзебезнең татар классик пьесаларын дөньяга чыгарсалар, ул театрлар үз вазыйфаларын тулырак рәвештә үтәгән булырлар иде бит.

Театрларның көндәлек репертуарларына, сезон афишаларына күз салсак, янә сораулар туа. Аларда төпле татар классик әсәрләре юк диярлек дәрәҗәгә төшеп, күбрәк уртакул, сай фикерле, бары көлкегә генә корылган пьесалар урын ала. Мине иң борчыганы – театрларның каникул көннәрендә һәм Яңа ел бәйрәмнәрендә татар балаларына экиятләрне рус телендә уйнап, шуннан килгән акча белән финанс планын тутырып, үзләренең эшчәнлегеннән бик канәгать булып йөрүләре.

Татар халкына нинди сәнгать күрсәтелә соң? Татар балаларына нинди тәрбия бирелә? Рус телендә спектакльләр карап үскән балалар 20 елдан соң, үсеп җиткәч, татар театрына килерләрме? Килсәләр, татар телен аңларлармы?

Шушы хәлләргә борчылып, берничә театр директоры белән әңгәмә корып карадым. «Нигә соң үзебезнең классик драматургларыбызны куймыйсыз? Нигә аларның әсәрләрен күрмисез? Нигә аларның иҗатлары белән татар халкын таныштырмыйсыз? – дип сорагач, күбесе гаепләрен сизеп, дәшми калалар.

Дөрес, сирәк-мирәк кенә булса да Кәрим Тинчурин әсәрләре куела, аның исемендәге фестивальләр дә үткәрелә. Моңа барыбыз да шат. Ләкин Тинчуриннан башка да, татар драматургиясенең җәүһәрләре саналган язучыларыбыз бар бит. Шуларның берсе, әлбәттә, Таҗи Гыйззәт. Менә кайда иҗади байлык, менә кайда театрлар өчен хәзинә! Аның әсәрләре аша татарның тарихы, гореф-гадәтләре, борынгы уеннары, җырлары, бәетләре халыкка җиткерелә. Таҗи Гыйззәт әсәрләре янә нәрсәсе белән мине үзенә тарта соң, нәрсәсе белән үзенә җәлеп итә? Иң элек миңа аның югары профессионализмы кадерле. Таҗи Гыйззәт безнең бөтен драматургларга караганда да иң җитди, иң төпле әдип. Мин аны пьеса структурасын төзүдә, аның систематикасын аңлап, драматургиянең канунnарын үзләштереп, ул законнарны саклап, жанрларны бутамыйча, сюжет үсешен дөрес корып язган иң белемле, иң профессионал драматург дип әйтер идем. Ләкин нигәдер аның әсәрләре, соңгы дистә елда режиссерларыбыз игътибарыннан югалып, онытылып бара төсле.

Икенче кыйммәтле ягы, ул үзе күргән, үзе белгән, үзе кичергән чор турында яза. Ә аның әсәрләре аша тамашачы татар халкының бик үк белеп бетермәгән тарихын ача.

«Наемщик» яки «Бишбүләк» пьесасында безнең татар егетләренең дә гражданнар сугышында кылыч күтәреп, наганнар тагып йөрүләре бик гади генә итеп күрсәтелсә дә (чөнки жанр шуны таләп итә), мин ул әсәрләрне рәхәтләнеп, йөрәгемә якын алып, елмаеп кабул итәм. Чөнки бу безнең тарихыбыз.

Ә «Башмагым» әсәре безгә бөтенләй башка дөнья ача. Татар кешеләре чабата киеп, ындыр артында гына йөрмәгәннәр икән бит?! Бу искиткеч матур әсәрдә автор татар интеллегенциясен, зыялыларыбызны, затлы нәселләрне тасвирлый. Казан халкының яшәешен, тормышын оперетта сәнгате аша таныштыра.

Татарның фаҗигале тормышын күрсәткән «Чаткылар»ны карасак, халкыбызның шаянлыгын, шуклыгын, зирәк акылын сурәтли торган «Кыю кызлар»-ны искә төшерсәк һәм, әлбәттә, XX гасырның иң дәһшәтле чоры, революция көннәрен һәм гражданнар сугышын чагылдырган «Ташкыннар» трилогиясен хәтердә яңартсак, Т. Гыйззәт иҗатының нинди күпкырлы һәм бай палитра икәнлегенә инанырбыз.

Аларның барысында да тирән фикер, көчле кичерешләр, җор телле, кабатланмас образлар бар, сюжетта социаль проблемалар ярылып ята. Иң кадерлесе – санап киткән шушы әсәрләр, барысы да татар рухы белән сугарылган. Бу әсәрләр татар халкына гына хас. Аларны бүтән халык

тормышына күчереп тә булмый, нәкъ безнең милли йөзебезне сурәтли торган әсәрләр. Аларда татар рухы ярылып ята. Ә бу – милли сәнгать, милли театрларның нигезендә ятарга тиешле төшенчәләр. Татар телендә чит ил авторларын уйнап кына, татар рухын чагылдырып булмый. Милли театрның максаты, вазифасы – башка халыкларга үзебезнең милләт сәнгатен, мәдәниятен күрсәтү, милли рухыбыз белән таныштыру. Миңа калса, бу максатны үтәү өчен Таҗи Гыйззәт пьесалары иң кулай әсәрләр.

Ләкин соңгы елларда без бу әсәрләрне нигәдер театр сәхнәләрендә күрмибез. Нигә алар безнең яшь тамашачыны, киләчәк буынны милли рухта, милли телдә тәрбияләмиләр? Нигә балаларны татарның гореф-гадәтләре, борынгы уен-җырлары, бәетләре, милли киемнәре белән таныштырмыйлар?

Менә шул сорауларга җавап табып булмый. Минемчә, Таҗи Гыйззәтнең иҗатын түкми-чәчми, кадерләп, ел саен бер генә әсәрен куеп барсак, уңай җавап табылыр иде. Куйган саен заманча ысулларга таянып, яңа форма, яңа стилистика табылса, ул спектакльләрне чит төбәкләргә, театр фестивальләренә алып барсак, үзебезнең милли йөзебезне, милли рухыбызны андагы халыкка күрсәтсәк, чыннан да «Татар театр сәнгатен тагын бер баскычка күтәрдек!» – дип, горурланырга мөмкин булыр иде.

***Хәйруллин Илдар Зиннур улы,***
*Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты*

УДК 929

*Л. Хәмидуллин*

## УЛҺӘРЧАК ҮРНӘК БУЛДЫ

Җәмил абый Гыйльманов 1925 елның 3 июлендә Самара өлкәсенең Кошка кантоны Төплистан авылында укытучылар гаиләсендә туа. Җиде яше тулмастан, аларның гаиләсе безнең Иске Төгәлбуга авылына күчкән (1943 елдан Ульянов өлкәсенә керә). Ибраһим ага белән Баян апаның һәм балаларының калган гомере шул авылда уза. Ибраһим ага байтак еллар безнең мәктәпнең укыту бүлеге мөдире булды. Сугыштан соң егерме ел чамасы директор вазифасын башкарды. Иске Төгәлбуга биш мәчетле зур бер авыл (мәчетләрнең беришесугыш чорында, иң соңгы төзелгәне, иң озын манаралысы җитмешенче еллар ахырында гына сүтелде). Шул зур авыл халкы арасында гына түгел, район, өлкә күләмендә дә танылган укытучыларның берсе иде Ибраһим ага. Илленче елларда ук аның эшчәнлеге югары бәяләнә, ул Ленин орденына лаек була. Җәмил Гыйльманов менә шушы укымышлы гаиләдә тәрбияләнә. Мәктәптә уку елларында ук, ата-бабалары кебек, мөгаллим булырга хыяллланса да, сугыш өермәсе аның ул хыялын кичектереп тора. 1943 елның башында, әле унсигез яше дә тулмаган яшь егет хәрби училищега кабул ителә. Унтугызы тулгач, яшь лейтенантны яу кырына озаталар. Хәрби мәктәптә бергә укыган иптәше, җитмешенче елларда «Советский воин» журналын җитәкләгән Д.С. Азов аны батыр сугышчы буларак искә ала. «Хәрби частька билгеләнгәч тә аны рота командиры, мине взвод командиры итеп куйдылар. Һөҗүм барышында Җәмил йөз иллеләп сугышчыны әйдәп, алдан ургылыр иде...» дип яза. Алар батальоны Польша, Чехословакия, Германия җирләрен азат итешүдә катнаша, аннан соң Японияга каршы сугышка җибәрелә. Җ. Гыйльманов Кызыл Йолдыз, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, Германия һәм Японияне җиңү уңаеннан медальләр белән бүләкләнә. Чехословакиянең Братимов шәһәрен азат итүдәге батырлыгы өчен аны соңрак шул шәһәрнең шәрәфле кешесе буларак таныйлар.

Капитан Җ. Гыйльманов 1947 елда демобилизацияләнә һәм күптәнге хыялын тормышка ашыру нияте белән Казанга килә. Университетны тәмамлагач та, аны аспирантурага кабул итәләр. Тарих факультеты каршындагы аспирантура бүлеген тәмамлаганнан соң, ул КПССның Яшел Үзән шәһәре бүлегенә лектор итеп җибәрелә (1955–1962), бер үк вакытта Казан авиация институтында да укыта башлый (1958–1967). 1962 елның урталарында аны кабат Казанга кайтаралар, һәм ул ике телдә нәшер ителүче «Татарстан коммунисты» белән

«Коммунист Татарии» журналларының баш мөхәррире итеп билгеләнә. Ә ике елдан соң, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалындагы гыйльми институтта (ТӘТИ) мөстәкыйль тарих бүлеген оештыру уе тугач, аны шул институтка эшкә алалар.

Җ. Гыйльманов Тел, әдәбият һәм тарих институтында 26 ел эшли (1964–1990), чирек гасыр чамасы анда тарих бүлеге мөдире вазифасын башкара (1996 елда шул бүлек җирлегендә Тарих институты барлыкка килде.) Шул ук вакытта ул Казан дәүләт университетында укыта. 1984 елда докторлык диссертациясен яклый, 1985 елда ул профессор дәрәҗәсенә ирешә. Күпьеллык фәнни һәм педагогик эшчәнлеге өчен аңа 1972 елда РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре, 1985 елда ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, дигән мактаулы исемнәр бирелә.

Авылдашымның беренче гыйльми хезмәте университет фәнни журналының 1957 елгы санында басыла. Шуннан соң аның тарих фәненә багышланган дистәләгән китабы дөнья күрә. Җәмил Гыйльмановның гыйлем өлкәсендә сайланган төп темасы – Татарстан һәм татар халкының явыз дошманны җиңүгә керткән өлешен барлау һәм шул мәгълүматны ил күләмендә таныту. Җәмил абыйның иң соңгы, 1989 елда басылып чыккан китабының исеме дә шул хакта бәян итә: «Без сугышта юлбарыстан көчлебез». Дөрес, заманга яраклы рәвештә, аның хезмәтләрендә таркатылган коммунистлар партиясе эшчәнлегенә дә күп урын бирелгән. Ләкин ул дәвер коммунистларының оештыру, төрле өлкәләрдә җитәкчелек итү эшчәнлеген тарихтан сызып ташлап булмый. Бу чорда безнең барлык җитәкчеләр шул фирка вәкилләре иде бит инде.

Менә Җәмил аганың китаплары исемлеге: «Бөек Ватан сугышы елларында коммунистлар партиясе эшчәнлеге» (Г. Шумилов белән бергә языла, рус һәм татар телләрендә 1960 елда нәшер ителә); «Деятельность татарской областной партийной организации в период Великой Отечественной войны» (Казан, 1962); «Татария в годы суровых испытаний 1941–1945 гг.» (Казан, 1967); «Шла дивизия вперед» (автордашы Н. Кирсанов; Казан, 1972); «Татарская АССР в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг.» (Казан, 1977); «Трудящиеся Татарии на фронтах Великой Отечественной войне. 1941–1945 гг.» (Саратов, 1984; тарих фәннәре докторы исемен яклау нигезләмәсе); «Галимджан Сайфутдинов: очерк жизни и деятельности татарского революционера» (Казан, 1988) һәм алда әйтелгән «Без сугышта юлбарыстан көчлебез» (Казан, 1989).

Җәмил Гыйльманов татар халкы һәм Татарстан АССР тарихына багышланган күмәк хезмәтләрне туплап чыгаруда да башлап йөрүчеләрдән була. «Татарстан АССР тарихы: иң борынгы заманнардан алып безнең көннәргә кадәр» дигән китап рус телендә 1968, 1973, 1980 елларда, татарчасы 1970 елда нәшер ителгән. «Торжество ленинской национальной политики в Татарии»

(Казань, 1968); «Развитие филологических и исторических наук в Татарии» (Казань, 1969); «Очерки истории татарской партийной организации» (Казань, 1973); «Исследования по источниковедению истории Татарии» (Казань, 1980; «Рабочий класс Татарии» (Казань, 1981); «Герои Советского Союза – наши земляки», 3 томнан торган бу басма Казанда 1982–1985 елларда нәшер ителде. «Борцы за счастье народное» җыентыгының да 2 нче, 3 нче томнарын туплый. Казан, 1983, 1988 еллар. «История Казани» басмасының 1 нче томы 1989 елда, 2 нчесе 1991 елда Казанда чыга. «Летопись борьбы и свершений» – шулай ук ике томлы хезмәт, ул Казанда 1985 елда дөнья күргән. Җәмил аганың тарихка багышланган хезмәтләре шулай ук Мәскәү, Куйбышев, Алма-Ата, Йошкар-Ола нәшриятлары чыгарган җыентыкларга да кергән.

Башка тарихчылар хезмәтләренә бәя бирүче (рецензент) яки редактор буларак Җ. Гыйльманов түбәндәге китапларны чыгаруда катнаша: С.Х. Алишевның «Татары Среднего Поволжья в пугачевском восстании» (Казань, 1973); «Исторические судьбы народов Среднего Поволжья XVI – нач. XIX вв.» (Москва, 1990); А.М. Җәләлевнең «Социологическое преобразование сельского хозяйства в Татарии. 1917–1937 гг.» (Казань, 1974); К.А. Нәҗиповның «Национализация промышленности в Татарии. 1917–1921» (Москва, 1976; Ю.И. Смыковның «Крестьяне Среднего Поволжья в период капитализма» (Москва, 1984) һ.б.

Остаз буларак, Җ. Гыйльманов дистәләгән галимне тәрбияләүдә катнаша. Аның аспирант һәм докторантлары арасында тарих фәннәре докторы И.К. Заһидуллин, В.В. Кузьмин, А.Ш. Кәбирова һ.б. бар. Улы Руслан Гыйльманов – химия фәннәре докторы, технологик университетта кафедра мөдире. Җәмил Ибраһим улы Гыйльманов, сугыш зәхмәтенә кагылышлы булган дәвамлы чирдән интегеп, 1991 елның 15 декабрендә арабыздан китте.

**Аңа багышланган әдәбият**

*Азов Д.С.* Воспоминания // Советский воин. 1984. № 14.

*Насыров Г.* Течения жизни. Самара. 2005;

*Гарипова З.Г.* Верность воинскому и научному долгу // Научный Татарстан. 2000. № 1.;

Памяти Зямиля Ибрагимовича Гильманова. Казань, 2000.

*Хамидуллин Л.Х.* На страже Родины с винтовкой и пером // Научный Татарстан. 2010. № 2.

***Хәмидуллин Лирон Хәйдәр улы,***
*язучы, Г. Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе*

УДК 821.512.145-4

*Иржан Алкая*

## СЕБЕРГӘ СӘЯХӘТ

Статья посвящена результатам научной экспедиции турецкого ученого-языковеда в Сибирь, предпринятой с целью изучения современного быта, нравов и обычаев сибирских татар. Автор, который занимается научными исследованиями в области диалектов татарского языка, в частности сибирских татар, делится своими впечатлениями от поездки.

**Ключевые слова:** тюркские языки, диалекты татарского языка, сибирские татары.

Orda bir köy var, uzakta,
O köy bizim köyümüzdür.
Gezmesek de, tozmasak da
O köy bizim köyümüzdür.

Анда бер авыл бар, еракта
Ул авыл безнең авылдыр
Гизмәсәк тә, йөрмәсәк тә
Ул авыл безнең авылдыр.

Төрки дөньяны күз алдыма китерү белән, акылыма шагыйребез Әхмәт Кудси Тәҗәрнең «Анда бер авыл бар еракта» исемле шигыре килә. Мин 1973 елда тудым, әнием җырлаган бишек җырлары, әбием сөйләгән әкиятләр белән үстем, ана телем булган төрек теле ярдәмендә дөньяны таныдым, аның ярдәме белән үз дөньямны кордым. Яшь чагымда бу телдә сөйләшкән кешеләрнең, Төркиядән тыш, башка җирләрдә дә яшәгәнлекләрен белдем. Төрки дип аталучы халыкларның иксез-чиксез киң мәйданнарны биләгәнлекләрен һәм һәр милләткә дә насыйп булмаган бай тарихка ия булганлыкларын аңлаганда, мин инде университетның тюркология бүлегендә белем алучы бер студент идем.

Элязыгда Фырат университетының Төрек теле һәм әдәбияты бүлеген 1994 елда тәмамлаганда, кардәшләремнең Балканнардан Тын океанга, Төньяк котыптан Тибетка кадәр җәелгән киң бер мәйданда яшәгәнлеген һәм татар, казакъ, кыргыз, алтай, тува, хакас, якут, башкорт һәм башка исемнәр белән телгә алынган олы Төрек ата балаларының Кытай, Монголия, Россия, Украина, Молдавия, Румыния, Югославия, Болгария, Македония, Греция, Сүрия, Гыйрак, Иран, Таҗикстан, Әфганстан, Польша, Литва кебек чит илләрдә һәм Төркия, Төньяк Кипр төрек җөмһүрияте, Азәрбайҗан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Казакъстан һәм Себер кебек җирләрдә көн күргәннәрен белә идем. Шул вакыттан башлап, ул җирләргә барып, кардәшләрем белән очрашып-күрешү теләге белән яши башладым.

Беренче бөтендөнья сугышыннан соң, дөньяда көчләр балансы үзгәреп, дәүләт чикләре кабаттан билгеләнде. 1917 елдагы большевиклар революциясеннән соң, төрки дөнья белән булган бәйләнешләребез, аралашу мөмкинлекләребез бөтенләйгә юкка

чыккан иде. 1990 нчы елларга кадәр, ул җирләрдән чынбарлыкны дөрес чагылдырган мәгълүматлар килмәде, очрашулар мөмкин түгел иде. Бу да кардәшләребезгә карата булган хәсрәтебезне арттыра иде. 1990 нчы елларда, Советлар Союзы тарала башлагач, хәлләр берникадәр үзгәрде. Азәрбайҗан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан, Казакъстан һәм Кыргызстан бәйсез төрки җөмһүриятләр буларак, дөнья аренасында үз урыннарын алдылар. Россия эчендәге татар, башкорт, тува, хакас, алтай, чуваш, якут кебек төрле төрки халыклар да, үз автономияләре эчендә билгеле бер казанышларга ирештеләр. Тора-бара бу җирләрдә яшәүче кардәшләребез белән элемтәләр корып, алар белән аралаша башладык.

Orda bir ses var, uzakta,
O ses bizim sesimizdir.
Duymasak da, tınmasak da,
O ses bizim sesimizdir.

Анда бер аваз бар, еракта,
Ул аваз, безнең аваз.
Ишетмәсәк тә,тынмасак та,
Ул аваз безнең аваз, димәдек.

Чөнки без бер-беребезне ишетә, аңлый ала идек инде.

Университет елларындагы хыялым 1996 елда чынга ашты. Ул елларда Төрки дөньяны тикшеренүләр вакыфының җитәкчесе мәрхүм доктор, профессор Туран Язган Азәрбайҗан, Казакъстан, Кыргызстан, Татарстан кебек өлкәләрдә төрек телендә белем бирә торган мәктәпләр ачып җибәргән иде. Туран Язган кадерле остазым филология фәннәре докторы, профессор Әхмәт Буран белән элемтәгә кереп, Татарстандагы шундый мәктәпләрдә эшләр өчен бер кеше җибәрүен сораган. Остазым, миннән: «Татарстанга барыр идеңме?», – дип сорауга, бер секунд та уйлап тормастан, «Әйе!», – дип җавап биргән идем. Шул максат белән 1996 елның ноябрь аенда Татарстанга килдем һәм Чаллы шәһәрендәге татар-төрек кызлар лицеенда бер ел төрек теле укытучысы буларак эшләдем. Яшьлек хыялларым чынга ашты, ниһаять, күп еллар буе күрешергә, дип хыялланган кардәшләрем белән очрашу бәхетенә ирештем. Бу вакыт эчендә татар телен өйрәндем, татар дөньясы һәм халкы белән якыннан таныштым. Татарстанның бик күп шәһәрләрен күрдем, моның белән генә чикләнеп калмыйча, Башкортстан республикасына, Пермь өлкәсенә барып, төрле тикшеренүләр үткәрдем. Чаллыда эшләгәндә, хәләл җефетем – Лилия белән таныштым һәм, 1998 елда өйләнешеп, үзебезнең гаилә учагын корып җибәрдек. Никахыбыздан Аллаһы Тәгалә, гаиләбезнең бизәкләре булган Алпарыслан Тукай белән Кылычарыслан Гюнай исемле ике ир бала насыйп итте. Төркиягә кайтканнан соң, төрки диалектлар, бигрәк тә татар теле белән бәйле фәнни эшчәнлегемә керештем.

Татарлар, үз башларыннан бик күп фаҗигаләрне үткәргән халык. 1552 елда Казан ханлыгы басып алынганнан соң, алар зур кыенлыклар кичергән, төрле сәбәпләр аркасында туган җирләре Идел-Урал буйларын

ташлап, бик ерак җирләргә китәргә мәҗбүр булганнар.

Бүгенге көндә татар халкының бер өлеше Себердә яши. Себер татарлары (икенче исеме – Көнбатыш Себер татарлары) бер җирдә тупланып яшәгән иң ерак татар төркемнәреннән санала. Билгеле булганча, кыпчак төркеменең әһәмиятле бер тармагын тәшкил иткән татар теле урта (казан татарлары диалекты), көнбатыш (мишәр), көнчыгыш (Көнбатыш Себер; себер татарлары) диалектларга бүленсә дә, телнең барлык өлкәләрен уртак билгеләр белән берләштергән бербөтен система буларак яши.

300 мең чамасындагы халкы булган себер татарлары хәзерге көндә Төмән, Новосибирск, Омск өлкәләрендә яшиләр. Алар үз эчләрендә Тобол-Иртыш (Төмән, Тобол, Саз төбәге, Тәбриз һәм Тара), Бараба, Том сөйләшләренә бүленәләр. Татар халкы, татар теле белән бәйле тикшеренүләрем барышында, Себер татарлары белән кызыксына башладым, аларның диалект һәм сөйләшләре турында фәнни китаплар язарга булдым. Шул сәбәпле, Казанга килеп, сүзлек, текстлар, китаплар һ.б. чыганакларны тупларга керештем. 2006 елда, Казанда алып барган тикшеренүләрем вакытында, филология фәннәре докторы, профессор Фәрит Йосыпов белән очраштым. Мин аның белән 2000 елда Төркиянең Измир шәһәрендә үткәрелгән Халыкара симпозиумда танышкан идем. Ул миннән Казанга килүемнең максаты турында сорагач, мин себер татар диалектының грамматикасын язу өчен материал тупларга килгәнлегемне әйттем. Мондый хезмәт язачагымны ишетеп, ул бик сөенде һәм миңа кирәкле һәртөрле ярдәм күрсәтәчәген әйтте. Кулымда әзерләгән китап исемлеген карап чыгып, бер көннән соң күрешергә булдык. Иртәгесе көнне үз күзләремә үзем ышанмадым, ул мин бик күптән эзләгән китапларны алып килгән дә иде инде. Казанда булган вакыт эчендә башка чыганакларны да китерә торды. Бер вакыт аннан: «Фәрит абый, мин дә сезгә берәр нәрсә эшли алмыйммы?», – дип сорагач, ул: «Берни дә кирәкми, киресенчә, мин һәрвакыт сезгә кирәкле ярдәмне эшләргә әзер, сез бит минем халкыма, аның теленә, әдәбиятына, мәдәниятенә хезмәт итәргә тырышасыз. Мин синең өчен ниләр генә эшләсәм дә, аз булыр» – дип җавап бирде.

Төркиягә кайтып, себер татарларына багышланган фәнни-тикшеренү эшләремне дәвам иттем. Төмән, Омск, Новосибрск өлкәләреннән җыелган 90 текстны компьютерыма керттем, бу текстларга нигезләнеп, фонетика һәм морфология бүлекләрен яза башладым. Хезмәтнең кереш өлешендә Себер топонимының мәгънәсен, Себер татарларының тарихы һәм этник яктан килеп чыгышы, аларның башка төрки кавемнәр белән мөнәсәбәте, яшәгән җирләре, халык саны, диннәре, социаль яшәешләре, гореф-гадәтләре һәм фольклоры, Себер татар теленең төрки диалектлар эчендәге урыны, аңа багышланган хезмәтләр хакында да мәгълүмат бирдем. Хезмәт 2008 елда, Әнкарада нәшер

ителде. Ул Төркиядә һәм Казанда бик җылы кабул ителде. Фәрит абый хезмәтнең танылуына зур өлеш кертте, 2015 елның июлендә Казанда булганда, бу хезмәтне Себердә дә танытырга кирәклеген әйтте.

Себергә бару, ул мөкатдәс туфракка аяк басу, андагы кардәшләрем белән күрешү, ул җирләрнең һавасын сулау, суын эчү, икмәген ашау – минем иң зур теләкләремнең берсе иде. Ул җирләрне үз күзләрем белән күрү күңелемдә йөрткән бер хыялым иде. Фәрит абый бу эшне тиз тотты, мине Бөтендөнья татар конгрессы рәисе Ренат Закиров белән таныштырды. Ренат әфәнде дә бу фикерне уңай кабул итеп, Төмәнгә бару өчен кирәкле шартлар тудырачагы турында белдерде. Нәтиҗәдә, 2015 елның 9–13 ноябрендә Төмәнгә китәргә, дип карар кылынды. Шул минутларда минем телемә Төркиядә һәр кеше яратып яттан укый торган бер шигырь килде:

Orda bir dağ var, uzakta,
O dağ bizim dağımızdır.
İnmesek de, çıkmasak da
O dağ bizim dağımızdır.

«Анда, бер тау бар, еракта,
Ул тау, безнең тавыбыз.
Төшмәсәк тә, менмәсәк тә
Ул тау безнең тавыбыз».

7 ноябрь, шимбә көнне, Истамбулдан Казанга очкан самолетка менгәндә, сөйләп кенә аңлатып булмаслык хис-тойгылар эчендә идем. Иртәгесе көнне Фәрит абый белән сәяхәтебезнең нечкәлекләрен сөйләштек. 9 ноябрь, дүшәмбе көнне, Казанның Северный вокзалыннан сәгать иртәнге сигездә кузгалачак поездга утырып, Төмәнгә юл тоттык.

Очсыз-кырыйсыз Россия киңлекләре буенча, бигрәк тә кышның салкын сулышы килеп торганда, поезд белән сәяхәт итү аеруча рәхәт икән. Моңа кадәр Төркиядә дә поездга утырганым булмаганлыктан, бу минем өчен бигрәк тә гаҗәеп тоелды. Купеларда икесе аста, икесе өстә урнашкан урыннар бар. Һәр юлчыга караватъ, одеял, чиста урын-җир әйберләре бирелә икән. Янда гына ресторан вагоны булуы да бер рәхәтлек өсти. Юлыбызны, Фәрит абый белән бергә әңгәмә корып, юлга дип алган тәм-томнарыбызны ашый-ашый, чәебезне эчә-эчә дәвам иттек. Казанда иртәнге сәгать сигездә башланган юлыбыз Әгерҗе, Екатеринбург, Красноуфимск кебек берничә шәһәрне үтеп, иртәнге сәгать дүрт тулып егерме ике минутта (Төмән сәгате белән алты тулып егерме ике минут) Төмәндә тәмамланды.

Поездан төшкәндә, һава бик суык иде. Безне дүрт көн буе сәяхәт иттерәчәк шофёрыбыз, себер татары – Газинур Сәетовның җылы каршылавы, бу суык һаваны бераз җылытып җибәргәндәй булды. Кечкенә булуына карамастан, җылы һәм тыныч кына бер кунакханәгә урнаштык. Икеөч сәгать ял иткәннән соң, иртәнге ашны ашар өчен кунакханәбезгә якын булган Төмән татар мәдәни үзәгенә киттек. Үзәктә безне бик җылы каршы алдылар. Анда Вәлимә Ташкалова һәм Бибинур Сабирова исемле бик матур ике ханым белән таныштым. Вәлимә ханым татар культура үзәгендә җитәкче булып эшләүче

бер сылу себер ханымы иде. Ул Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе, үзе дә себер татарларыннан булган фольклорчы галимә, мәрхүмә Флора Урманчега бик охшаган иде. Флора ханым белән без, Измир шәһәрендә үткәрелгән бер халыкара симпозиумда танышкан идек. Вәлимә һәм Бибинур ханымнар икесе дә Флора ханым белән якын дуслар булганнар икән. Бибинур ханым күп еллар укытучы, аннан соң Төмән өлкәсенең Укытучылар белемен күтәрү институтында татар теле укытучыларының җитәкчесе булып эшләгән. Бүгенге көндә лаеклы ялда булуына карамастан, мәдәни чараларның даими катнашучысы, үзе оештырган «Ак калфак» исемле интернет-журналның редактор вазифаларын башкара. Һәр икесе дә, дүрт көн буе, яныбыздан аерылмыйча, һәр җирдә безнең ярдәмчеләребез булдылар.

Төмәндәге программабыз иртән үк башланып китте. Беренче булып, безне Төмән өлкәсе хакимиятенең Милли эшләр комитетының рәисе Евгений Михайлович Воробьёв кабул итте. Ул, бу вазифасына кадәр, Тобол шәһәренең мэры булып эшләгән икән. Без аңа Себер татарлары турындагы китапларыбызны бүләк иттек. Миңа аның Себер татарларына кагылышлы проблемалар белән якыннан таныш булуы, шуларга карата уңай фикердә булуы ошады. Ул Казанда себер татарларының антологиясе төзелә башлауны бик шатланып кабул итте. Милли эшләр комитетыннан соң, без Төмән татарларының атналык «Яңарыш» газетасына юнәлдек. Газетаның мөхәррире Алсу Сәгыйтова җитәкчелегендәге иҗат коллективы безне себер татарларының милли ризыкларыннан гына әзерләнгән мул табын белән каршы алды. «Яңарыш» газетасы 1990 елдан бирле чыгып килә икән. Гүзәл татар ашларыннан авыз итеп, себер күлләренең иң зур байлыкларыннан саналган табан балыгын бик яратып ашадым. Миңа ул гомеремдә ашаган балыкларның барысыннан да тәмлерәк тоелды. Бәхетемә, без булган себер авылларының һәркайсында мул табыннарның иң дәрәҗәле урынында бу балык куелды.

Өйләдән соң шәһәрнең бизәге булып саналган тарихи матур таш бинага урнашкан, концерт салоны, музее, тел укыту дәресханәләре булган Төмән татар мәдәният үзәгендә, Төмән җәмәгатьчелеге алдында «Сибирия татар төрекчәсе» һәм «Сибирские татары: из сокровищницы духовной культуры. Антология сибирских татар», «В.В. Радлов. Образцы народной литературы тюркских племен, живуших в Южной Сибири и Джунгарской степи, часть 4. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар» дигән китапларыбызны таныту башланды. Бу үзәкнең матди чыгымнарының бер өлешен өлкәнең атаклы эшмәкәре Ринат Насыйров каплый икән. Төмән өлкәсендә, 2010 нчы ел күрсәткечләренә караганда, 3395755 кеше яшәгән. Халык санының 73,3%ын (2352063) руслар, 239995 кешелек төркемне барлыкка китергән татарлар исә 7,5% ын алып тора.

Китапларыбыз белән таныштыру концерт салонында узды. Мин «Себер татарчасы» исемле хезмәтем белән таныштырдым, ә филология фәннәре докторы, профессор Фәрит Йосыпов «В.В. Радлов, Образцы народной литературы тюркских племен, живших в Южной Сибири и Джунгарской степи, часть 4. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар» исемле хезмәте белән «Сибирские татары. Из сокровищницы духовной культуры» исемле хезмәтләре турында сөйләде. Бу очрашуга махсус чакырылган галимнәр, татар җәмәгатьчелеге, күпсанлы мәдәният һәм мәгариф эшлеклеләре катнашты. Китап авторларының чыгышыннан соң, танытуда катнашучылар үзләрен кызыксындырган мәсьәләләре буенча сораулар бирделәр, кайбер проблемалар хакында безнең фикерләребезне белергә теләделәр. Соңыннан Төмән өлкәсенең танылган җырчылары Мөнирә Хөснетдинова, Луиза Сөрмәтова, Айсылу Йонысова һ.б. үзешчән артистлар катнашында бик матур концерт булды. Алар себер татарларының күз явын алырлык милли киемнәрендә чыгыш ясадылар. Күңелле һәм файдалы, бик җылы шартларда үткән концерттан соң, эчкерсез әңгәмәләр күңелемә хуш килде. Миңа төрекчә: «Иржан әфәнде, хуш килдегез!» – дип бер чибәр ханым сәлам бирде. Зөлфия Булдык исемле бу ханым безнең киленебез булып чыкты. Ире Карс шәһәреннән, ике балалары бар икән. Аларның матур гаилә коруларына мин бик сөендем.

Мин, Фәрит абый һәм Бибинур апа белән бергә мәрхүм фольклорчы, филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Флора Урманченың апасы Роза Ниязованың өендә кунак булдык. Роза ханым һәм оныгы Гүзәл безне зур бер кунакчыллык һәм ачык йөз белән каршыладылар. Алар пәрәмәч, кош теле, бавырсак, төрле бәлешләр һәм табан балыгыннан торган бик мул табын корганнар иде. Гомеремдә беренче тапкыр себер татарлары белән якыннан танышуыма чиксез шатлану һәм дулкынлану хисләрен кичердем.

Бу шатлык һәм дулкынлану хисләре чәршәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә дә дәвам итте. Төмән районының Янбай, Түбән Тәүде районының Янтык һәм Саз (Тарман), ә икенче көнне Ялутор районының Аслана һәм Яңа Атъял авылларында булдык. Һәр авылда да күңелләребездә гомерлеккә истә кала торган үзенчәлекле каршы алулар, җирле артистларның чыгышлары хәзерләнгән иде. Мәдәни үзәктә яки мәктәпләрдә авыл халкы милли киемнәрен киеп, гармуннар уйнап, татар җырлары һәм халык уеннары белән каршы алдылар. Алыштыргысыз табан балыгы, тәм-томнарга мул табыннардан соң, безнең өчен хәзерләнгән тамашаларны карап, халыкның мәдәни сәләтенә хәйраннар булып утырдык. Төрки халыкларга гына хас булган киң күңелле авыл кешеләре тормыш-яшәешләре, өй-куралары, горурлыклары саналган мәчетләре белән дә таныштырырга

онытмадылар. Авыллар берберләреннән үзләренә генә хас булган матурлыклары белән аерылып торалар. Совет чорында мәчетләр я ябылган, я җимерелгән, яисә башка максатларда кулланыла башлаган. Милли һәм дини тормыш бары тик 1990 нчы еллардан соң гына җанлана башлаган. Нигъмәтуллаһ хаҗи Кармышаков тарафыннан Янбай авылында 1884 елда төзелгән мәчет Төмәндәге иң иске мәчетләрнең берсе санала. Ул күпләрнең игътибарын үзенә генә хас сәнгати бизәлеше белән җәлеп итә. Миңа да Янбай авылындагы тарихи мәчеттә ике рәкәгать шөкер намазы уку насыйп булды.

Мин Аслана һәм Яңа Атъял кебек кайбер авылларны электән үк ишетеп белә идем. «Себер татарчасы» исемле китабымда бу авыллардан җыелган текстлар да урын алып тора. Аслана авылында китабымны таныткандa, бу авылдагы кешеләрдән тупланган материаллар да булганын сөйләдем, аларның исемнәрен атап чыктым. Текстларның язып алыну тарихы 1990 нчы елларга карый. Авторларның күбесенә бу вакытларда 70 яшь тирәсе булгандыр. Бүген аларның күбесе гүр иясе. Китабымда Фәүзия Бакиева исемле бер ханымнан язып алынган текст та бар иде. Ул вакытта Фәүзия ханым 54 яшендә булган. Ул да хәләл җефете белән безнең белән очрашуга килгән иде. Аңа хәзер 75 яшь икән. Аның исемен әйтүгә, залдагы бөтен кеше кул чабып, бер авыздан: «Менә гуй, каршыңда утыраты гуй!» – диделәр. Мин бу очракка бик сөендем. Үзеннән язып алынган җырларны укып күрсәттем:

Алма бөртеккәе төшкән,
Минем яулыкларыма.
Синең сагынуларың җитми,
Минем сагынуларыма.
...
Сандугацым әйтеп сайра,
Песнең тыуганнар кайта.
Сантугац итем, ай, илемтә,
Сайрый торган итем җиремтә.
Сандугац телен белмәсәм тә.
Сайрый торган итем илемтә.
...
Утырдым көймәнең түренә,
Каратым суларның төбенә.
Сыу төпләрентә ич кара юк,
Аллам язган эшкә чара юк.

Бу җырларны укыганнан соң, Фәүзия ханым белән аның тормыш иптәшенең күңелләре нечкәреп, күзләреннән яшьләр килде: Төркиядән берсе китап язачак һәм ул китапта сезне дә телгә алачак, дип кем уйлаган инде... Бу алар өчен, әлбәттә, сөйләп бетергесез бер шатлык булды. Мин аларның икесенең арасына утырып фотога төштем. Фәүзия апа махсус минем өчен бер-ике куплетлык бер матур җыр җырлап күрсәтте, аны да камерама төшереп алдым.

Ике көн дәвамында Янбай, Янтык, Саз (Тарман), Аслана һәм Яңа Атъял авылларында гадәттән тыш мизгелләр кичердек. Дөньяның шундый ерак почмагында яшәгән, моңа кадәр миңа билгеле булмаган милләтем өчен мин тагын бер тапкыр горурлык хисләре кичердем, мине төрек булarak яратканы өчен һәм бу бөек милләтнең бер күзәнәген тәшкил итүемә Аллаһыма меңнәрчә шөкер иттем.

Дүрт көн буена дәвам иткән сәфәребез ахырына якынлашты. Барлык көннәребез авылларда үткәнлектән, Төмән шәһәрен күрү форсатыбыз булмаган иде. Шофёрыбыз Газинур абый безне берике сәгать эчендә Төмән шәһәре белән таныштырып чыгарга булды. Төмән шәһәрендәге тарихи урыннарга һәм шәһәр үзәгенә алып барды. Боз белән каплана башлаган Тура елгасын, Кызлар монастырен, Ир-атлар монастырен, иске чиркәүләрне күрү һәм рәсемгә төшерү мөмкинлеге булды. Аннан соң борынгы дип саналган «Сабыр» мәчетен зыярәт итеп, мәчетнең имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт белән аралаштым. Мәчет 2003 елда торгызылган, кечкенә генә булса да, бик уңай һәм бик матур.

Казанга кайту вакыты да якынлашты. Газинур абый безне поезд станциясенә китерде. Әйберләребезне купега урнаштырдык. Карасак, перронда кулларына күчтәнәчләрен тотып Вәлимә һәм Бибинур апалар басып торалар. Безгә юлда ашарга дип, үз куллары белән татар ашлары пешереп китергәннәр. Бу яхшы күңелле кешеләрдән аерылу авыр булса да, хушлашу сәгатебез җиткән иде инде...

Поездыбыз Казанга таба хәрәкәт иткәндә, телемдә татар җырлары, йөрәгемдә ул кешеләрне ярату, акылымда еллар буе уйлап йөргән, хыялымда һәм хәтеремдә җуелмаячак гүзәл хатирәләр бураны иде. Шагыйребезнең тагын шушы юллары искә төште:

Orda bir yol var, uzakta,
O yol bizim yolumuzdur.
Dönmesek de, varmasak da
O yol bizim yolumuzdur.

Анда бер юл бар, еракта,
Ул юл, безнең юлыбыз.
Кайтмасак та, бармасак та
Ул юл, безнең юлыбыз.

Әй, газиз кавемдәшләрем, сезне гомерем буе күңел түрендә саклаячакмын, сезне беркайчан да онытмаячакмын. Яратуыгызны һәм җылылыгыгызны Һәрвакытта да йөрәгемдә йөртәчәкмен. Бу турыдагы изге төшенчәләрне миңа тагын бер кат хәтерләтүегез һәм зиһенемә сеңдерүегез өчен рәхмәт сезгә!

***Алкая Иржҗан,***
*филология фәннәре докторы,*
*Фырат университеты профессоры, Төркия, Элязыг*
*E-mail: ealkaya16@gmail.com*

# ТӨРКИ ХАЛЫКЛАРНЫҢ КАҺАРМАНЛЫК ЭПОСЫ
## (Ф.И. Урманчеевның «Тюркский героический эпос» монографиясе турында)

Фольклористикада үзенең сүзен әйткән, күп санлы мәкаләләре, саллы монографияләре белән татар фольклорын дөнья аренасына чыгарган күренекле галим Фатих Урманченың (Фатих Ибраһим улы Урманчеев) яңа китабы дөнья күрде. Төрки эпосны бер система буларак тикшергән «Тюркский героический эпос» – галимнең гомер буе тупланган тәҗрибәсенә таянып монографик планда язылган хезмәт.

Фатих Урманчеев фольклор фәненең берничә юнәлешендә эшли. Ул татар дастаннарын беренчеләрдән булып фәнни әйләнешкә керткән һәм төрки эпосны гомуми планда өйрәнгән галим. Галимнең яратып башкарган икенче эше – мифология өлкәсендә эзләнүләр. Ф.И. Урманчеев татар мифларын бербөтен система буларак өйрәнә. Әдәбият белән фольклор бәйләнешләре, татар әдипләренең иҗатын фольклор һәм мифология кодлары аша анализлау – галимнең өченче фәнни юнәлеше. Шуны да әйтү урынлы булыр, ул татар фольклорын гына түгел, дөнья халыклары фольклорын да яхшы белә. Теләсә кайсы халыкның күпчелек фольклор әсәрләре турында үзенең фикерен әйтерлек дәрәҗәдә энциклопедик белемгә ия галим.

Шулай да Ф.И. Урманчеев беренче чиратта фольклорда эпос жанрын өйрәнүче галим. Ул, татар фольклористикасы тарихында беренче булып, дастан жанрын өйрәнә башлый. Татар дастаннарын тикшерүгә багышланган «Героическое сказание «Ак Кубек»», «Сказание «Йир Тюштюк»» у тюркоязычных народов», «По следам Белого Волка», «Тюрко-башкирские сккзания о Туляке», «Легенды о булгарских богатырях и сказание об Алпамыше», «Традиции тюркского эпоса в сказании “Джик Мэргэн”», «Татарска версия сказания “Кузы Курпяч и Баян-Сылу”», «Героико-архаическое сказание “Алтаин Саин Суме”» һәм башка күп санлы фәнни мәкаләләр (татар дастаннарына багышланган 17 мәкалә) «Советская тюркология» журналында күп еллар дәвамында басылып килә.

Алабуга педагогия институтында эшләгән дәверендә татар халкының эпосын тикшерүгә багышланган «Героический эпос татарского народа» монографиясен язып тәмамлый. Монография 1984 елда 3300 тираж белән басылып чыгып, татар фольклорчыларының гына түгел, азәрбайжан, кыргыз, казах, үзбәк, нугай һәм башка халык галимнәренең дә өстәл китабына әйләнә. Чыккан елында ук раритетка әйләнгән бу хезмәт хәзергә көнгә кадәр фәнни кыйммәтен югалтмый. Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, галимнең соңрак чыккан хезмәтләрен дә шул ук язмыш көтә. Ф.И. Урманчеевның татар эпосына багышланган «По следам белого волка» (1994), «Идегәй. Нурсолтан. Сөембикә» (1997), «Народный эпос «Идегей» (1999) монографияләре дә дөнья күрде.

Ниһаять, 2015 елда шушы күп еллык фәнни эшчәнлекнең күркәм

нәтиҗәсе буларак «Тюркский героический эпос» монографиясе басылып чыкты.

Хезмәттә төрки эпос сюжет композициясен тәшкил иткән төп мотивлар аша бербөтен система буларак анализлана. Галим, төрки эпосны чагыштырма-тарихи планда тикшереп, аның дөнья эпосының аерылгысыз бер өлеше булуын дәлилли.

Кереш өлештә төрки халыкларның эпосын тикшерүгә багышланган хезмәтләргә күзәтү ясала. Төрки халыкларда эпос жанрының терминнарына туктала, укучыны төрки эпосны классификацияләү мәсьәләсе белән таныштыра. Хезмәтнең максаты – эпик әсәрнең күпсанлы мотивлардан торган композициясен реконструкцияләү һәм торгызу, эпос композициясенең эзлекле система булуын исбатлау, халык эпосының «уртак» иң борынгы архетип сюжетын табу.

Ф.И. Урманчеев фольклористикада эпик әсәрләрнең сюжеты һәм композициясен Борынгы Шәрыкъ мифологиясе, фольклоры һәм язма әдәбияты традицияләрен, фольклордагы һәм әдәби әсәрләрдәге төп мотив, сюжет һәм композиция үзенчәлекләренең зороастризм, буддизм, христианлык һәм ислам китапларында ук калыплашкан булуын истә тотып өйрәнү генә тиешле нәтиҗәләргә китерүен яза (34 бит).

Монографиядә эпос структурасы «Истоки. Начало повествования», «Бездетность. Вымаливание детей», «Рождение героя», «Имя эпического героя», «Детство героя. Богатырьский конь и оружие», «Выезд. Богатырсткое сватовство», «Битвы богатырей», «Гибель героев. Конец повествования» бүлекләрендә анализлана. Галим һәр мотивны фольклорның иң борынгы катламнарына төшеп, генетик тамырларын барлап, мифология, антропология, тарих фәннәре ачышлары белән чагыштырып тикшерә. Шул ук вакытта эпоста халыкның иҗтимагый, фәлсәфи, эстетик карашлары чагылуын күрсәтә һәм, икенче яктан, халык иҗатының бу жанрының этносның дөньяны танып-белүе формалашуда уйнаган ролен ачыклый.

Хезмәтнең тагын бер кызыклы ягы – Ф.И. Урманчеев эпик мотивларның төрки халыклар, шул исәптән татар халкының, тормышында ни дәрәҗәдә саклануын да күзәтеп бара. Бу укучыга аларның ерак тарих һәм анда калган вакыйгалар гына булмыйча, ерак бабалардан килгән хәбәр-хәтер булып, бүгенгә кадәр килеп җитүен аңларга ярдәм итә.

Яңа гына басылып чыккан бу хезмәт турында аңа тиешле бәя биргән рецензияләр әле булыр, дип уйлыйбыз. Әлбәттә, гаять катлаулы һәм дә кызыклы бу хезмәтне укып чыгу һәм кабул итү зур әзерлек таләп итә. Әмма бу монография турында ишетеп, аны Россия, Казахстан, Азәрбайҗан галимнәре үзләрендә булдыру хәстәренә керешкән икән, димәк, бу югары дәрәҗәле, кирәкле хезмәт. Татар фольклор фәненең бу дәрәҗәгә чыгуы – безнең өчен горурлык. Афәрин, Остазым!

***Закирова Илсөяр Гамил кызы,***
*филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

## ИЛДАР ХАНОВ. ВОСПОМИНАНИЯ, РАЗМЫШЛЕНИЯ О ТВОРЧЕСТВЕ
## (автор-составитель Р.Р. Султанова)

Бу китапта танылган рәссам-монументалист, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Илдар Мәнсәви улы Ханов турындагы истәлекләр һәм замандашларының аның тормышы һәм иҗаты хакындагы уйланулары урын алган. Алар хәзерге заман сәнгатенең, мәдәниятенең күп кенә проблемаларына, шулай ук рәссамның җәмгыятьне рухи үсешендәге эшчәнлегенә тукталганнар.

Китап алты бүлектән тора: «Неизвестные страницы», «Шестидесятники», «О творчестве», «Старое Аракчино», «Учитель», Просвещение». Материаллар рус, татар, инглиз, төрек телләрендә нәшер ителгәннәр.

Китапның авторы Р. Солтанова башлап йөрүе белән нәшер ителгән бу басмадан талантлы сәнгатькәрнең генә түгел, ә бәлки аны укытучы, эзотерик, рәссам буларак искә алган дусларының да күңел җылысы бөркелә.

Китапны укыгач күз алдыбызга гаҗәеп язмышка ия булган, күп кенә кызыклы проектларын тормышка ашырган кеше күз алдына килеп баса. Тормыш мәктәбе, иҗат мәктәбе, социаль мөнәсәбәтләр мәктәбе – игътибарлы укучы боларның һәммәсе турында да әлеге басма битләреннән таба алачак.

Китапның бизәлешен аерым билгеләп үтәсем килә. Китапның дизайн-концепциясен Кама сәнгать һәм дизайн институты эшләгән. Бүлекләрнең төгәл урнашуы, шрифт сайлау, композицион төзелеш аны тулы бөтенлегендә кабул итәргә мөмкинлек тудыра һәм танылган замандашыбыз иҗатын төрле яклап ачарга ярдәм итә.

Китап киң катлам укучыларга адресланган, тарихи һәм иҗади кыйммәткә ия булган рәсемнәр белән баетылган.

***Пудакова Ольга Владимировна,***
*Кама сәнгать һәм дизайн институты доценты,*
*Россия дизайнерлар берлеге әгъзасы.*
*Яр Чаллы шәһәре.*

## Г. ТУКАЙ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ III ҺӘМ IV ТОМНАРЫ ТУРЫНДА

2015 елда Г. Тукай әсәрләренең алты томлык Академик басмасының 3, 4 нче томнары дөнья күрде.

Академик басманың 3 нче томы – үзенең фәнни эшләнеше, тулылыгы белән бөтенләй яңа басма. Шагыйрьнең кульъязмалары сакланмаганга, беренче чыганаклар булып калган, үзе исән чагында чыккан барлык газета-журналларда басылган әсәрләре текстологик яктан яңадан тикшерелеп, кыскартылган урыннары өстәлеп тулыландырылган. Текстларда ялгыш укылган сүзләр, даталардагы хаталар, дөрес күрсәтелмәгән чыганаклар һәм башка фактик төгәлсезлекләр төзәтелгән. Сыйнфыйлык идеологиясенә туры китереп язылган элекке шәрех-комментарийлар яңадан эшләнгән. Текст эчендә булган яки алдагы басмалардан төшеп калган Коръән сүрәләре, гарәпчә гыйбарәләр, хәдисләрнең язылышы төзәтелеп, мәгънәләре татарчага тәрҗемә ителеп бирелгән. 1985 елгы басманың «Тукайныкы булуы ихтимал әсәрләр» бүлегеннән, авторы ачык билгеле булса да, ни сәбәптәндер шунда кергән ике әсәр төп өлешкә күчерелгән («Җәһаләт вә сәфаләт», «Мөкыйләмә, яхуд Мөсарәгате фикрәйн»).

Шулай ук моңа кадәр Тукай томнарында басылмаган, фәндә Тукайныкы дип кабул ителгән тәхәллүсләр (псевдонимнар) астында язылган 19 әсәр бу томга беренче мәртәбә кертелгән. Шулай итеп, бу томга Тукайның 1904–1906 елларда язылган, проза һәм публицистикасына караган 148 әсәр тәкъдим ителгән һәм алар барысы да хронологик тәртипне саклап урнаштырылган. Бу исә Тукайның фикер үсешен, иҗат лабораториясен ачыграк күзалларга һәм аңларга ярдәм итәр, дип уйлыйбыз.

Академик басманың 4 нче томына Г. Тукайның 1907–1913 елларда язылган публицистик мәкаләләре, проза һәм тәрҗемә әсәрләре Уральскида, соңрак Казанда чыгарылган «Фикер», «Әлислах», «Кояш», «Йолдыз», «Уклар», «Әлгасрелҗәдид», «Яшен» һәм «Ялт-йолт» кебек матбугат басмаларыннан алып урнаштырылган. Дөрес, аларның күбесе Тукай әсәрләренең элекке елларда нәшер ителгән ике-, дүрт-, биштомлыкларында инде дөнья күргән иде. Әмма бу басмалар Совет чорында әзерләнгәнгә күрә, аларда текстларны тулысынча төгәл бирү кыен булган, ә кайберләре бөтенләй кертелмәгән. 4 нче томны әзерләү барышында Г. Тукайның барлык публицистик мәкаләләрен дә урнаштыру төп максат итеп куелган. Элек читтә калып килгән, шагыйрьнең «Шүрәле», «Кырмыска» кебек мәгълүм имзалары белән чыккан барлык текстлар томга кертелгән. «Тәртә башы» псевдонимы белән басылган 4 текст, «Мөгаббир», «Татар угылы» имзалы 3 текст та, һичшиксез, Г. Тукай язган әсәрләр сыйфатында томның төп өлешенә урнаштырылган, шул рәвешле, Г. Тукайның тәхәллүсләре белән һәм имзасыз чыккан 20 мәкалә

шагыйрь томнарына беренче мәртәбә кертелгән. Барлык текстлар чыганаклар буенча тикшерелгән, заманында төшереп калдырылган урыннар, җөмләләр, сүзләр текстларга кире кайтарылган. Әсәрләрнең теле тулысынча диярлек сакланган. Тукайның публицистик мәкаләләре һәм проза әсәрләрендә XX гасыр әдәби теленә хас булган, аерым алганда, гарәп-фарсы, төрек, рус һәм европа телләреннән үтеп кергән алынма сүзләргә астөшермәләр бирелгән. Г. Тукай язмаларында очраган Коръән аятьләренә, хәдисләргә, дини гыйбарәләргә аңлатмалар язылган. Барлык искәрмә һәм аңлатмалар XX гасыр башы татар иҗтимагый тормышында барган тарихи һәм әдәби процесска таянып яңадан эшләнгән. Төрле чыганакларда табылган фактик материалларга нигезләнеп, әүвәлге басмаларда әле ачыкланып бетмәгән, дөрес шәрехләнмәгән реаль вакыйгалар һәм шәхесләргә кагылышлы искәрмәләр китерелү текстларны тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә. Кыскасы, искәрмәләрнең саны һәм күләме бермә-бер арткан, эчтәлеге тулылана төшкән. 4 нче том эчтәлеге белән дә, текстларның бирелеше, аңлатылышы белән дә Г. Тукай текстологиясенең җитди казанышы буларак бәяләнә ала.

***Шәйхелисламов Заһир Рәхмәтулла улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре;*
***Мөхәммәтшин Зөфәр Гомәр улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

19 сентябрь – 5 октябрь көннәрендә ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы А.А. Тимерханов Америкада узган фәнни конференциядә катнашты. Галим профессор Ринат Шәйхетдинов җитәкләгән Атлантик университетта (Флорида) студентларга лекцияләр укыды. Әлеге лекцияләрдә Россия Федерациясендәге тел сәясәте, Татарстан Республикасының бу өлкәдәге тәҗрибәсе, шулай ук төрки-татар лексикографиясе проблемалары яктыртылды. Төрки мәдәни үзәктә (Помпано Бич шәһәре) А. Тимерханов Майами, Бока Ратон, Бойнтон Бич шәһәрләрендә көн күргән татарлар белән очрашты, туган телне, милли мәдәниятне саклау һәм үстерү хакында фикер алышты.

7 октябрьдә иртән Арча зиратында Фәннәр академиясенә нигез салучы һәм аның беренче президенты булган М. Хәсәнов истәлегенә һәйкәл ачылды. Бюстның авторы – Казанның атказанган скульпторы Асия Миңнуллина. Шул ук көнне ТР Фәннәр академиясендә Мансур Хәсәновның тууына 85 ел тулуга багышланган «Гуманитарные науки в Татарстане на рубеже XX–XXI веков» Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе булды. Конференцияне ачуда ТР дәүләт киңәшчесе М. Шәймиев катнашты. Фәннәр Академиясе президенты М. Сәләхов М. Хәсәновнең Татарстанда Фәннәр академиясен ачуга зур өлеш керткән күренекле шәхес, күпкырлы галим булуын искәртте.

Конференция барышында алты томлы «Татар энциклопедиясе»нең русча вариантын тәкъдир итү булды. Бу хакта М. Шәймиев: «Шушы энциклопедияләр өчен без Мансур Хәсәнов җитәкләгән Татар энциклопедиясе институтына рәхмәтле булырга тиеш. Бу – бик әһәмиятле эш. Әлеге энциклопедияләр аша без үзебезне, эшләребезне, ирешкән дәрәҗәләребезне күрсәтәбез», – дип искәртте.

Конференция эшендә Татарстан, Удмуртия, Марий-Эл, Башкортстан галимнәре катнашты.

19–23 октябрьдә Бишкек шәһәрендә (Кыргызстан) «ART-ORDO» V Халыкара театр фестивале булып узды. Анда Кыргызстан, Казахстан, Таҗикстан һәм Татарстан драма театрлары катнашты. Безнең республика исеменнән Татар дәүләт драма театры чыгыш ясады. Ул тамашачыларга «Тирәкләр шаулый җирдә» (Авторы Ж. Сиблейрас, режиссеры Т. Имамутдинов) дигән спектакль тәкъдим итеп, «Иң яхшы актерлар ансамбле» дигән бүләккә лаек булды. Тәнкыйтьчеләр коллегиясендә ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының сәнгать бүлеге җитәкчесе Р.Р. Солтанова да эшләде. Шулай ук галим «Театр һәм заман» фәнни-гамәли конференциясендә «Театр сәнгатенең яңарыш юллары» (татар театры мисалында) дигән темага эчтәлекле чыгыш ясады.

21 октябрь көнне Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты бинасында «Татар телендә фән: үткәне, бүгенгесе, киләчәге» дигән темага түгәрәк өстәл булып узды.

Татар телендә фән бармы? Аның үткәне нинди? Бүген ничек яши ул? Ә киләчәге ничек булыр дип көтелә? Әлеге сораулар барысы да түгәрәк өстәлдә барган әңгәмәнең үзәк темалары булдылар. Чарада танылган галимнәр, фән эшлеклеләре катнашты. Араларында физика-математика фәннәре кандидаты, КФУның Н.И. Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институты доценты Әнис Галимҗанов, физика-математика фәннәре кандидаты, профессор Гамир Мөбәрәкҗанов, Татар энциклопедиясе институты директоры Искәндәр Гыйләҗев, Архитектура-төзелеш университеты доценты Рәшит Шакирҗанов,

филология фәннәре докторы, профессор Фәнүзә Нуриева, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фәнни эшләр буенча директор урынбасары, филология фәннәре кандидаты Олег Хисамов һ.б. бар иде.

27 октябрьдә НБ КазНЦ РАН уку залында ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Болгария, Абхазия һәм Көньяк Осетия галимнәре белән очрашу үткәрелде. Әлеге чара «Героический эпос как источник по этнической истории» семинары кысаларында узды.

Очрашуның төп кунаклары Абхазия Фәннәр академиясе президенты, Абхазия университеты профессоры, абхаз нарт эпосы, фольклоры, әдәбияты белгече Зураб Джапуа, Болгар академиясе фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы, болгар һәм балкан героик эпосы, фольклоры, этнографиясе, музыка белеме белгече Константин Рангочев, Көньяк Осетия университетының осетин һәм гомуми филология кафедрасы мөдире, доцент, осетин һәм кавказ эпосы, осетин теле тарихы, ономастика, иранистика, Кавказның этник тарихы буенча белгеч Альбертович Дзиццойты иде.

Кунаклар һәм институт хезмәткәрләре халыклар арасындагы тарихи бәйләнешләр, ТР ФА институтлары белән Болгария, Абхазия, Көньяк Осетия телче, әдәбиятчы, тарихчы галимнәренең киләчәктә дә элемтәдә тору, хезмәттәшлек итү мәсьәләләре хакында фикер алыштылар.

27 октябрьдә ТР ФА Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының конференц-залында җиде томлык «История татар с древнейших времен» хезмәтен тәкъдир итү булды. Әлеге чарада ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры Р.С. Хәкимов, РФ Дәүләт Думасы депутаты, профессор Ф.С. Сибагатуллин, ТР ФА Гуманитар фәннәр бүлеге җитәкчесе Н.М. Вәлиев, томнарның авторлары, фәнни редакторлары, академия һәм югары уку йорты вәкилләре катнашты. Әлеге хезмәтнең күптән көтелгән әһәмиятле басма булуы хакында фикер алыштылар.

2 ноябрь көнне Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгенә Көнчыгышны өйрәнү институты (Лейпциг), Ломоносов исемендәге МДУның Африка һәм Азия илләре институты студентлары килде. Кунаклар үзәк фондында саклана торган кулъязма китаплар, язучылар, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләренең шәхси архивлары, шәҗәрә коллекцияләре һ.б. белән танышты. Студентларга археографик экспедицияләр, татар халкының эпитафик истәлекләре, сирәк кулъязма һәм шәҗәрәләр, VIII гасыр ахыры – XX гасыр башында Идел-Урал төбәгендә киң таралган фикх һәм мантыйк дәреслекләре, Т. Ялчыгол, Г. Баруди, М. Бигиев, Р. Фәхретдин, Ш. Мәрҗани, Г. Утыз Имәни һ.б. хакында киң мәгълүмат бирелде. Шулай ук кунакларга төрле тематик юнәлешкә – дингә, суфыйчылыкка караган кулъязмалар, астрономия, мантыйк, фикх трактатларын, төрле уку-укыту әсбаплары һ.б. белән танышу мөмкинлеге бирелде. Германия кунаклары төрле вариантларда сакланып калган кулъязма Коръән коллекциясе белән кызыксынды. Аннары студентлар һәм магистрлар тимер пластинкаларга яздырылган татар көйләрен тыңладылар.

3 ноябрьдә Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, атаклы рәссам-монументалист, Бөтен диннәр гыйбадәтханәсенә нигез салучы Илдар Хановның (1940–2013) тууына 75 ел булды. Татарстан Язучылар берлегендә И. Ханов истәлегенә багышланган кичә үткәрелде, шунда ук «Ильдар Ханов. Воспоминания, размышления о творчестве» (автор-төзүче – Р.Р. Солтанова)

китабын тәкъдир итү булды. Сәнгать фәннәре кандидаты Динә Вәлиева, РТ халык шагыйре Равил Фәйзуллин, РТ халык рәссамы Владимир Попов, рәссам-монументалист Фәрит Вәлиуллин, архитектор Николай Мамаков, РТ халык артистлары Наилә Гәрәева, Миңгол Галиев һ.б. чыгыш ясады. Кичә И. Ханов турында төшерелгән «Песни света» (режиссеры Людмила Усова) документаль фильмын карау белән үрелеп барды. Кичәне ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының сәнгать бүлеге җитәкчесе Рауза Солтанова алып барды.

3 ноябрь көнне ТР Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институтында күренекле татар галиме, тарих фәннәре докторы, профессор Җәмил Гыйльмановның (1925–1991) тууына 90 ел булуга багышлап, киңәйтелгән Гыйльми совет утырышы уздырылды. Утырышта Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты галимнәре И.К. Заһидуллин, А.Ш. Кәбирова, Ә.Г. Галләмова һ.б., Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Ш.Н. Асылгәрәев, Н.Ш.Хисамов, Г.Г. Саберова, шулай ук ТР ФА академигы И.Р. Таһиров һ.б.лар галим турындагы истәлек-хатирәләре белән уртаклашты.

20 ноябрь көнне Язучыларның Тукай клубында (Бауман урамы, 19) Гаяз Исхакый истәлегенә багышланган «Төрки телле мәгълүмати мәйданда татар журналистикасының роле һәм урыны» дип исемләнгән фәнни-гамәли конференция булып узды. Әлеге чара КФУның социаль-фәлсәфи һәм гаммәви коммуникация институты, «Татмедиа» АҖ тарафыннан оештырылды. Конференциянең пленар утырышында ТФА Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре Ф.Г.Фәйзуллина институтның текстология бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнгән Гаяз Исхакый «Әсәрләр»енең унбиштомлыгын бастырып чыгару хакында сөйләде. Конференциядә катнашучылар игътибарына Г.Исхакый иҗатына һәм әлеге зур хезмәтне башкаручыларга багышланган презентация булды.

«Татар журналистикасы тарихын өйрәнү проблемалары» секциясендә ТФА Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге хезмәткәрләре Эльмера Галимҗанова һәм Гөлназ Хөснетдиновалар катнашып, татар вакытлы матбугаты тарихында әлегә кадәр фәнни дәрәҗәдә өйрәнелмәгән «Ил» («Безнең ил», «Сүз») һәм «Маяк» газеталары хакында чыгыш ясадылар.

19–21 ноябрь көннәрендә УФада IV Бөтендөнья башкорт корылтае һәм филология фәннәре докторы, профессор Ф.Г. Хисаметдинова юбилее уңаеннан «Россия халыклары телләре диалектологиясенең көнүзәк мәсьәләләре» дигән XV Бөтенроссия фәнни конференциясе уздырылды. Конференция эшендә Г.Ибраһимов исемендәге ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, профессор К.М. Миңнуллин, директор урынбасары О.Р. Хисамов, баш фәнни хезмәткәр Д.Б. Рамазанова һ.б. катнашты. Галимнәр үзләренең чыгышларында татар диалектологиясенә кагылышлы актуаль мәсьәләләрне яктырттылар. Конференция кысаларында галимнәр «Коръән» китабын һәм Г.Батталованың «Кояшлы Рәхмәт кызы Фирдәвес» фильмын тәкъдир итүдә дә катнаштылар.

25–27 ноябрь көннәрендә Казан дәүләт (федераль) университетында «Ике һәм күптеллелек шартларында дәүләт һәм төбәк телләре кулланылышының хокукый нигезләре (федератив дәүләт шартларында тел сәясәтен гамәлгә куюда дөнья тәҗрибәсе)» дип исемләнгән фәнни-гамәли конференция булып узды. Анда татар теленең кулланылышы, тел сәясәте, икетеллелек мәсьәләләре һ.б. турында чыгышлар ясалды.

Конференция эшендә ТР ФА Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтыннан М.З. Зәкиев һәм З.А. Исхакова катнашты.

Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Милли китапханәсе, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты 2015 елның 27 ноябрендә «Әнвәр Хәйри укулары: Милли-мәдәни мирасны барлау, өйрәнү һәм пропагандалау юлында» исемле фәнни-гамәли конференция үткәрде. «Әнвәр Хәйри хезмәттәшләре истәлекләрендә» дип аталган Беренче сессиядә галимнең замандашлары сүз алды. «Язма мирасны өйрәнүнең кайбер мөһим мәсьәләләре» исемле икенче сессиядә милли-мәдәни мирасны өйрәнүче галимнәр үзләренең фәнни ачышлары белән уртаклашты.

4 декабрь көнне ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин белән очрашу булды. Очрашуда Татарстан Фәннәр академиясе президенты Мәгъзүм Сәлахов, баш гыйльми сәркәтиб Д. Заһидуллина, Институт директоры К. Миңнуллин, Татар энциклопедиясе институты җитәкчесе И. Гыйләҗев, Ислам тикшеренүләре үзәге җитәкчесе Р. Патеев, институт хезмәткәрләре һ.б. катнашты.

Эшлекле сөйләшү барышында М.Сәлахов Татарстан Фәннәр академиясенең чит ил фәнни үзәкләре, Россия ислам университеты, башка югары уку йортлары белән хезмәттәшлеге, ислам уку йортларының хәзерге хәле, борынгы мирасыбызны халыкка кайтару мәсьләләренең актуальлеге хакында сөйләде. Шулай ук Болгар Ислам академиясен оештыру дини оешмалар алдына гына түгел, ә бәлки фән галимнәре өчен дә зур бурычлар куюын билгеләп, бердәм хезмәттәшлекне үстерүнең әһәмиятен ассызыклады.

К.Миңнуллин Язма һәм музыкаль мирас үзәгенең эшчәнлеге белән таныштырып, биредә саклана торган кыйммәтле хәзинә турында сөйләде, Татарстан Диния нәзарәте белән уртак проектлар, хезмәттәшлек хакында тәкъдимнәр белән чыкты.

Камил Сәмигуллин Болгар Ислам академиясен торгызу дәүләт җитәкчеләре, дин әһелләре, фән эшлеклеләре өчен уртак бер проект булуына басым ясады, алга таба да дини белемне үстерү, өйрәнү, киләчәк буыннарга тапшыруның уңай тәҗрибәсенә таянып, бердәм эшкә теләктәшлеген белдерде.

Очрашуда катнашучылар Мирасханәдә саклана торган кульязма Коръәннәр, борынгы китаплар, силсиләләр, шәҗәрәләр, шәхси фондлардагы сирәк һәм төп нөсхәдәге документлар урын алган кызыклы һәм эчтәлекле күргәзмә белән дә таныштылар.

14 декабрьдә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә генетика, этник тарих һәм антропогенез мәсьәләләренә багышланган семинар булды. Чара ТР Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исем. Археология институты тарафыннан оештырлган иде. Семинарның төп максат, бурычлары турында этник тарихның методологик проблемаларын өйрәнү секторы җитәкчесе тарих фәәннәре докторы, Россия Фәннәр академиясенең мохбир әгъзасы В.В. Напольских әйтеп үтте. Идел буе татарларын өйрәнүнең нәтиҗәләре һәм перспективалары турында биология фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының Фундаменталь медицина һәм биология институты хезмәткәре О.А. Кравцова чыгыш ясады. Соңыннан чарада катнашучылар өчен К.А. Тимирязев исем. Биология музееннан китерелгән «17 черепов и зуб, или Изменение человека во времени» күргәзмәсен карадылар.

## Журнал битләрендә 2015 елда дөнья күргән мәкаләләр исемлеге


**Тел белеме**

*Алишина Х.Ч.* Профессор Д.М. Насилов – борынгы уйгур теле һәм язуы буенча Россиядә беренбер белгеч. № 3. Б. 34–38.

*Асылгәрәев Ш.Н.* Татар теленең алфавиты һәм орфографиясе турында. № 2. Б. 32–41.

*Бәширова И.Б.* Татар телендә сүзнең лексик мәгънә типлары. № 3. Б. 17–26.

*Вәлиева Л.Г.* Төрки телләрнең синтаксик берәмлекләре арасында пространство мөнәсәбәте. № 1. Б. 20–23.

*Вәлиева М.З.* Лексик-семантик категорияләрне иске татар язма чыганаклары нигезендә өйрәнү тарихыннан. № 4. Б. 31–36.

*Гайнетдинова Г.Р.* Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия» язма истәлегенең исем сүз төркеменә тарихи-лингвистик анализ («Лут пәйгамбәр кыйссасы» мисалында). № 1. Б. 24–27.

*Зәкиев М.З.* Татар терминнары ясалу һәм аларны төркемләү. № 2. Б. 20–31.

*Ибраһимов Т.И., Сәйхунов М.Р.* Татар теле, татарлар һәм ассимиляция күренеше. № 1. Б. 6–14.

*Йосыпов Ф.Й.* Татар халкының югалып баручы этнографик төркемнәре: нагайбәкләр һәм нагайбәк сөйләше. № 3. Б. 5–16.

*Йосыпов Ф.Й.* Нагайбәк татарлары сөйләшенең фонетик үзенчәлекләре турында. № 4. Б. 9–18.

*Максимов Н.В.* Сөйләм теленә һәм язуга бер караш. № 3. Б. 27–33.

*Мирхәев Р.Ф.* Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә матур әдәбият һәм публицистик катламнар нисбәте. № 1. Б. 28–32.

*Мирхәев Р.Ф.* Татар язуы тарихыннан. № 4. Б. 25–30.

*Мөхәммәтшин Ф.М.* Хәзерге татар вакытлы матбугатының тел үзенчәлекләре. № 1. Б. 33–35.

*Рамазанова Д.Б.* Телебездә шумер теле белән уртак сүзләр. № 2. Б. 9–19.

*Сафина Э.И.* Кешеләрне сыйфатлаучы орнитоним компонентлы фразеологик берәмлекләр. № 1. Б. 15–19.

*Сәгъдиева Ф.К., Сәфәров Р.Т.* Поэтик текстта сугыш концептының ассоциатив-мәгънәви чагылышы (Ф. Кәрим лирикасы мисалында). № 2. Б. 5–8.

*Хисамов О.Р.* Бараба татарларын өйрәнү тәҗрибәсеннән. № 4. Б. 19–24.

**Әдәбият белеме**

*Әхмәтҗанов М.И.* Алтын Урда дәүләтенең башлангыч дәверендәге публицистик әдәбият традицияләре хакында (XIII–XVI йөзләр). № 3. Б. 51–55.

*Әхмәтьянов Р.Г.* Йосыф Баласагуни һәм аның «Кутадгу билик» әсәре турында. № 3. Б. 39–50.

*Ганиева-Гыйниятуллина А.Ф.* Гариф Ахуновның соңгы чор иҗатында яңа эзләнүләр. № 3. Б. 61–67.

*Гарипова Л.* Язучы Мөхәммәтгариф Бурнашев: тормыш юлы һәм иҗаты турында. № 2. Б. 65–69.

*Заһидуллина Д.Ф.* Г. Әпсәләмов прозасы: көчле кеше фәлсәфәсе аша романтизмга. № 2. Б. 42–50.

*Миңнегулов Х.Й.* Киң колачлы казакъ галиме (Күлбәк Ергобәк). № 3. Б. 56–60.

*Мусабәкова Р.Р.* Г. Тукай әсәрләренең рус теленә тәрҗемәләре (шигырь исемнәрен тәрҗемә итү аспекты). № 1. Б. 36–40.

*Харрасова Р.Ф.* Г. Ибраһимовның «Адәмнәр» фаҗигасе. № 1. Б. 48–53.

*Харрасова Р.Ф.* Әдәбият тарихының академик басмасына куелган таләпләр. № 2. Б. 55–59.

*Хәсәнова Ф.Ф.* Равил Фәйзуллин шигырьләрен тәрҗемә итү үзенчәлекләре. № 1. Б. 41–47.

*Хәсәнова Ф.Ф.* Ренат Харис иҗатында Муса Җәлил образы. № 2. Б. 51–54.
*Червинский Гжегож.* Бүгенге Польша татарлары әдәбияты проблемалары хакында. № 1. Б. 54–68.
*Шәрипов Ә.М.* Мәңгелеккә таулар белән каламын... (Әдхәт Синугылның тууына 80 ел). № 2. Б. 60–64.
**Әдәби багланышлар**
*Калижанов В.К.* Казакъстан әдәбияты һәм бүгенге заман. № 4. Б. 43–48.
*Кунафин Г.С.* XIX гасыр әдәби «башкорт җыры» жанрының идея-художество үзенчәлекләре № 4. Б. 37–42.
**Конкурска**
*Булатова М.Р.* Башкортстанда туган татар язучылары иҗатындагы телбизәкләр. № 3. Б. 68–75.
*Каюмова Г.И.* Ризван Хәмид драмаларында конфликт һәм характерлар гәүдәләнеше. № 2. Б. 70–84.
*Мансуров А.И.* Р. Гаташның «Ирләр булыйк» шигыренә салынган фәлсәфи фикер. № 3. Б. 76–80.
*Хаҗиева-Демирбаш Г.С.* Рафаил Газиз хикәяләренең поэтик ономастикасы. № 4. Б. 54–58.
*Хәбибуллина Л.Г.* Әдәби тәрҗемә мәсьәләсе (Анна Ахматованың «Сайланма әсәрләр»е мисалында). № 4. Б. 49–53.
**Халык иҗаты**
*Дәүләтшина Л.Х.* Казан арты татарларында йорт-каралты тирәсендәге рух-ияләр. № 1. Б. 74–82.
*Дәүләтшина Л.Х.* Халкыбызның дини-мифологик күзаллаулары (материал туплау өчен сораулык). № 4. Б. 65–74.
*Закирова И.Г.* Татар халык дастаннары. № 2. Б. 85–105.
*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* XIX йөз татар әдәбияты һәм китаби дастаннар: тарихи янәшәлек. № 1. Б. 69–73.
*Рогачев В.И.* Мордва фольклорында татар образы. № 4. Б. 59–64.
*Ямалтдинов И.И.* Тукай турында бәетләр. № 3. Б. 81–84.
**Тарих сәхифәләре**
*Баһаветдинова Х.З., Исхаков Р.Р.* XIX гасырның икенче яртысында Казан арты керәшен татарлары тормышының укытучы Т.И. Тмәй көндәлегендә чагылышы. № 1. Б. 96–102.
*Гарипова З.Г.* Мөһаҗирлектәге татарларның милли-мәдәни тормышы. № 2. Б. 106–121.
*Заһидуллин И.К.* Мөселманнарның хокукларын киңәйтү турында Казан сәүдәгәрләренең 1879 елгы «программасы». № 1. Б. 83–90.
*Исхаков Р.Р.* XVI–XVII гасырда Идел–Урал халыкларын христианлаштыру һәм татар-керәшен конфессиональ берлеген формалаштыру мәсьәләсенә карата. № 3. Б. 85–104.
*Кореева Н.А.* XIX гасырның беренче яртысында татар эшмәкәрләре эшчәнлегендә вексель хокукы. № 4. Б. 75–86.
*Мөстәкыймов И.А.* XVII гасырның икенче яртысы – XVIII гасыр башы Урта Идел тарихына караган ике мәгълүмат. № 3. Б. 105–108.
*Сәлахова Э.К.* Казанның Болгарга мөнәсәбәте. № 1. Б. 91–95.
**Фәлсәфи фикер**
*Корганбеков Б.С.* Күчмә төркиләрнең рухи яшәешендә Хуҗа Әхмәт Ясәви карашлары. № 4. Б. 87–98.
**Төгәл фәннәр**
*Галимҗанов Ә.Ф., Миңнегалиева Ч.Б.* Гомумиләштерелгән интерполяцион полиномиаль оператор. № 4. Б. 99–110.

*Минһаҗев М.Н., Минһаҗев Б.М., Кыямова А.Г.* Татарстан геологик структураларының нефть бирүчәнлеге һәм җир кабыгының яңа геодинамикасы арасындагы бәйләнеш. № 1. Б. 103–111.

**Шәхесләребез**

*Бустанов Ә.К.* Татар археографы Альберт Фәтхинең шәхси архивы. № 1. Б. 112–126.

*Заһидуллин И.* Хәсәнгата Габәши хатирәсе. № 2. Б. 122–139.

*Хәсәнгата Габәши.* Тәрҗемәи халемнән, гыйльми һәм иҗтимагый хезмәтләремнән беркадәресе. № 2. Б. 139–145; № 3. Б. 118–148.

*Яхин Ф.З.* Татар әдәбият белемендә Гали Халит. № 3. Б. 109–117.

**Мансур Хәсәновка – 85**

*Заһидуллина Д.Ф.* Әдәбият галиме Мансур Хәсәнов: Г. Ибраһимовның иҗат мирасын комплекслы өйрәнү. № 4. Б. 111–115.

*Зыятдинов А.Ш.* Ул эш кешесе иде. № 4. Б. 121–126.

*Таһиров И.Р.* Мансур Хәсәнов – күренекле галим, кыю һәм тәвәккәл дәүләт эшлеклесе. № 4. Б. 116–120.

*Фәйзуллина Ф.Г.* Мансур Хәсәнов. «Сайланма хезмәтләр». Яңа китапка күзәтү. № 4. Б. 127–129.

**Таҗи Гыйззәткә – 120**

*Арсланов М.Г.* Таҗи Гыйззәтнең иҗат эволюциясе. № 4. Б. 140–145.

*Галимуллин Ф.Г.* Таҗи Гыйззәт иҗатында татар халкы язмышы. № 4. Б. 130–134.

*Миңнуллина Ф.Х.* Т. Гыйззәт драматургиясендә шәхес фаҗигасе. № 4. Б. 135–139.

*Хәйруллин И.З.* Таҗи Гыйззәт иҗаты һәм периферия театрлары. № 4. Б. 154–156.

*Шакирҗан Л.Г.* Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры репертуарында Таҗи Гыйззәт иҗаты. № 4. Б. 146–153.

**Җәмил Гыйльмановка – 90**

*Хәмидуллин Л.* Ул һәрчак үрнәк булды. № 4. Б. 157–159.

**Милли мәгариф**

*Әхтәмова А.В.* Педагогик тикшеренү үзәкләре (1960–1970 еллар). № 1. Б. 148–152.

*Ганиев Ф.Ә.* Татарның үз дәүләте каршында ни гаебе бар? № 2. Б. 146–149.

**Фәнни ядкәрләр**

*Әхмәтҗанов М.И.* Татар әдәбиятында Алтын Урда поэзиясен фәнни нигездә тикшерүнең беренче тәҗрибәсе. № 1. Б. 127–140.

*Нигъмәт Хәким.* Имля хакындагы корылтай карарлары турында. № 3. Б. 150–153.

*Шәрәф Г.* Беренче буын (иҗектәге) «о», «ө» авазларының үзеннән соңгы авазларга тәэсире һәм бу тәэсирне язуда күрсәтү-күрсәтмәү мәсьәләсе. № 1. Б. 141–147.

**Экспедицияләр эзеннән**

*Алкая И.* Себергә сәяхәт. № 4. Б. 160–167.

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Юлы уңның эше уң, яки Самарага сәяхәт. № 3. Б. 154–161.

*Шкляева Л.М.* Самара өлкәсе татарлары: авыл төзелешендә тәрәзә йөзлекләрен традицион орнаментлар белән бизәү. № 1. Б. 153–158.

*Шкляева Л.М.* XX–XXI гасырларда Урта Идел буе авылларында яшәүче татарлар йортының тышкы бизәлешендә кошлар образы (2013 елгы экспедиция нәтиҗәләре буенча). № 2. Б. 150–155.

**Сәнгать**

*Газизова М.Р.* Сатирик рәссам Илдар Нәфиев иҗаты. № 3. Б. 162–164.

*Галимова Э.М.* Мордовиядә яшәүче татарларның җыр үзенчәлекләре (Абдулла Кротов башкаруындагы җырлар мисалында). № 3. Б. 165–170.

*Москвина А.Р.* Татарстанда монументаль сынлы сәнгать үсешенең бүгенге тенденцияләре. № 1. Б. 159–163.

*Новикова С.Н.* Харис Якуповның фронт графикасы. № 2. Б. 156–159.

*Сәйдәшева З.Н.* Фәрит Яруллин – композитор һәм сугышчы. № 2. Б. 160–166.

*Фәрдиева Д.Р.* «Инсаният» труппасының эшчәнлеге. № 1. Б. 164–166.